# Самарские татары
# Самар татарлары

ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР

№ 2 (35), АПРЕЛЬ – ИЮНЬ, 2022



«ВМЕСТЕ МЫ МОГЛИ БЫ ДЕЛАТЬ БОЛЕЕ МАСШТАБНЫЕ ВЕЩИ»



ИСЕМЕҢ ДӘ СИНЕҢ «ЯКТЫЛЫК» БИТ!



«МАЛАЯ ЗЕМЛЯ» НА ДНЕПРОВСКОМ БЕРЕГУ



САБАН ТУЕ – ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ СИМВОЛЫ



## «ГАЗИЗ ХАЛКЫМА ХЕЗМӘТ ИТЕП ЯШӘГӘНЕМ ӨЧЕН РАББЫБЫЗГА МЕҢ ШӨКЕР»

6+










ГОД ОСНОВАНИЯ 1974

**Кулинария**

НА РЕВОЛЮЦИОННОЙ

- Праздничные торты и пирожные по индивидуальным заказам
- Готовые изделия из мяса, рыбы, птицы
- Салаты и гарниры
- Охлажденные и замороженные полуфабрикаты
- Большой ассортимент свежей выпечки
- Принимаем заказы на пироги
- Доставка горячих обедов в офис
- Обслуживание банкетов и фуршетов

**г. Самара, ул. Революционная, 142**

**Тел.: 260-10-60, 260-15-60**











# Хөрмәтле дуслар!

Сезгә журналыбызның быелгы икенче санын тәкъдим итүемә шатмын.

Бу юлы басмабыз гадәттән тыш килеп чыкты. Беренчедән, ул, элеккеге саннарга караганда, күләмлерәк. Һәм бу Бөтендөнья татар конгрессының юбилейлы, 30нчы җыелышы белән бәйле. Әлеге чара июль ахырында Казанда узачак. Шушы вакыйга алдыннан без журналыбызда танылган публицистларга, җәмәгать эшлекләренә сүз бирдек. Алар милләтебезнең киләчәге турында уй-фикерләре белән уртаклаштылар.

Икенчедән, җәй – ул яраткан Сабан туебызны бәйрәм итү вакыты. Быел, ковид сәбәпле кертелгән чикләүләр гамәлдән чыгарылгач, татар милли бәйрәме губернабызның күп авыл-шәһәрләрендә узды. Әлбәттә инде, Самарда өлкә Сабан туе да гөрләп үтте.

Шулай ук Самар делегациясе 17 – 18 июньдә Ульян шәһәрендә уздырылган Федераль Сабан туенда да катнашты. Шуларның барысы турында басмабыздан укып белерсез.

Медицина хезмәткәрләре көненә багышланган мәкаләләрне дә урнаштырдык.

Һәм, гадәттәгечә, регионыбыз һәм, гомумән, илебез үсешенә зур өлеш керткән лаеклы якташларыбыз, мөһим вакыйгалар турында да укып белерсез.

Авторларыбызның тирән эчтәлекле мәкаләләре сезне битараф калдырмас, дип ышанам.

Яңа очрашуларга кадәр!



**Данияр СӘЙФИЕВ,**
*“Самар татарлары” журналы мөхәррире*

# Дорогие друзья!

Рад представить вам второй в этом году номер нашего журнала. В этот раз он получился не совсем обычным. Во-первых, он стал более объемным по сравнению с предыдущими номерами, и связано это с предстоящим юбилейным, 30-м съездом Всемирного конгресса татар, который в конце июля состоится в Казани. В преддверии этого события мы на страницах издания предоставили слово известным публицистам и общественным деятелям, которые поделились с нашими читателями своими размышлениями о будущем нашей нации. Во-вторых, лето – это время проведения нашего любимого праздника Сабантуй. В этом году, когда были сняты все ковидные ограничения, татарские национальные праздники прошли во многих селах нашей губернии. Конечно же, традиционный областной самарский Сабантуй состоялся и в Самаре. Более того, самарская делегация побывала на Федеральном Сабантуе, который состоялся 17–18 июня в Ульяновске. О том, как все это было, вы узнаете, прочитав репортажи с этих событий в нашем журнале.

Также часть материалов мы приурочили ко Дню медицинского работника и постарались познакомить вас с яркими представителями этой гуманной профессии. Как всегда, мы подготовили разноплановые материалы о заслуженных земляках, внесших большой вклад в развитие нашего региона и страны в целом, наиболее важных событиях, прошедших с начала зимы в жизни самарского татарского сообщества. Надеюсь, что работа, проделанная нашими авторами, не оставит вас равнодушными.

До новых встреч!


РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ

**Шакуров Ильяс Гумерович –** президент СОТО «Туган тел»; председатель правления НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», член Общественной палаты г.о. Самара

**Хазиев Артур Ахатович –** председатель Центра Стратегических Исследований «Платформа XXI»

**Сайфиев Данияр Ирекович –** гл. редактор журнала «Самар татарлары» («Самарские татары»)

**Нуретдинова Римма Равильевна –** главный редактор сайта samtatnews.ru

**Вакказов Расих Ахметшамилович** имам-хатыб мечети «Булгарское наследие»

**Ибятова Ляйсян Замиловна –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Надиров Азат Камилович –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Махмутова Альбина Харисовна –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Сафин Иршат Халилович –** имам-хатыб Соборной мечети г. Самары

**Хузин Ривгат Туктарович –** председатель комиссии Общественного совета при ГУ МВД России по Самарской области

**Мифтахов Искандер Фуадович –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Рамазанова Гюзяль Ибрагимовна –** директор СОТО «Туган тел»

**Юсупов Рамиль Закяриевич –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Юсупов Фагим Ханифович –** член Совета СОТО «Туган тел»

РЕДАКЦИОННАЯ КОЛЛЕГИЯ

**Биктаев Наиль Данисович**
**Варфоломеева Эльмира Мугаммаровна**
**Галимов Шамиль Хайдарович**
**Мифтахов Искандер Фуадович**
**Файзуллов Рустам Ильясович**
**Салахова Лилия Акрямовна**
**Ширияздaнов Фарид Хамитович**
**Шарипов Руслан Кабирович**

# Содержание:

Его имя будут помнить всегда ... 6
Прославленный ансамбль на самарской земле ... 8
Исемең дә синең «Яктылык» бит! ... 9
“Язмышыбыз үзебездән тора, татарларым!” ... 11
Беренче карлыгачлар ... 14
Рабит Батулла: «У меня еще остается надежда...» ... 19
Дефицит мотивации ... 24
Рустам Ямалеев: «Вместе мы могли бы...» ... 26
Обращение Национального конгресса татар ... 29
Роль современных информационно-коммуникационных технологий ... 32
“Газиз халкыма хезмәт итеп яшәгәнем өчен Раббыбызга мең шөкер” ... 34
Рейхстаг түбәсенә Кызыл байрак элгән каһарман ... 42
«Малая земля» на днепровском берегу ... 44
Иске Ярмәкнең батыр татары ... 55
Военный путь малая из Мукмень-Каратая ... 58
Әтисез узган гомер... ... 70
“Вакытны – бушка, гомерне заяга уздырмыйсы иде” ... 73
“Балачактан хыялланган һөнәремдә бик бәхетле мин” ... 76
Табиб булу өчен белем генә җитми ... 79
Эта служба и опасна, и трудна... ... 82
Укучыларына, хезмәтенә карата күңеле мәхәббәт белән тулы ... 86
А может быть, буртасы ... 91
«Добрый царь» ... 93
Җәдитчелек – татар халкын үсеш юлына бастырган мәгърифәт эшчәнлеге ... 95
Среди первых советских олимпиоников ... 109
Чтобы достичь успеха, не надо себя жалеть ... 118
«Батыр» егетләре Самарны таныта ... 120
“Киләчәктә укучыларымны татар милли гореф-гадәтләренең дәвамчылары итеп тәрбиялисем килә” ... 123
Для тех, кто ценит свое время ... 126
И Солнце в небе ближе: небесные светила в духовной культуре ... 129
Традиционная азербайджанская культура и Самарский край ... 131
Сабан туе – халыклар дуслыгы символы ... 133



56 ГАЙСӘ МӘХМҮТ УЛЫ ХӘСӘНОВНЫҢ ЛЕГЕНДАР ТОРМЫШ ЮЛЫ



101 НА КРЫЛЬЯХ ДЗЮДОГИ И САМБОВКИ



137 БӨТЕНХАЛЫК САБАН ТУЕ



38 ОН БЫЛ НАСТОЯЩИЙ ПОЛКОВНИК

## Уважаемые друзья!

***Приобрести журнал «Самар татарлары» можно по следующим адресам:***

- **Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»)**
- **Самара, пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»),**
- **магазин «Булгар» на территории Соборной мечети Самары.**

**Стоимость текущего номера с доставкой – 220 рублей, стоимость номеров за 2020 год – 300 рублей, все предыдущие номера – по 700 рублей.**
**Доставка журналов по Самаре – тел.: 8-937-64-044-77.**

Издатель «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», адрес: 443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28

**Главный редактор:** САЙФИЕВ Данияр Ирекович
**Корреспонденты:** Миляуша ГАЗИМОВА, Фарид ШИРИЯЗДАНОВ, Шамиль ГАЛИМОВ, Рашид ШАКИРОВ, Нурсина ХАКИМОВА
**Дизайн-макет, верстка:** Александр ГОРБАЧЕВ, Юрий ШВЕЦ
**Фото:** Миляуша ГАЗИМОВА, Аняс МИНГАЛЕЕВ
**Корректоры:** Миляуша ГАЗИМОВА, Вадим ОЛЕНИН

**Адрес редакции:**
443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28
**Телефон редакции:** 8-917-104-44-45
**Электронная почта:** samartatarlary@bk.ru
**www.samtatnews.ru**

**Отпечатано в ООО «Полиграфика плюс»,**
443070, Самарская область, г. Самара, ул. Верхне-Карьерная, 3а

**Журнал «Самар татарлары»** («Самарские татары»), № 2 (35), апрель–июнь, 2022 г.
**Учредитель:** «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области»
Журнал зарегистрирован Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области. Свидетельство о регистрации СМИ: ПИ №ТУ63 – 00628 от 15.10.2013 г.
Дата выхода 30 июня 2022 г.
Тираж 1000 экз. Цена свободная

# МИННИХАНОВ ОСТАЕТСЯ ПРЕЗИДЕНТОМ

Как заявила пресс-секретарь Рустама Минниханова Лилия Галимова, президентский статус в республике будет сохранен на фоне вступления в силу закона о единственном президенте для всей страны.

*www.islamnews.ru*



Галимова напомнила, что законом предусматривается переходный период. Согласно нововведению, вступившему в силу 1 июня, регионы РФ должны отказаться от слова «президент» при указании должности руководителя субъекта и выбрать для нее одно из двух названий – глава или губернатор.

Работа по приведению региональных законодательств в соответствие с данным федеральным законом должна быть завершена до начала 2023 года.

# АЛИНӘ ЗАҺИТОВАГА «ЯҢА ЗАМАН СПОРТЧЫСЫ» ПРЕМИЯСЕН БИРДЕЛӘР

*tatar-inform.tatar*



Фигуралы шуу буенча 2018 елгы Олимпия чемпионы Алинә Заһитова «Яңа заман спортчысы» («Спортсмен нового времени») номинациясендә премия алуын шәрехләде.

«Бу бүләк өчен зур рәхмәт. Минем өчен «Яңа заман спортчысы» номинациясендә җиңү зур кыйммәткә ия, чөнки спорт – ул минем бөтен тормышым», — диде Заһитова. Бу хакта «Матч ТВ» хәбәр итә.

Моннан тыш, Әлмәттә туып-үскән кыз Россия спортына нәрсә кирәк булуын белүе турында әйтте.

«Мин безнең спортка нәрсә кирәген беләм, сезнең белән бергә аны көчлерәк итәсем килә. Әлегә спортчы һәм телетапшырулар алып баручы булырак, ә киләчәктә — кем белгән», — диде Алинә Заһитова.

Искәртик, ул 2018 елда Олимпиадада җиңгәннән соң спорт карьерасын туктатып торды.

# РОССИЯ ФЕДЕРАЛЬ ТРАССАЛАРЫНДА НАМАЗ БҮЛМӘЛӘРЕ АЧЫЛА

9 июнь көнне «Мәскәү–Уфа» М7 федераль трассасының 710 нчы чакрымында «Ирбис» автомобильләргә ягулык салу станциясе территориясендә Россия федераль трассаларында стационар намаз уку бүлмәләрен ачу буенча «Юлчы намазы» проектын гамәлгә ашыруга рәсми старт бирелде.

*tatar-inform.tatar*

Барлыгы «Волга» М7 һәм «Урал» М5 трассаларында илнең 7 төбәгендә: Владимир һәм Түбән Новгород өлкәләре, Чувашия, Мари Эл Республикалары, Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы, шулай ук Пенза өлкәсендә 24 стационар намаз уку урыны ачу ниятләнә. Намаз бүлмәләре челтәре картасы автомобиль юлларының теге яки бу участокларында булган ихтыяждан чыгып төзелде. Бу хакта ТР Диния нәзарәте матбугат хезмәте хәбәр итә.

Бүген беренче намаз бүлмәсе үз ишекләрен М7 трассасының 710 километрында Чувашия Республикасының Сине-Кинчере авылында ачты. Монда берьюлы 10 кеше намаз укый ала.



# ПЕРВЫЙ В РОССИИ ПЕЧАТНЫЙ КОРАН ПРИВЕЗЛИ ИЗ ПЕТЕРБУРГА НА ВЫСТАВКУ В КАСИМОВ



Историческую реликвию, первый печатный Коран, который был создан в России в 1787 году, привезен из Петербурга на выставку в город Касимов Рязанской области. Он будет представлен на VI Всероссийской научно-практической конференции «Чтения имени Мухлисы Буби», которая стартовала 9 июня.

*tatar-inform.ru*

«Первый печатный Коран, изданный на арабском языке по указу Екатерины II в 1787 году, впервые вышел за пределы стен Российской национальной библиотеки. Сейчас Коран находится в Касимове, перед вами. И мы имеем честь воочию видеть первый в истории печатный Коран. Выражаю благодарность руководству Российской национальной библиотеки за организацию перевозки священной реликвии сначала из Петербурга в Москву, а затем в Касимов. Отдельное спасибо за то, что сохранили это сокровище до наших дней в отличном состоянии», – отметил первый заместитель председателя Духовного управления мусульман РФ Дамир Мухетдинов.

По словам Мухетдинова, специально для первого печатного Корана казанский имам Усман Исмаил разработал арабский шрифт, который впоследствии стал известен как «Казан басмасы». «Шрифт Корана, изданного в 1787 году в Петербурге, и Корана, напечатанного в 1803 году в Казани, – один и тот же. Усман Исмаил оставил пояснения на полях петербургского издания, это доказывает его высокую образованность», – отметил Дамир Мухетдинов.

Сегодня в Касимове стартовала VI Всероссийская научно-практическая конференция «Чтения имени Мухлисы Буби». Конференция приурочена к 1100-летию официального принятия ислама народами Волжской Булгарии, 870-летию основания города Касимова и 570-летию со дня основания Касимовского ханства.



## В ГОСДУМУ ВНЕСЕН ЗАКОНОПРОЕКТ О СДАЧЕ ЕГЭ НА РОДНОМ ЯЗЫКЕ

*islamnews.ru*

В России может появиться единый государственный экзамен (ЕГЭ) по языкам коренных народов страны. Соответствующий законопроект внесла в Госдуму группа депутатов из госсобрания Республики Башкортостан. Документ опубликован на сайте Системы обеспечения законодательной деятельности, сообщает «Лента».

Депутаты предложили внести изменения в федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации». В пояснительной записке парламентарии отметили, что школьные предметы «Родной язык» и «Родная литература» являются обязательными к изучению, однако при этом остаются единственными учебными дисциплинами, не включенными в перечень предметов, по которым проводится государственная итоговая аттестация (ГИА).

«Освоение образовательных программ среднего общего образования должно завершиться государственной итоговой аттестацией. Однако по действующему законодательству порядок и форму проведения ГИА устанавливают органы государственной власти субъектов Российской Федерации, вследствие чего результаты единых региональных экзаменов (ЕРЭ) по родному языку и родной литературе не учитываются при поступлении в образовательные организации высшего образования, даже на профильные специальности», – объясняется в дополнении к документу.

Депутаты добавили, что в случае принятия законопроекта новые нормы проведения ЕГЭ позволят выпускникам сдавать экзамены по родному языку и литературе, с результатами которых можно будет поступать на обучение в вузы.

## ГЫЙБАДӘТХАНӘЛӘР АРХИТЕКТУРАСЫ

Бу ел башында Самарда берничә яңа китап басылып чыкты. Шуларның берсе – “Самар губернасындагы гыйбадәтханәләр архитектурасы” дип атала. Анда XIX гасырның икенче яртысы — XX гасыр башына караган корылмалар урнаштырылган. Китап-альбомны Самар өлкәсенең Үзәк архивы хезмәткәрләре басмага әзерләгәннәр һәм 300 данә тираж белән бастырып чыгарганнар.

Әлеге басманы тиңсез дип атарга да була. Андагы материаллар өлкәбезнең күпконфессиональле, бөтен диннәрнең һәм милләтләрнең дә дус һәм тату булуын дәлилли. Самарның кабатланмас архитектурасын төрле стильләрдә төзелгән православ храмнары, католик һәм лютеран чиркәүләре, мәчетләр һәм синагогалар бизи.



“Самар губернасы, чыннан да, үзенчәлекле регион. Биредә гасырлар буе үзләренең телләрен, культураларын һәм диннәрен саклап, төрле милләт халыклары яши. Алар тугандаш халыклар булып яшәгәнлектән, Самар губернасы башкаласының архитектурасы да бай һәм күпкырлы булып күренә”, — дип яза кереш сүзендә губернатор Дмитрий Азаров.

Туган як тарихчысы Шамил Галимов та, бу китапны туплау эшендә катнашып, өлкә авылларында сакланган борынгы мәчетләрнең проектларын китапка кертүдә булышкан. Камышлы районының Иске Ярмәк авылында — 1902 елда, Кошки районының Иске Фәйзулла авылында — 1890 елда, Похвистнево районының Яңа Мансур авылында — 1904 елда, Шенталы районының Денис авылында — 1909 елда, Самар шәһәренең хәзерге Алексей Толстой урамында 1891 еллар тирәсендә салынган мәчетләрнең проектлары һәм рәсемнәре, кайберләренең фотосурәтләре һәм тарихы да китап-альбомга кертелгән.

Китапны төзүчеләр әлеге басма альбом белгечләргә — архитекторларга, тарихчыларга, мәдәният хезмәткәрләренә генә түгел, туган як тарихына битараф булмаган башка якташларыбызга да кызыклы булыр, дип өметләнәләр.

## УКУЧЫЛАРГА ҺӘМ УКЫТУЧЫЛАРГА ГРАНТЛАР ТАПШЫРЫЛДЫ

Самарның «Яктылык» татар мәктәбендә узган чыгарылыш тантанасында 12нче тапкыр Алия Аләветдин кызы Шәкүрова исемендәге премия тапшырылды. Быелгы премия татар теле олимпиадаларында һәм конкурсларында җиңү яулаган, укуда яхшы нәтиҗәләр күрсәткән 28 укучыга һәм аларның укытучыларына бирелде.

37 ел буе Тупли авылы мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укыткан Алия Аләветдин кызы Шәкүрова исемендәге грантны «Туган тел» җәмгыяте президенты, «Яктылык» мәктәбенең Попечительләр советы рәисе Ильяс Шәкүров үз акчасыннан финанслый. Алия апа - мәктәптә эшләгән чорда күпсанлы грамоталар һәм медальләр, шулай ук Татарстан Республикасының мәгариф министрлыгы тарафыннан «Мәгариф



өлкәсендәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән зыялы шәхес. Ә аның иң югары казанышы — күпсанлы укучыларының тануы һәм хөрмәте. Тормыш иптәше Гомәр Закир улы белән алар өч бала тәрбияләп үстергәннәр, ике уллары профессорлар дәрәҗәсенә күтәрелгәннәр.

Укытучыларга һәм укучыларга бүләкләрне “Туган тел” җәмгыяте директоры Гүзәл Рамазанова тапшырды.

Грант алучылар арасында татар теле буенча өлкә, регионара һәм халыкара олимпиадаларда, Каюм Насыйри исемендәге XX регионара фәнни-гамәли укуларында, “Җәлил укулары” халыкара әдәби конкурсында югары урыннарга ирешкән укучы балалар һәм аларның укытучылары Фәния Гыйлаҗева, Фәүзия Дәүләтбаева, Рәхимә Хәйрова, Фәридә Хәмидуллова, Асия Сәйфетдинова.

# У ГЕРОЯ РОССИИ, ПИЛОТА ДАМИРА ЮСУПОВА РОДИЛСЯ СЫН

*sovainfo.ru*

Дамир Юсупов подписал снимок, на котором гордый и счастливый стоит рядом с коляской: «Первое фото с новым человечком».

По цвету коляски можно было бы подумать, что в семье появилась девочка, но многие подписчики решили не угадывать, а спросить прямо. Дамир Юсупов ответил, что у него родился сын.

Напомним, Дамир Юсупов стал народным героем и прославился на весь мир после посадки самолета в кукурузном поле в Подмосковье в августе 2019 года. Чудом стало то, что более 200 пассажиров в авиационном происшествии остались целы и невредимы. До того, как стать летчиком, Дамир несколько лет работал юристом в Сызрани.





# ИЛЬЯС ГУМЕРОВИЧ ШАКУРОВ ВОШЕЛ В СОСТАВ ОБЩЕСТВЕННОЙ ПАЛАТЫ Г.О. САМАРА

30 мая 2022 года президент Самарского областного татарского общества «Туган тел» Ильяс Шакуров утвержден членом Общественной палаты г.о. Самара – совещательного и консультативного органа города.

Поздравляем Ильяса Гумеровича и желаем дальнейшей плодотворной работы!

# ПОЧЕТНЫЙ ГРАЖДАНИН РАЙОНА

Решением Собрания представителей муниципального района Похвистневский звание «Почетный гражданин Похвистневского района» за большой вклад в сохранение межнационального и межконфессионального мира и согласия в обществе, за активную общественную работу на территории муниципального района Похвистневский присвоено Фахрутдину Канюкаеву, президенту Самарской региональной творческой общественной организации «Дуслык», уроженцу села Мочалеевка. Соответсвующее удостоверение Фахрутдину Канюкаеву 19 июня вручил глава Похвистневского района Юрий Рябов.




# В ЯКУТИИ СТАРТОВАЛИ ДНИ ТАТАРСКОГО КИНО




*«Татар-информ»*

В рамках Дней Татарстана в Республике Саха (Якутия) в кинотеатре «Лена» стартовали показы татарстанского кино. Первой зрителям оказалась представлена музыкальная комедия «Эпипэ» режиссера Ильшата Рахимбая.

Зал был заполнен на 50%, и это считается хорошим показателем для такого рода мероприятий. После показа фильма «Эпипа» якутским зрителям представили драматический фильм Ильдара Ягафарова «Исәнмесез», который на XVII Казанском международном фестивале мусульманского кино завоевал приз Президента Татарстана «За гуманизм в киноискусстве» и приз зрительских симпатий.

# ВСЕТАТАРСКИЙ ОБЩЕСТВЕННЫЙ ЦЕНТР* ПРИЗНАН ЗАПРЕЩЕННОЙ ЭКСТРЕМИСТСКОЙ ОРГАНИЗАЦИЕЙ

*realnoevremya.ru*

Верховный суд Татарстана принял решение ликвидировать Всетатарский общественный центр* как экстремистскую организацию. Об этом сообщили в пресс-службе суда.

Суд удовлетворил иск прокуратуры Татарстана. Решение суда пока не вступило в законную силу, уточняет «Интерфакс».

В прокуратуре «Реальному времени» поясняли, что деятельность организации носит экстремистский характер и представляет угрозу основам конституционного строя РФ.




В декабре Всетатарский общественный центр* признали Вахитовским районным судом виновным по статье о возбуждении ненависти либо вражды, а равно унижении человеческого достоинства, и оштрафовали на 250 тысяч рублей.

** Общественное объединение «Татарстанское региональное всетатарское общественное движение – Всетатарский общественный центр» входит в перечень общественных и религиозных объединений, деятельность которых запрещена в связи с осуществлением ими экстремистской деятельности.*

***В Самарском доме дружбы народов прошла презентация трехтомной монографии «Материалы к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая», подготовленной Институтом языка, литературы и искусства Академии наук Республики Татарстан. Уникальное издание вобрало в себя архивные источники, письма, дневники, воспоминания, материалы из газет и журналов, различные официальные документы. Все это дает возможность увидеть жизненный и творческий путь известного татарского поэта.***

*Данияр Сайфиев*

# ЕГО ИМЯ БУДУТ ПОМНИТЬ ВСЕГДА

В Самарском доме дружбы народов прошла презентации трехтомной монографии «Материалы к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая», подготовленной Институтом языка, литературы и искусства Академии наук Республики Татарстан. Уникальное издание вобрало в себя архивные источники, письма, дневники, воспоминания, материалы из газет и журналов, различные официальные документы. Все это дает возможность увидеть жизненный и творческий путь известного татарского поэта.

Презентовал издание кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства АН РТ Марсель Ибрагимов, который рассказал о том, как шла работа над подготовкой монографии, какие при этом открывались неизвестные ранее страницы биографии поэта. Поделился Марсель Эльдарович и своими впечатлениями от посещения гостиницы «Жигули» (ранее «Бристоль»), где когда-то останавливался Тукай. Он напом-



нил собравшимся о самарских злоключениях, о которых с горечью поэт писал после в своих путевых заметках. Дело в том, что, ступив на самарскую пристань, а Тукай путешествовал на теплоходе, он нанял извозчика и попросил его отвезти в недорогую гостиницу. Извозчик отвез его в «Бристоль» (ныне «Жигули»), где номер обошелся ему в один рубль. Для сравнения, в гостиницах тогда можно было снять номер за 40–50 копеек. Поселившись в «Бристоле», поэт решил навестить имама Мухаметфатыха Муртазина. Нашего города



Тукай, конечно же, не знал и поэтому согласился на условия извозчика, который за поездку до дома имама зарядил опять же целый рубль. Каково же было удивление и разочарование Тукая, когда извозчик высадил поэта на следующем перекрестке: выяснилось, что Муртазин жил совсем рядом.

Об уральском периоде жизни и творчества Габдуллы Тукая, где он состоялся как публицист и поэт, рассказали гости, специально приехавшие на мероприятие из соседнего Казахстана. Среди них председатель Татарского культурного центра г. Уральска Флюра Миликеева, заслуженный работник культуры Республики Татарстан Эльмира Амирова, директор Дома-музея Габдуллы Тукая Марат Багаутдинов. Они рассказали об уральском периоде его жизни, отметив, что имя Тукая глубоко почитается не только в Татарстане, но и далеко за его пределами.





– Мы гордимся, что в нашем городе Уральске великий татарский поэт Габдулла Тукай прожил двенадцать лет. Также мы гордимся, что у нас есть музей его имени, который пользуется среди горожан и приезжающих гостей большой популярностью. Каждый год 26 апреля мы отмечаем день рождения поэта: возлагаем цветы, читаем его стихи на русском, на татарском, на казахском, на башкирском языках. Наши дети учат его стихи в школе, это очень много значит для всех нас, – отметила в своем выступлении Эльмира Амирова.

Подробно о деятельности музея рассказал его директор Марат Багаутдинов.

– В конце XIX – начале XX века Уральск считался центром образования для мусульман. В трех медресе города преподавали эрудированные, грамотные педагоги. Учиться у них приезжали из близлежащих городов – Самары, Саратова, Оренбурга, Астрахани и даже из отдаленной Казани. Наш музей – единственный дом, стены которого помнят Тукая. В этот дом к своему учителю, мулле Мутыгуллы Тухватуллину, Тукай приходил на протяжении двенадцати лет. Поэтому мы и взяли его под наш музей. Уже тогда это был центр культуры, центр знания. Здесь издавалась газета на татарском языке, здесь собралась первая татарская театральная труппа. Тукай был не только певцом нашего народа, но еще и переводчиком, благодаря которому мусульманский мир узнавал о татарах, – рассказал директор музея.

О последних годах жизни поэта и казанском докторе Григории Андреевиче Клячкине, в частной больнице которого умер Тукай, с лекцией выступила доцент Казанской государственной медицинской академии Марина Подольская. Она же представила участникам мероприятия внучку доктора Клячкина – профессора, кандидата педагогических наук Наталью Клячкину, которая живет и работает в Самаре и стала инициатором проведения данной презентации.



Выступления гостей сменялись номерами в исполнении учащихся школы «Яктылык». Дети очень талантливо и эмоционально читали стихи великого поэта, танцевали, после чего вместе со зрителями исполнили негласный гимн всех татар на стихи Тукая «Туган тел».

Завершилось мероприятие вручением трехтомных изданий школе «Яктылык» областной научной библиотеке, региональному духовному управлению мусульман Самарской области, Дому-музею Габдуллы Тукая в Уральске и, конечно же, чаепитием.









*«Визитная карточка» Татарстана – коллектив Государственного ансамбля песни и танца Республики Татарстан 18 мая в ДК «Металлург» представил самарцам яркую и красочную концертную программу «По следам Булгарии», посвященную 1100-летию принятия ислама Волжской Булгарией.*

*Данияр Сайфиев*

# ПРОСЛАВЛЕННЫЙ АНСАМБЛЬ НА САМАРСКОЙ ЗЕМЛЕ

На протяжении более чем двух часов самарские зрители могли насладиться настоящими шедеврами татарской культуры, номерами с большой историей с глубокими фольклорными корнями. В исполнении оркестра и хора ансамбля звучали задушевные народные татарские мелодии и песни, полные теплоты, сочные жанровые татарские танцы. А во втором отделении концерта самарцам был представленный музыкально-хореографический спектакль «Туй», основанный на фольклорно-этнографических материалах казанских и сибирских татар конца XIX – начала XX века. У зрителей была уникальная возможность окунуться в историю и увидеть традиционную татарскую свадьбу. Для постановки этого спектакля была проведена большая работа с архивами, документами, чтобы как можно достовернее показать сценический вариант свадьбы казанских и сибирских татар в прошлом веке.

Напомним, что гастрольный тур уникального татарского коллектива проходил по городам Астрахани,







Волгограду и Самаре в рамках федеральной программы «Мы – Россия», включенной во всероссийский гастрольно-концертный план Министерства культуры РФ.

На протяжении многих лет Государственный ансамбль песни и танца Республики Татарстан является самым известным коллективом, в котором исконные национальные традиции татарского народа, его музыкальная, танцевальная культура и прикладное искусство сохранены на самом высоком профессиональном уровне. Примечателен факт, что в этом году коллектив отметит свое 85-летие.

В завершение мероприятия к участникам коллектива со сцены ДК «Металлург» со словами благодарности обратились муфтий Талип хазрат Яруллин, президент СОТО «Туган тел» Ильяс Шакуров, директор культурно-исторического фонда «Булгарское наследие» Гузель Сагадатова и бессменный организатор концертов татарских исполнителей в Самаре Флорида Лукманова. Они отметили огромный вклад ансамбля в сохранение традиционных духовно-нравственных устоев татарского народа, популяризацию богатейшей татарской культуры и, конечно же, прославление Республики Татарстан в стране и мире.



# ИСЕМЕҢ ДӘ СИНЕҢ «ЯКТЫЛЫК» БИТ!

*2022 елның 17 маенда Самарның «Яктылык» татар мәктәбе үзенең 25 еллык юбилеен билгеләп үтте.*

*Эльмира СӘЙФУЛЛИНА*




Өлкәбездә генә түгел, гомумән, Россия күләмендә дә уникаль булып саналган мәктәбебезне күп регионнарда яхшы беләләр. Рәсми рәвештә мәктәп 1997 елда ачылган. Ә, чынлыкта, аның тарихы 33 ел элек башланган. 1989 елда Самар шәһәренең 12 санлы кичке мәктәбе директоры Хәридә Габделҗан кызы Дашкина тәкъдиме һәм яңа гына барлыкка килгән "Туган тел" татар җәмгыяте тырышлыгы белән якшәмбе татар мәктәбе оештырыла. 1993 елда шул ук бинада милли компонентлы беренче гомум белем бирү сыйныфы ачыла. Ә ике елдан соң кичке мәктәптән янәшәдә генә урнашкан ябык балалар бакчасы бинасына күченә. Ул вакытта укытучылар һәм «Туган тел» иҗтимагый оешмасы әгъзалары, өйдән-өйгә йөреп, татар балаларын җыйганнар.

Бүген исә мәктәпнең популярлыгы шулкадәр югары ки, биредә укырга теләүчеләргә сайлап алу конкурсы аша узарга туры килә. Проект буенча бина 400 укучыга исәпләнгән. Укучылар саны инде 600дән артып киткәнлектән, бүген алар ике сменада укый. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, «Яктылык» мәктәбе укучыларга иҗади сәләтләрен үстерергә, өстәмә белем алырга мөмкинлек бирә: мәктәптә төрле семинарлар, конференцияләр үткәрелә, Самар шәһәре һәм Татарстан Республикасы галимнәре татар теле укытучыларының квалификациясен үстерү курслары уздыралар. Шуңа да уңышлары күзгә күренерлек: 2013 елда «Яктылык» мәктәбе «Россиянең иң яхшы 100 мәктәбе» исемлегенә керде, 2015 елда Самар шәһәр округының «Актив гражданин мәктәбе» номинациясендә иң яхшы мәктәп дип танылды, 2021 елда мәгариф оешмалары арасында этномәдәни белем бирү эшен оештыру буенча Бөтенроссия конкурсында җиңде. Шулай ук «Мирас» этнографик музее һәм «Йолдыз» халык бию театры мәктәпнең аерым горурлыгы булып торалар...

"Яктылык"ның 25нче туган көне «Заря» Мәдәният сараенда узды. Фойеда Марк Коган





җитәкчелегендәге «Самар губернасы виртуозлары» тынлы оркестры татар көйләре уйнап тора. «Яктылык»ны туган көне белән котларга бик күп мөхтәрәм кунаклар килгәннәр: Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзалия Закирова, Самар шәһәре администрациясенең мәгариф департаменты җитәкчесе Илья Осипов, Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгының төбәкара хезмәттәшлек секторы мөдире Әлфия Әхәтова һәм Гөлия Мусина, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары Илгиз Халиков, Казан Федераль университеты каршындагы 2нче санлы татар гимназиясе директоры Рамил Гайнуллин, Самар өлкәсе мөфтие Талип хәзрәт Яруллин, Самар өлкәсенең милли оешмалары җитәкчеләре һәм ата-аналар.

Котлауларны шәһәр Думасы рәисе Алексей Дегтев башлап җибәрде. Ул мәктәпкә бүләкләр тапшырды һәм әлеге уку йортына үсәргә генә түгел, киңәергә дә вакыт җитүен билгеләп үтте. Алексей Петрович сүзләренә караганда, “Яктылык”ка бүлеп бирелгән 12 санлы кичке мәктәп корпусын төзекләндерү буенча проект-смета эшләре инде тәмамланып килә. Ул балаларга әхлакый тәрбия бирү эшендә катнашкан мөфтиебез Талип хәзрәт Яруллинны «Патриотик тәрбия өчен» Мактау билгесе белән бүләкләде.

- «Яктылык» - бик үзенчәлекле мәктәп. Бирердәге укучылар башкалардан тәрбияле булулары белән аерылып торалар. Аны тәмамлаучылар өлкә икътисадының төрле өлкәләрендә уңышлы эшлиләр. Араларында табиблар да, укытучылар да, галимнәр дә, танылган спортчылар да, уңышлы җитәкчеләр дә бар. Иң мөһиме, аларның барысы да чын патриотлар булып тәрбияләнгән, Ватанга, милләтенә һәм мәдәниятенә карата мәхәббәт орлыклары күңелләренә салынган. Бу әхлакый традицияләр киләчәктә дә саклаyнып, дип ышанам. Аллаһы Тәгалә укучыларыбызның уңышларын күрергә насыйп итсен, - дип теләде Талип хәзрәт.

Чарага «Яктылык» татар мәктәбенең беренче директоры - мәгариф отличнигы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган мәгариф хезмәткәре Хәридә апа Дашкина да килгән иде. Дулкынланудан, шатлыктан ташып чыккан хисләре, күз яшьләре аша ул укытучыларга һәм мәктәпнең хәзерге директоры Радик Газизовка рәхмәт сүзләрен җиткерде:

«Мин «Яктылык» мәктәбенең алга таба да үсәчәгенә ышанам, анда укырга теләүчеләр тагын да күбрәк булачак. Өлкә хөкүмәте дә мәктәбебезгә ярдәм итәр, дип өметләнәм. Барыгызны да яратам, хөрмәт итәм, хәтерлим, беләм һәм бик сагынам».

Бу көнне бик күп матур теләкләр һәм ихлас котлау сүзләре яңгырады. Самар шәһәр округы башлыгы урынбасары, Самар шәһәре администрациясенең мәгариф департаменты җитәкчесе Илья Осипов мәктәпкә департамент исеменнән акча сертификаты тапшырды һәм мәгариф үсешенә керткән өлеше өчен Радик Газизовны - Мактау грамотасы белән, ә укытучыларны Рәхмәт хатлары белән бүләкләде. Татарстан кунаклары да Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән укытучыларга - югары исемнәр һәм бүләкләр, ә мәктәпкә Республика Президенты Рөстәм Миңнехановтан 1 миллион сум акча тапшырдылар. Мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзалия Закирова: «Без күптән инде «Яктылык»ны үзебезнең мәктәп, дип саныйбыз, аның тормышы белән бик кызыксынабыз, ә уңышлары белән горурланабыз. Киләчәктә сезгә зурдан-зур уңышлар телибез. Алга! Бергә булыйк!» - дип сәламләде юбилярны.

«Яктылык»лылар да кунаклар өчен бик күркәм концерт әзерләгәннәр иде. Әлфия Сөләйманова, Асия Сәйфетдинова һәм Вәсимә Фәрдиеваның кызыклы идеялары, хореографлар Рәшит Гыйззәтуллин һәм Алия Сурина куйган биюләр, вокал укытучысы Алинә Шәмсетдинова әзерләгән җыр номерлары, укучылар Алия Гыйматдинова, Равил Вахитов, Әмир Кантеев, Рушан Йосыпов һәм Илнур Сөләйманов җыеп монтажлаган видеосюжетлар, концертны алып барган Әлсинә Дәүләтбаева тырышлыгы нәтиҗәсендә концерт күпкырлы һәм масштаблы булып узды. Тамашачылар залында утырган хореография кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты Юлия Кивенко бөтен номерларның да югары дәрәҗәдә әзерләнүе, һәр чыгышта милли гореф-гадәтләр чагылуы турында:

«Искиткеч биюләр һәм җырлар. Тел-теш тидерерлек бер генә нәрсә дә юк, афәрин!» - диде. Габдулла Тукайның «И туган тел»ен һәм «Яктылык» мәктәбе гимнын зал аягүрә басып җырлаганнан соң, бәйрәм сәхнәсе Татарстанның «Казан егетләре» төркеменә тапшырылды.

Самар татарларын берләштерүче, гореф-гадәтләребезне саклаучы, яшь буынга нур һәм җылылык өләшүче учак булып янган «Яктылык» мәктәбе озак еллар яшәр, дип ышанып калабыз.

# Роберт Миңнуллин: “...Язмышыбыз үзебездән тора, татарларым!”

*Анам теле – телләр теле,*
*Милләтемнең бердәнбере.*
*Син булганга – без дә исән,*
*Син булганга - без дә тере.*
***Фәнис Яруллин.***

***Эльмира Шәвәлиева.***
*“Бердәмлек”*

Самарның «Яктылык» татар мәктәбе үзенең 25нче туган көнен бәйрәм итә. 16 майда “Заря” Мәдәният сарае сәхнәсендә бәйрәмнең тантаналы өлеше гөрләп үткән булса, 17 майда Самар өлкәсенең “Профессиональ белем үстерү институты” дәүләт автоном учреждениесе бинасында “Күпмилләтле шәһәрдә туган телебезне саклау һәм үстерү” дип аталган региональ фәнни-практик конференция үткәрелде. Әлеге чарада Казан кунаклары - Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары Илгиз Халиков, Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгының төбәкара бүлек җитәкчесе Гөлия Мусина, Казан Федераль университеты укытучысы Кадрия Фәтхуллова, Казанның 2 санлы гимназиясе директоры Рамил Гайнуллин, “Яктылык” мәктәбе укытучылары һәм директоры Радик Газизов, мөфти Талип хәзрәт Яруллин, Самар шәһәренең татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Ленар Сабиров, “Бердәмлек” газетасының баш мөхәррире Эльмира Шәвәлиева катнаштылар.

Учреждение җитәкчесе Владимир Александрович Пылев институт буйлап экскурсия тәкъдим иткәч, кунаклар шатланышып риза булдылар. Чөнки без җыелган бүлмәнең диварларына, өстәл-урындыкларына карап кына да элеккеге СИПКРО бинасына яхшы ук ремонт ясалганын күреп куандык. Коворкингта – педагогларның үзара иркен аралашу бүлмәсендә, кунакларның игътибарын иң зур телевизордан да зуррак экран һәм электр чыбыклары, розеткалары күренеп торган тартма җәлеп итте. Бу экран күпфункцияле булып чыкты – ул телевизор да, компьютер да, киноэкран да, элемтә чарасы да икән. Ә тартмада, бик астында, унбишләп ноутбук саклана. Дәресләр вакытында аларны квалификацияләрен үстерергә килгән педагогларга тараталар. Без, экскурсиячеләр, тагын берничә шундый әйбәтләп ремонтланган бүлмәләрне үткәч, зур гына залга килеп кердек. Лекторийда иллеләп балалар бакчалары тәрбиячеләре бер - кулларындагы ноутбукларга, бер - зур экранга карап, нидер үзләштереп утыралар иде. Экскурсовод мондый укулар биредә даими алып барыла, дип белдерде. Ә фойеда бу көнне алар өчен диңгезче көненә багышланган искиткеч бай күргәзмә урнаштырылган иде. Анда балаларның вак моторикасын үстерү өчен төрле уеннар, диңгезче профессиясенә кагылышлы уенчык әйберләр, киемнәр, кораблар, матрос сыннары һәм хәтта диңгез төеннәре төрләре дә урнаштырылган иде. Нинди профессиональ бәйрәм булуына карап, бу экспозицияләр көн саен диярлек алмашынып тора. «Мәсәлән, иртәгә музейлар көненә багышланган күргәзмә урнаштырачакбыз», - дип сөйләде экскурсоводыбыз.



Бәлки, Самар өлкәсенең яңартылган “Профессиональ белем үстерү институты”на сокланып, темадан ераграк та киткәнмендер. Тик Казан кунакларында да бу учреждениенең цифралаштырыл-



ган эшчәнлеге зур кызыксыну уятты һәм Татарстанда да бу хәтле үзәкләрнең сирәк нәрсә булуы турында әйтеп үтелде.

Конференциябез дә шундый бүлмәләрнең берсендә узды. Теге, телевизордан да зуррак экран аша, элемтәгә Самар өлкәсенең мәгариф министры Виктор Акопян, Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры Илсур Хәдиуллин чыктылар һәм, мәктәпне юбилее белән котлап, конференциядә катнашучыларга уңышлар теләделәр. Виктор Акопян өлкәнең 34 мәктәбендә туган телләр укытыла, дип белдерде. Кызганычка, шуларның җидесе генә татар теле.

Кереш сүзендә Радик Газизов мәктәп эшчәнлеге белән таныштырып үтте. Ата-аналарның, мәктәпнең һәм мәчетнең тәрбия эшчәнлеге нәтиҗәсендә акыллы һәм тәртипле, сәләтле һәм тыңлаучан укучылар олы тормыш юлына баса, дип белдерде ул. 25 ел эчендә педагогика институтын тәмамлаган 8 баланың мәктәпкә эшкә кайтуы да - «Яктылык» өчен зур дәрәҗә.

Соңында Радик Рифкатович мәктәп юбилеена 1 миллион сум акча җибәргән Татарстан хөкүмәтенә рәхмәтләрен белдерде һәм... тагын 1 миллион сумлык дәреслекләр сорады. Мондый "тыйнаклык"ка кунаклар елмаештылар һәм, мөмкинлек булгач та, дәреслекләр бүлеп биреләчәк, дип вәгъдә иттеләр.

Мөфти Талип хәзрәт Ярруллин "Яктылык" мәктәбенең башка мәктәпләр өчен үрнәк булуын белдерде. "Рухи байлык һәм милли үзенчәлек кулга-кул тотынышып баралар, - диде ул. - Гореф-гадәтләрнең барысы да дин үзенчәлекләреннән килә. Мәсәлән, ислам динендә ак сакаллы кешенең сүзе үтемле. Бу традиция бүген дә саклана. Олы кеше яшьләрнең хисчәнлеген тигезли, сабырлыкка өйрәтә. Шулай, буыннан буынга олыларны хөрмәтләү һәм сүзен тыңлау гадәте туа. Кем дә кем үзенең тамырларыннан аерыла икән, шуның киләчәге юк.

"Яктылык"та ислам культурасы дәресләре укытыла, һәм без ислам дине кыйммәтләрен бала күңеленә салырга тырышабыз", - дип сөйләде мөфти.







Педагогика фәннәре кандидаты, кафедра мөдире Анатолий Нуждинның чыгышы туган телләрне укыту актуальлегенә багышланган иде. Россия халыкларының күптеллелеге проблемасы беркая да китмәгән, соңгы елларда хөкүмәт тә, милләтләр дә туган телләрне югалта баруга игътибар итә башладылар, мәктәпләрдә туган телләрне укытуны торгызу турында сүз алып баралар, дип белдерде. Россиядә кулланышта 300ләп телләр бар. Шуларның 89сы мәктәпләрдә укытыла. Федераль канунда "Туган телләрне укыту өчен шартлар булдырылырга тиеш", дип язылган. Ләкин, кызганычка, өлкә мәктәпләрендә "туган тел" төшенчәсен дөрес кулланмыйлар. Укытучылар юк, ата-аналар теләге юк дигән сылтама белән, рус телен туган тел итеп алалар да рус телен укыталар. Ә милли телләр торышы ничек бар, шулай кала бирә - татар, чуваш, мордва һәм башка телләр укытылмый. Ата-аналар һәм укытучылар шуны аңларга тиеш, туган тел белән бергә бала күңеленә милли мәдәният тә сеңә. Туган телен бала бишектән үк үзләштерә башларга тиеш. Мәктәп, гаилә, дин, җәмгыять бергәләшеп эшләгәндә генә, милли телләрне һәм мәдәниятләр төрлелеген саклап кала алабыз, дип сөйләде.

Казан Федераль университеты педагогы Кадрия Фәтхуллова да, Анатолий Вячеслав улы башлаган теманы дәвам итеп, һәр милли тел кешелек дөньясы тарихын саклый, дип белдерде. Шуңа күрә милли телләрне саклауга бөтен игътибарыбызны юнәлтергә, үстерергә, бөтен дөньяга таратырга тиешбез, дип дәвам итте чыгышын.

– Татар теле Татарстанда гына түгел, бөтен дөньяда да киң таралган булырга тиеш. Моның өчен онлайн курслар оештыру юлы белән китәргә кирәк. Һәм бүгенге көндә иң мөһиме - телебезне, мәдәниятебезне, түкми-чәчми, яшь буын кешеләренә тапшырып калдыру. Чөнки телне яклау милләтне яклау белән тиң. Барыбыз да аңлыйдыр – тел булмаса, халык та булмаячак. Балалар мәктәпләрдә әдәби телне үзләштерә алмыйлар икән, аның киләчәге дә булмаячак. Һәр татар теле укытучысы нәкъ шул проблемага аеруча зур игътибар бирергә тиеш: ата-аналарга һәм балаларга туган телебезне саклау мөһимлеген аңлату һәм

татар булуы белән горурлану хисе тәрбияләү. Сабый бала бишектә чакта ук татар җырлары, әкиятләре тыңлап үсә икән, мәктәптә танылган язучыларыбызның әсәрләрен укый икән, ирексездән татар рухын күңеленә сеңдерә һәм нәтиҗәдә чын татар кешесе булып үсә.

Кичә без "Яктылык" мәктәбенең юбилеенда никадәр талантлы татар балаларын күрдек! Бииләр, җырлыйлар, милли киемнәрне күреп-белеп, хәләл ашлар ашап үсәләр. Бу инде - татар телен саклау хезмәтенә кертелгән конкрет эшләр. Моның өчен бик зур рәхмәт Сезгә, Радик Рифкатович!

2022 – 2023 уку елларында без яңартылган дәүләт стандартлары буенча эшли башлаячакбыз. Бу эшнең мөһимлеген аңлап, Татарстанның мәгариф министрлыгы татар теле һәм әдәбияты буенча яңа программалар эшләп



чыгарды һәм үз сайтына куйды. Бүгенге көндә бу программалар Федераль экспертиза узалар. Һәр укытучы алар белән таныша алачак.

Самар шәһәре татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Ленар Сабиров үзенең чыгышын Коръән аяте белән башлап җибәрде: "Мин сезне халыклар һәм ырулар итеп яралттым, бер-берегезне өйрәнү өчен". Димәк, без үз ыруларыбызны сакларга һәм башка милләт халыкларының көнкүрешен дә өйрәнергә тиеш. Минем балачак Нурлат шәһәрендә, татарлар арасында үтте. Ә хәзерге балалар мегаполиста, рус мохитында үсәләр, туган телне кирәксенмиләр, чөнки аларның тормышында ул юк диярлек. "Яктылык"та укучыларның ата-аналары үзләре дә күп очракта туган телләрен белмиләр. Бәлки, шуңадыр балаларын татар мәктәбенә китерәләр. Ләкин без татар теле мохиты, дустанә атмосфера, җыр-бию һәм спорт белән генә канәгатьләнә алмыйбыз. Безнең балаларга төпле белем дә кирәк. Моның өчен мәктәптә сыйфатлы милли һәм гомумбелем бирү өчен бөтен шартларны да булдыру ләзим.

Татарстан регионнарда яшәүче татар балаларының җәйге ялын оештырып кына калмый, ике-өч атна эчендә балаларның татар телен камилләштерү, яшьләрне берләштерү җаен да таба. Бу турыда Татарстанның "Сәләт" лагеры җитәкчеләренең берсе булган Диләрә Якупова сөйләде.

Казанның Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2 санлы гимназия директоры Рамил Гайнуллин татар теле укытучылары өчен бик тә саллы киңәшләр бирде, яңа технологияләр белән таныштырды, үзләре төшереп интернетка элгән видеодәресләрдән файдалана алулары турында әйтте...

...Читтән караганда, татар теле белгечләрен тыңлаганда, "Багдадта бар да тыныч, бар да яхшы". Татар телен өйрәнергә бөтен мөмкинлекләр дә бар, дип әйтергә дә була. Тик нигә соң бу төз система һаман бер урында таптана? Таптана гына түгел, артка тәгәри. Нигә татар авылларындагы балалар бакчаларында рус телендә сөйләшәләр, ник мәктәпләрдәге бөтен чаралар да рус телендә уздырыла, ник татар теле дәрес булып түгел, факультатив буларак укытыла? Бу турыда педагоглардан сораганым да бар. Аларның җавабы бер: өстән төшерелгән фәрман буенча эшлибез.

Бу сорауны конференциядә катнашкан абруйлы мәгариф белгечләренә бирмичә булдыра алмадым, әлбәттә. Ни гаҗәп, татар телендә укыту һәм чаралар уздыру өчен ата-аналар теләге һәм бакча мөдире яисә мәктәп директоры ихтыяры булырга тиеш икән. Ата-аналар гариза язган очракта җитәкче аларга татар телендә уку, чаралар уздыру шартларын булдырырга, татар теле укытучылары белән тәэмин итәргә тиеш. Илгиз Халиков әйтүенчә, директорның абруе һәм теләге булган очракта, бөтен предметларны да татар телендә укытырга да мөмкин.

Әйе, бу турыда без үзебезнең газетада язганыбыз да бар. Тик йөк урыныннан кузгалмый гына бит. Ә өлкәдә татар теле буенча хәл бик тә хөрти. Бигрәк тә әдәби татар теле нык аксый. Миңа, татар газетасы редакторына, соңгы елларда тәрҗемәче булып эшләргә туры килә. Күп кенә язмалар газетага рус телендә килә. Ә татар газетасын рус телендә бастырып чыгара башларга күңелебез бармый. Шуңа күрә рус телендә язылган язмаларны татарчага тәрҗемә итеп гомерем уза.

...Татар мәктәбебез дә шәп, конференция дә уңышлы үтте, тиешле программалар һәм әсбаплар да бар... Тик балаларыбыз гына Казан университетларының татар теле бүлекләренә укырга бармыйлар. Барсалар да, кайтмыйлар, Татарстанда калу ягын карыйлар. Бу турыда Гөлия Мусина да ачынып сөйләде: "Без, Казан Федераль университетына керү өчен, документларын җибәргән абитуриентларга дип урыннар саклап торабыз, башкаларны алмыйбыз. Ә күбесе соңгы көнне, башка югары уку йортын сайлап, я Мәскәүгә, я Питерга китеп баралар...

Менә шундый мәсьәлә, татарларым.

# БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧЛАР

**_Самарның “Яктылык” мәктәбенә быел 25 ел тулды. Әмма, шуны әйтеп үтәргә кирәк, әлеге уку йортының тарихы чирек гасыр белән генә чикләнми, аның чишмә башы 1989 елга барып тоташа._**

**_Миләүшә Газимова._**



*Унынчы сыйныфта укыганда. Мәктәп мөдире Хәридә Дашкина һәм татар теле укытучысы Рушания Минһаҗева белән.*

Татар теле һәм әдәбияты укытылган, милли мәдәниятебез, гореф-гадәтләребез, тарихыбыз өйрәтелгән “Яктылык” мәктәбенә мәгариф отличнигы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган мәгариф хезмәткәре Хәридә ханым Дашкина нигез салып, аны күп еллар җитәкләде.

Нәкъ ул, үз вакытында Самарның 12 санлы кичке мәктәбе директоры, өлкәбезнең милли хәрәкәте җитәкчеләре һәм активистлары янына килеп, шәһәребездә татар телен укыту, мәктәп булдыру турында сүз кузгата. Аның бу фикерен милли әйдаманнарыбыз ике куллап каршы алалар, һәм барысы бергә, җиң сызганып, эшкә керешәләр.

Башта 12 санлы кичке мәктәптә татар якшәмбе мәктәбе булдырыла. Ул Самар татарларының милли учагына әверелә. Бирегә балалар да, урта һәм өлкән яшьтәге кешеләр дә йөри. Татар теле һәм әдәбиятын, төрек телен, гарәп графикасын үзләштерәләр, бер-берсе белән аралашалар, чәй эчүләр оештыралар.

Татар милли хәрәкәте активистлары, шушында очрашып, эшлекле сөйләшүләр алып баралар.

Ә 1992 елда 12нче мәктәптә беренче татар сыйныфы булдырыла.

1997 елда исә әлеге уку йорты янәшәдә урнашкан балалар бакчасы бинасына күчерелә, һәм “Яктылык” мәктәбе барлыкка килә.

Шулай итеп, 80нче еллар ахырында Самарда милли мәгарифне торгызу буенча эшләрне башлап җибәргәч, 12 санлы кичке мәктәпкә, беренче булып, унынчы сыйныфка балалар җыялар.

Унбер кыз һәм бер малай, тугыз ел укыган рус мәктәпләреннән әлеге уку йортына күчеп, урта белем алуны татар классында дәвам итәләр.

Менә алар - беренче юл салучылар, 12нче мәктәптәге беренче татар сыйныфын тәмамлаучылар:

***Ләйсән Курмакаева,***
***Алсу Әхмәтова,***
***Равил Сиражетдинов,***
***Гөлнара Ногманова,***
***Гүзәл Ногманова,***
***Миннур Мостафина,***
***Гөлнара Хәйбуллова,***
***Зөлфия Агаева,***
***Гөлнара Әксәнова,***
***Зөлфирә Таҗиева,***
***Светлана Нуриева,***
***Алия Шахмәмәтова.***

1994 елда унберенче сыйныфны бетергән шушы уникe укучыга Металлурглар паркында үткән Сабан туе сәхнәсендә тантаналы рәвештә таныклыклар тапшыралар. Шул вакытта Хәридә ханым Дашкина бу балаларны назлы итеп беренче карлыгачлар дип атый. Һәм аның бу сүзләре канатлы сүзләргә әйләнә. Яшьләргә әлеге гыйбарә шулкадәр ошый ки, бүгенге көндә дә алар үзләрен беренче карлыгачлар, дип атап йөриләр. Вайберда булдырган сыйныфташлар төркеменә дә шундый исем биргәннәр икән.

“Күңелемне шатлыклы һәм шул ук вакытта бераз моңсу хисләр биләп алды. Шунысы сөенечле ки, бүген беренче карлыгачларыбызны зур тормышка очырып җибәрәбез. Икенче яктан, мәктәбебездә татар сыйныфларына юл ачкан балаларыбызны бик сагыначакбыз”, - дип чыгыш ясый ул чакта 12нче мәктәпнең мөдире, химия укытучысы Хәридә Дашкина.

Ике ел укучыларга, төп фәннәрдән тыш, татар теле һәм әдәбияты, татар халкы тарихы дәресләре буенча белем бирелә. Ә якшәмбе мәктәбендә, факультатив буларак, Минәхмәт әфәнде Сәгыйров аларга - гарәп графикасын, Төркия вәкилләре төрек телен өйрәтәләр.

Унынчы сыйныфта татар теле һәм әдәбиятын Рушания Минһаҗева укытса, унберенче класста бу дәресләрне Нурзидә Фәйзуллина алып бара.

Хезмәт юлын 12 санлы кичке мәктәптә башлаган Нурзидә ханым - “Яктылык”та күп еллар эшләп, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, тәрбия һәм белем бирү өлкәсендә Рос-

С июня по сентябрь 1921 года Миргазиян был старшим помощником начальника штаба по оперативной части Экспедиционного корпуса 5-й армии, руководившего операциями по ликвидации войск барона Р.Ф. Унгерна, перешедших советскую границу в конце мая. 1–13 июня в боях под г. Троицкосавском (с 1934 года – г. Кяхта) Унгерн был разбит и отступил в Монголию. Для преследования его и сформировали Экспедиционный корпус 5-й армии. 6 июля его части вступили в Ургу (ныне – г. Улан-Батор), но барон оттуда успел уйти



*Азиатская конная дивизия Унгерна на марше*



*Арестованный барон Р.Ф. Унгерн*

и в середине месяца повторил попытку прорыва в Россию. Однако и она, несмотря на ряд побед, кончилась для него через месяц очередным бегством в Монголию, где его свои же и сдали. 14 сентября Экспедиционный корпус, выполнивший поставленные задачи, был расформирован.

После этого Крымова отправили на учебу в Военную академию РККА, где он окончил основной факультет в 1924 году. Отметим при этом то, что Миргазиян выдержал чистку этого учебного заведения, проведенную летом 1922 года. А проверка была нешуточной – по ее итогам исключили 52% проверенных комиссией или 48% всех слушателей. Более того, наш герой продолжил обучение и в 1924–1926 годах был слушателем восточного факультета этой академии, ставшей носить имя М.В. Фрунзе. Тогда было установлено, что на данный факультет должны поступать только выпускники Военной академии или равного с ней военно-учебного заведения.

Освоивший английский и турецкий языки Крымов следующие пять лет находился в Турции и выполнял спецзадание в качестве сотрудника аппарата военного атташе при полпредстве СССР. Поведать что-либо о его нелегальной деятельности в этой стране мы не в силах, но можем привести интересную цитату из воспоминаний о 20-х годах бывшего заместителя советского торгпреда в Турецкой Республике, невозвращенца И. Ибрагимова: «В Турции действует целый штаб, очень хорошо организованный, из бывших офицеров – северных татар, ставших коммунистами и окончивших спецкурсы при Красном Генштабе, числящихся официально на должностях драгоманов (переводчиков) разных рангов при полпредствах и в консульствах… Результатом их работы очень довольны были всегда в Центре, и в Генеральном штабе вполне удовлетворены… Их в конце концов отозвали, но с назначением на высокие военные должности в штабе



*Группа слушателей восточного факультета Военной академии им. Фрунзе*



*На занятиях в Военной академии им. Фрунзе, 1934 год*



*Подполковник М.Г. Крымов, начало 30-х годов*



*Слушатели основного факультета Военной академии им. Фрунзе, 1928 год*

Закавказской Армии, в частях, расположенных на турецкой границе, фактически на ту же работу, только с резиденцией на территории СССР».

Именно так получилось с нашим героем, который, вернувшись из-за рубежа, служил в штабе Кавказской Краснознаменной армии, поначалу помощником начальника, а затем и начальником разведотдела, занимавшегося Турцией и Персией. В конце 1932-го его вновь отправили учиться – теперь уже на оперативный факультет Военной академии имени М.В. Фрунзе, который открылся годом ранее для подготовки широко образованных оперативных работников для высших штабов.

По завершении полугодовой учебы Миргазиян эфенди два года служил начальником штаба 1-й Казанской стрелковой дивизии имени ЦИК Татарской АССР и неоднократно бывал временно исполняющим обязанности командира этого соединения. В феврале 1935 года Крымова назначили помощником начальника штаба 19-го стрелкового корпуса. Однако, прибыв к месту службы, он получил новое направление – в альма-матер – руководить кафедрой общей тактики. В декабре того же года ему присвоили звание полковника.

Казалось бы, всё идет хорошо, по нарастающей. Полковник Крымов возглавил кафедру, ему есть что рассказать слушателям из личного опыта и накопленного багажа знаний. Но пришло время очередной чистки академии, и на сей раз вспомнили об эсеровской молодости Миргазияна Галиулловича и о том, что он сын муллы. «Хороший был парень, жаль, что эсер» – это сказано не именно о нашем герое, но фраза характерна для того времени. В итоге с 1 января 1937 года полковника понизили в должности до руководителя кабинета кафедры тактики первого курса, а затем – до ассистента. Осенью же следующего года его уволили из армии в запас по статье 43 «б» Положения о прохождении службы командным и начальствующим составом РККА – в аттестационном порядке по служебному несоответствию. Но до этого Крымову вручили медаль «XX лет

РККА», которая весьма ценилась в то время и была первой медалью в наградной системе СССР.

В начале 1939 года Миргазияна абый приняли на работу преподавателем военной кафедры Московского института стали им. И.В. Сталина. Одновременно он вел занятия по военной подготовке в школах Москворецкого района. В том же году его исключили из ВКП(б) в связи с троцкистскими взглядами и несообщением о расстреле отца. Маховик репрессий мог ударить по Крымову и сильнее, если бы его имя увязали с фамилией «японского шпиона» В.К. Блюхера или с бывшими начальниками героя статьи: председателем ЦМВК М.Х. Султан-Галиевым, обвиненным в создании «контрреволюционной организации», и военно-морским атташе при полпредстве СССР в Турции А.А. Соболевым, который стал невозвращенцем.

Тем не менее Крымов не побоялся побороться за свое доброе имя. Он обратился в Наркомат обороны с просьбой о возвращении в ряды РККА и получил ответ центральной комиссии при Управлении по командному и начальствующему составу об оставлении его в запасе с изменением пункта статьи увольнения. Приказом НКО от 30 ноября 1939 года упомянутый пункт был изменен на 43 «а» – за невозможностью использования в связи с сокращением штатов или реорганизацией. Это позволило запаснику вернуться в армейский строй.

В октябре 1941 года он прибыл в созданный летом Высший военный гидрометеорологический институт Красной Армии (ВВГМИ КА) и был зачислен на должность старшего преподавателя общевойсковой тактики. В том же месяце институт отправили в г. Ленинабад Таджикской ССР (ныне – г. Ходжент), куда он добрался на излете осени. А в декабре на всех факультетах и отделениях ВВГМИ КА приступили к занятиям. Наступивший вскоре День Красной Армии стал памятным для Крымова, так как он – красногвардеец с 1917 года – снова принял военную присягу. Но накануне следующего учебного года его направили в распоряжение отдела кадров Среднеазиатского военного округа (САВО) «для прохождения дальнейшей службы».

Причину такого решения поясняют составленные на нашего героя характеристики, текст которых приводят казанские ученые Я.Я. Гришин и Д.Р. Шарафутдинов в книге «На службе Родине». В них отмечается, что полковник Крымов показал себя в институте грамотным и политически развитым командиром, который любит и знает свое дело как преподаватель и добился неплохих результатов в обучении слушателей. Вместе с тем, за недостаточную дисциплинированность в работе получил два взыскания от начальника института. С товарищами не общителен, грубоват к подчиненным, не смог сработаться с преподавательским составом, т. к. вместо терпеливой помощи и показа действовал окриком или нотациями. Скрытен и упрям, не признает свои ошибки. Мстителен и способен к очернению товарищей по работе, выставляя себя в выгодном свете, в силу чего создал вокруг себя нервную и недружелюбную обстановку. В конце этих документов сделан вывод о несоответствии Миргазияна Галиулловича занимаемой должности и целесообразности его использования в тыловых частях или в системе всеобуча.

А в САВО от него отказались из-за «невозможности использовать на равнозначащей должности». Тогда Крымова отправили в действующую армию. В начале октября 1942 года он приехал в Тамбов на должность заместителя командира 98-й стрелковой дивизии (2-го формирования), которую после сражений в районе Сталинграда вывели в Тамбовскую область, где до 6 декабря она укомплектовывалась личным составом. Боевые действия соединение возобновило 18 декабря, но через три месяца оно было отправлено на формирование в г. Сведловск Ворошиловградской области и 16 апреля 1943 года преобразовано в 86-ю гвардейскую стрелковую дивизию. Комдив подписал характеристику на своего зама, в которой подчеркнул, что его оторванность от полевых частей сказалось на руководстве Крымова обучением войск, и он потерял авторитет вследствие незнания боевого опыта частей.

Вот цитата из того документа, который опубликовали названные выше историки Казани: «Будучи в боевой обстановке, растерялся и в 4[-м] с[трелковом] п[олку] допустил личную панику, чем окончательно подорвал веру в себя. Будучи посылаем в части, всегда блуждал, поручения не только не выполнял, но их путал, чем усложнял положение в руководстве. Авторитетом не пользуется. В общении с подчиненными вызывает конфликт. Личная военная грамотность теоретическая есть, но не соразмеряет с обстановкой вследствие неумения ее учитывать. Вывод: занимаемой должности не соответствует. Оставить в дальнейшем нет возможности…»

М.Г. Крымова направили в распоряжение Военного Совета Южного фронта, который в апреле 1943 года решил использовать его на той же должности, но уже в 387-й стрелковой дивизии. Однако и здесь отзывы о нем не радуют. Уже через два месяца его начальник полковник Макерьев дает такую характеристику герою статьи: «Теоретически подготовлен очень хорошо, но в бою свои знания по своему укладу характера применить не может – в бою нерешителен, не инициативен, страдает излишней осторожностью. Физическое напряжение переносит с трудом. Целесообразнее использовать на преподавательской работе в военно-учебных заведениях». Тем не менее, когда вскоре Макерьев покинул дивизию, ее комдивом на следующий день стал Крымов. Возможно, в Военном Совете фронта решили, что военный «потенциал» нашего гвардии полковника перевесит трудности его характера и

вхождения в новую войну.

На этой должности он служил ровно два месяца, а затем Крымова в начале августа перебросили на командование 127-й дивизией (3-го формирования) Южного фронта. Она была обескровленной после июльских боев на Миус-фронте. Тем не менее дивизия показала свои лучшие качества при сражениях в Донбассе под руководством нашего героя. Так, 18 августа ее бойцы освободили Криницы и подошли к Саур-Могиле – кургану в Шахтерском районе, господствовавшему над местностью. Не случайно на его вершине располагался наблюдательный пункт 6-й армии вермахта.



*Штурм Саур-Могилы, 1943 год*

На склонах кургана были врыты в землю бронеколпаки с огневыми средствами, блиндажи и дзоты. Огневые позиции располагались в несколько ярусов. Для обороны использовались также огнеметные танки, самоходные артиллерийские установки «Фердинанд», орудия и минометы.

В штурме Саур-Могилы участвовали 96-я и 34-я гвардейские стрелковые дивизии, а левый фланг наступления составили части 127-й дивизии полковника Крымова. По воспоминаниям очевидцев, одно из самых страшных впечатлений тех дней у бойцов – как они ползли вверх, к дзотам, а немцы выбрасывали из амбразур гранаты. Вид их, катящихся сверху, ожидание, когда они разорвутся – у твоей ли головы, на спине ли, или на соседе – остался кошмаром у многих выживших участников тех боев. Для защиты от пуль и осколков залегшие на склонах красноармейцы использовали тела своих убитых товарищей.

30 августа высота 277,9 метра (Саур-Могила) была взята. Над немецкими войсками нависла угроза расчленения и окружения. «Командование группы «Юг» приказало поэтому, – признавался позже ее командующий Э. Манштейн в книге «Утерянные победы», – 31 августа отвести 6-ю армию на подготовленную тыловую позицию. Этим был сделан первый шаг к сдаче Донбасса».

А 127-я сд к 19 часам 1-го сентября уже вела бои в восточном и юго-восточном секторах г. Чистяково (с 1964 года – г. Торез). На следующий день город был освобожден войсками Южного фронта, и вскоре дивизии Крымова присвоили наименование «Чистяковская». За отличие она отмечена в приказе Верховного Главнокомандующего от 4 сентября 1943 года. Двумя неделями позже самого комдива представили к награждению орденом Красного Знамени.

В наградном листе отмечено, что его дивизия в боях за освобождение Донбасса, особенно при взятии Чистяково и штурме г. Горловки (она освободила его 4 сентября. – Прим. Р.Ш.) проявила высокую боевую стремительность к окружению и уничтожению противника. В сражениях за Горловку части дивизии нанесли противнику ощутимые потери и захватили большие трофеи. При его преследовании в дальнейшем 127-я сд продемонстрировала хорошую маневренность, а личный состав – сработанность и выносливость. Говорится также о личном мужестве и храбрости беспартийного М.Г. Крымова, его умении хорошо организовывать боевые действия своих частей и подразделений. Добавим, что в этом соединении Миргазияна эфенди снова приняли кандидатом в члены ВКП(б).

Но характер комдива по-прежнему давал о себе знать. Исследователь действий дивизии и пути своего отца-офицера в ее рядах А.П. Пискунов приводит выдержку из журнала боевых действий 55-го стрелкового корпуса (55-го ск) по поводу освобождения Горловки: «127-я стрелковая дивизия (полковник Крымов) должна была наступать с севера и выйти на северо-западную окраину. Товарищ Крымов самовольно нарушил боевые порядки, определенные приказом командира корпуса, вследствие чего дивизия не участвовала во взятии Горловки». Пискунов считает, что этот нонсенс есть проявление сложных взаимоотношений нашего героя с командиром корпуса генерал-майором П.Е. Ловягиным, который, похоже, не терпел строптивости, даже если она не выставлялась напоказ.

Дивизия Крымова, потерявшая с июня 67% личного состава и заметно ослабившая огневую вооруженность, продолжала двигаться вперед и освобождать населенные пункты. Так, 7 сентября ее воины взяли железнодорожную станцию и крупный населенный пункт Авдеевку, 18-го – села Юрковку и Жеребец. Войдя в состав 55-го корпуса, она почти постоянно находилась в его первом эшелоне, сражаясь днем и ночью.

Но 18 сентября в журнале боевых действий 55-го ск появилась запись такого содержания: командир корпуса приказал 127-й стрелковой дивизии ночными действиями усилить наступление. И далее практически дословно: «Командир 127-й сд Крымов отстранен комкором за бездеятельность от командования дивизией. Командовать дивизией временно допущен май-

ор Батенков». Обратите внимание, уважаемый читатель, что именно в этот день командование 5-й ударной армии представило полковника к награждению орденом. А Ловягин явно погорячился, ибо не в его власти снятие и назначение комдивов.

20 сентября было решено вывести 127-ю сд в резерв фронта. Бойцам досталась не только передышка и обучение, но и череда маршей-переходов. А через два месяца дивизию направили на 1-й Украинский фронт, где она приняла участие в Житомирско-Бердичевской операции. Немцы готовили рывок к Киеву, и на их пути оказался Радомышль – райцентр Житомирской области. Как раз в этих местах встали в оборону части под командованием полковника Крымова. В изодранном летнем обмундировании, грязными после долгих маршей – такими их увидел проверяющий из штаба армии. Вагоны с зимним обмундированием дивизии, полученным еще в октябре, удалось отыскать 7–8 декабря, а питание в 127-й дивизии вошло в норму только на пару-тройку дней ранее.

Поэтому в декабре уже прославившегося комдива отстранили от должности «за плохое руководство дивизией, за отсутствие заботы о быте и питании личного состава» и зачислили в распоряжение Военного Совета 1-го Украинского фронта.

Новое место службы нашлось довольно быстро. 18 января 1944 года Крымов возглавил 38-ю стрелковую дивизию (3-го формирования), командир которой 15 января был арестован, так как, находясь в нетрезвом состоянии «в период отхода своих частей, застрелил без необходимости несколько солдат и офицеров». В конце месяца он был приговорен к расстрелу, и приговор был приведен в исполнение. В феврале Крымов получил пополнение в 2392 чел., затем выстраивал оборонительные позиции соединения, совершал с ним марши, подчиняясь разным корпусам. А уже с 20 апреля он стал заместителем командира по строевой части 232-й стрелковой Сумско-Киевской Краснознаменной ордена Богдана Хмельницкого и Суворова дивизии (2-й Украинский фронт).

В те дни это соединение (2-го формирования) после тяжелых боев по расширению плацдарма перешло к обороне, в которой пребывало до середины августа 1944 года. А что касается Крымова, то не прошло и месяца его нахождения в дивизии, как ее командир дал оценку своему заму: «Безынициативен, в работе вял и постоянно ждет приказа. Приказы выполняет вяло, всегда с некоторымиирониями. К подчиненным относится безразлично, не требовательный. Характер очень слабый, но большого мнения о себе. Вывод: может быть использован на преподавательской работе или же на административной работе». Но командование 40-й армии посчитало, что наш полковник «должности заместителя командира дивизии соответствует».



*Бойцы 38-й стрелковой дивизии*

Прошло еще два месяца, и тот же комдив пишет, что если «по прибытии в дивизию полковник Крымов недостаточно проявил себя как заместитель командира дивизии в связи с его переживаниями снятия с командования дивизией, то в настоящее время все недостатки полковник Крымов устранил и к работе относится добросовестно, к подчиненным требователен и настойчив, – характер недостаточно твердый. В тактической обстановке разбирается хорошо, тактичен, грамотен, решения принимает правильно, дисциплинирован, исполнителен, в общении с подчиненными культурен. Занимаемой должности соответствует».

В связи с чем так разнятся эти документы? То ли комдив славной дивизии – Герой Советского Союза в генеральском звании – поторопился с выводами, то ли принял точку зрения начальства. А 9 октября того же года он подписал наградной лист на Крымова, представив его к ордену Красного Знамени. В изложении заслуг отмечено большое внимание гвардии полковника к повышению боевой подготовки и учебе частей в период обороны и выучке их к наступательным боям. Поэтому при прорыве вражеского укрепрайона 19–20 августа части дивизии умело выполнили свою задачу. А в период наступления в Карпатах Крымов, находясь в передовых отрядах соединения, правильно оценивал обстановку и принимал умелые решения. Причем при прорыве



*Группа командиров 232-й стрелковой дивизии, 1944 год.*
*М.Г. Крымов – 4-й слева в нижнем ряду*

укрепрайона у румынского села Содомень он выполнил указание комдива и лично помог командиру 1-го батальона 794-го стрелкового полка в организации этого успеха.

С 15 по 25 октября 232-я сд приняла участие в освобождении румынского города Сату-Маре, затем вступила в бои за венгерский город Ньиредьхаза. Ее подразделения имели отношение и к взятию г. Мишкольца. А в декабре соединение перешло границу Венгрии с Чехословакией и вступило в полосу упорнейших сражений, позволивших ему за месяц с лишним пройти менее 100 км. Но герой статьи эти километры не промерил, так как в декабре был направлен в 206-ю стрелковую Корсуньскую Краснознаменную орденов Суворова и Кутузова дивизию заместителем командира по строевой части (2-й Украинский фронт).

Здесь ему дали блестящую характеристику по всем позициям и в феврале 1945 года представили к награждению орденом Ленина. Со своей последней дивизией Миргазиян абый продвигался с зимними боями по Венгрии и Словакии. Затем весь февраль соединение находилось южнее Будапешта и, не имея соприкосновения с противником, занималось боевой и политической подготовкой, за организацию которой отвечали Крымов и политотдел. 6 марта передышка окончилась, и дивизия вновь вступила в сражения на территории Венгрии, выйдя в конце месяца на границу этой страны с Австрией. Поэтому в апреле 1945 года 206-я сд вела боевее действия на родине Моцарта, Штрауса и Шуберта, вступая в населенные пункты федеральной земле Штирия. Так, 8 апреля красноармейцы взяли г. Феринг.

А через неделю в журнал боевых действий дивизии была внесена вот эта запись: «За 15.4.45 г. противнику нанесены потери: уничтожено около 75 солдат и офицеров, взято в плен 7 чел. Потери дивизии за 15.4.45 г.: убито – 27, ранено – 77. В числе убитых


Противник подразделениями 5 ТД СС "ВИКИНГ", I ТД и 6-ном " ФОЛЬКСШТУРМ"продолжал оказыватьупорное огневое сопротивление на рубеже УЕБЕРСБАХ, ЗЕХАУ.

В течение суток вел сильный руж.пулм. огонь и производилarт. мин. налеты по боевым порядкам частей дивизии .

За 15.4.45 г. противнику нанесены потери : уничтожено до 75 солдат и офицеров, взято в плен 7 чел.

Потери дивизии за 15.4.45 г. убито – 27 ранено 77.
В числе убитых Зам. командира дивизии по строевой части ПОЛКОВНИК КРЫМОВ, Командир 748 сп. ПОДПОЛКОВНИК – ШМОНИН,.

*Часть страницы журнала боевых действий 206-й стрелковой дивизии*

зам. командира дивизии по строевой части полковник Крымов, командир 748-го стрелкового полка подполковник Шмонин».

Наш герой был похоронен возле церкви югославского города Сомбор, который ныне находится в Республике Сербия (автономный край Воеводина). Летом того же года Миргазияна Галиулловича



*Общий вид красноармейской части партизанского кладбища, Сомбор*




*Боевой путь 206-й стрелковой дивизии (2-го формирования)*



*В день 70-летия Победы у памятника павшим односельчанам, Мукмин-Каратай*

перезахоронили на партизанском кладбище, расположенном в северо-восточной части Сомбора и имеющем югославскую и красноармейскую части. В нашей части оборудованы 325 одиночных захоронений и одна братская могила девяти офицеров с памятником, на котором выбиты только шесть фамилий, в том числе Крымова и Шмонина.



***Памятник над братской могилой наших офицеров, Сомбор***

Вот так, вдали от Родины, завершил военный путь наш земляк. Да и житейский – тоже. Посмертно он был награжден орденом Богдана Хмельницкого II степени. Его не забывали в СССР, помнят и в постсоветское время. Так, и поныне одна из улиц г. Тореза ДНР носит имя М.Г. Крымова. В год его 80-летия в газете «Вечерний Челябинск» была напечатана статья «Герой двух войн». Публикации об уроженце Самарской губернии появляются в разных изданиях и в XXI веке. Еще бы увидеть фамилию Миргазияна эфенди в перечне погибших на войне его односельчан, который вывешен на памятнике им в Мукмин-Каратае. О таких, как он, сложил стихотворные строчки М. Джалиль:

*«Умирая, не умрет герой –*
*Мужество останется в веках.*
*Имя прославляй свое борьбой,*
*Чтоб оно не молкло на устах!»*

# ӘТИСЕЗ УЗГАН ГОМЕР...

***Аналар кайгысы, аналар хәсрәте, аналар кичереше... Сугыш аналарга кайгыларның иң тирәнен, сагышларның иң ачысын бирә.***
***Ирен сугышка озаткан әниебезгә дә шушындый хәсрәт кичерергә туры килә. Ул безгә әтиебез турында гел сөйли торган иде.***

*Саимә МОРЗАХАНОВА.*
*Гали авылы, Похвистнево районы.*

Әтием – Хәмидулла улы Әхмәдулла Хәмидуллин сугышның беренче көненнән алып, соңгы көненә кадәр илебезне саклау өчен көчен, гомерен кызганмаган. Аның ике медале дә бар иде. Без бәләкәй чакта, медальләрен читәнгә кыстырып, кибетче булып уйный идек.

Әтиебез сугышка кадәр атлар караган. Ул киткәч, бу эшне әни башкарган. Каравылда да торган ул, ат җигеп, районга икмәк тә ташыган. Иң авыр эшләр әниебез җилкәсенә төшкән.

Әтине сугышка озатканда әни ике кызын – Халидә апамны (1936 елгы) һәм Халисә апамны (1939 елгы) кочаклап, өченчегә авырлы булып, акырып елап калган.

Киткәндә әти әниебезгә: "Малай тапсаң, Лотфулла дип исем бир", - дип әйтеп калдырган.

Әйе, әни малай тапкан, аңа Лотфулла дип исем куштырган. Тик сигез айлык бала, күз тиеп, вафат булган.

Әни сабыйга үзе теккән ак күлмәк, кара түбәтәйне кидереп, үзен бишеккә салган гына булган, күрше Хәдичә апа килеп кергән. Ул Лотфулланы тешләп-тешләп, бик каты сөйгән. Шуңардан соң бала имине капмаган да. Ашамыйча, кара сөяккә калган. Бармагына кап-кара шеш чыккан. Шулай бер ай интеккәннән соң күзләрен мәңгелеккә йомган. Үлгәч, шеш тә тишелеп чыккан. Инәкәйнең ул вакытта елаганнары...

Әни: "Иремә ни әйтермен? Ул безнең өчен сугышта кан коя. Син баланы да саклый алмагансың, дияр", - дигән уйлар белән калтырап яшәгән.

Әти сугышта элемтәче булган. Карпат тауларында чолганышка калып, 15 көн ач-ялангач яткан. Шинельләре бозланып каткан. Ут ягарга ярамаган. Самолеттан үзләренә ашарга ыргытып китә торган булганнар.

Гали авылыннан сугышка дүртәү чыгып киткәннәр – әти, Барый Насретдинов, Хәбибулла Самкаев, Камалетдин Хөснетдинов.

Инәкәй безгә сугышта булган бер могҗиза турында да сөйләгән иде. Әткәйләр юл буена ял итәргә утырганнар. Юлдан бер төркем атларны фронтка куып баралар. Ат караучы булган әтием, юлга чыгып, боларны күзәтә икән. Кинәт, тирәякны яңгыратып, үзәкне өзәрдәй итеп, арада бер ат кешнәп җибәрә дә әткәйнең каршына килеп баса. Әти, үзе караган атны танып, аңа исеме белән эндәшә. Хайван, ыргылып, югалткан атасын тапкан баладай, башын әтинең кулбашына куя. Шулчак атның күзләреннән мөлдерәп яшьләр агып, гимнастерка аша әткәйнең аркасын юешләтә. Әти, хайванны кочаклап, елый икән. Аларга карап, бөтен сугышчылар елаган шунда.

Бу мизгелдә әтиниләр кичерде икән? Шул вакытта инәкәебез, балалары, туган авылы исенә төшкәндер.

Шулай, әтиебез, атлар үтеп киткәч тә, үзенә килә алмыйча, озак кына басып торган. Күз каршыннан югалганчы, атлар артыннан карап калган.

Әткәебез 1946 елда сугыштан, коры сөяккә калып, бик бетеренеп кайткан. Инәкәй аны үләннәр белән дәвалаган.

Җиң сызганып, колхозда эшкә керешкән әти. Каравылда торган, атлар караган, җәй көне әни белән икесе дә кырда эшләгәннәр. Буш вакытларында әткәй кәсеп иткән. Камышлы якларыннан бәрәңге җыеп, шуны саткан. Күрше хатыннары йортыбызда аның кайтуын көтеп утырганнар. "Әхмәдулла, чамалап кына бир инде, барыбызга да җитсен", - дия торган булганнар.

Маллар суеп, итен Куйбышевка илтеп саткан әти. Әчәкләреннән инәкәй аш пешергән. Күп ятимнәрне ашатып, аларны ачлыктан коткарып калганнар.

Әти, яңа өй салырга җыенып, агачлар җыйган. Аларны су буена таллыкка яшерә барган. Күрше бабай, көнләшеп, бу турыда авыл советына барып әләкләгән. Язуы юк, дип, агачларны төяп алып киткәннәр. Шулчак әтием, берни әйтә алмыйча, елап басып калган. Закон каты булган шул.

1947 елда мин туганмын.

1949 елда колхозда иген бик тә уңган. Әткәй лобогрейкада иген урган, ә инәкәйләр, көлтә салып, бәйләп баралар икән. Кинәт әткәйнең хәле беткән. Әзрәк ял итеп алыйм әле, дип, җиргә яткан ул. Һәм шунда аңын югалткан. Аны, атка салып, Похвистнево хастаханәсенә илткәннәр. Өч ай буе дәвалап та, файдасы тимәгән. Инәкәй ул вакытта дүртенчегә йөкле булган. Атлар карау, каравылда тору – иң авыр эшләр тагын аның җилкәсенә төшкән. Ул, 15 чакрым араны йә җәяү, йә атта узып, әткәй янына йөргән.

Әти бик ябык булган, әни, үзенә дә юкны пешереп, аны ашаткан.

Менә әнинең бала табар вакыты килеп җиткән. Әтием аңа башка килеп йөрмәскә кушкан. Хатыны өчен курыккан. Ул вакытта



*Әхмәдулла Хәмидуллин утырганнар арасында сулдан беренче.*

бүреләр дә йөри торган булган бит. “Юлда, кырда чирләп китүең дә бар. Кем булышыр үзеңә? Белгән догаларыңны укып, терелүемне теләп тор. Аллаһыга тапшырабыз, иртәгә операция ясыйлар”, – дигән аңа әти. Ә шулвакыт үзенең күзләреннән яшьләр, ияге буйлап авызыннан кан агып төшә. Инәкәйгә күрсәтмәскә тырышып, ул, борылып, палатасына кереп киткән.

Бу аларның соңгы очрашуы була. Икесе дә ниләр кичергәнен үзләре генә белгәннәрдер инде. Әткәйгә операция ясыйлар, тик коткарып кала алмыйлар. Ул өстәлдә җан бирә. Үпкәләре инде тәмам каралып беткән була.

Икенче көнне абыйсы Кәлимулла хәлен белергә барган. Аңа әтинең үлеме турында хәбәр иткәннәр. Кәлимулла абыйның, өйгә кайтып, безнең әнидән: “Килен, олы кешегә ничә метр кәфенлек кирәк икән?” – дип соравы була, инәкәй, барысын да аңлап, акырып еларга тотынган һәм, аңын югалтып, идәнгә егылган.

Дүртенче кызын бик интегеп тапкан әни. Елаудан күзләре шешенгән булган, берни күрмәгән. Үзен көчкә генә аңына китергәннәр.

Икенче көнне әтиебезнең үле гәүдәсен кайтарганнар. Инәкәй, күзләрен көчкә ачып, сабыен кулына алган да, аны әткәй янына китереп, беренче һәм соңгы тапкыр күреп кал кызыңны, дигән.

“Әтисе вафат булганчы, бу бала үлсен иде. Хәзер дүрт кызын ялгызы ничек үстерер инде”, - дип, әниемне кызганып, елашканнар күрше-тирә хатыннар.

Әткәйнең чебештәй бәләкәйләнеп калган гәүдәсен алып чыкканда идәннең өрлеге сынып, ул ишелеп калган.

Өй суык. Октябрьнең уналтысы. Ягарга - утын, ашарга ризык булмаган. Олы апама - 13 яшь, икенчесенә – 11 яшь. Ә мин әле ике яшьлек кенә.

Апамнар әтиебезнең яхшы кеше булуын бүген дә сөйләп елыйлар. Ата рәхәтен түгел, сеңелем белән мин “әти” сүзен дә әйтә алмыйча, ятимлек шулпасын эчеп үстек.

Әткәйне җирләп кайткач, аның абыйлары идәннәрне ясаганнар. Хәрби комиссариаттан ниндидер кешеләр килеп, безгә колхоздан сыер бирү турында тиешле язуларны калдырып киткәннәр. Инәкәебез үзе дә ятим үскәнгә, бер класс та белеме булмаган. Шул язуларны авыл советына Зөфәр исемле кешегә биреп калдырган. Ә колхоз безгә сыер бирү түгел, әле, киресенчә, бездән бурычларыбызны түләүне таләп иткән. Әткәй хастаханәдә ятканда, әни аны, безне ашатыр өчен аннан ит, он, ярмалар алган булган.

Сеңелемә ай саен дүрт сум акча бирелгән. Аңардан да салым тотып калганнар.

Утын әзерләргә кеше булмаган. Йә ферма, йә бригад өйләрендә кыш чыкканбыз. Инәй өч эштә эшләсә дә, акча булмаган. Ул вакытта таякка хезмәт итәләр иде бит.

Апамнар сөйләве буенча, әниебезнең күргәннәрен язсаң, бер китапка гына сыймас иде, мөгаен.

Әткәй турында мин бернәрсә дә белми идем диярлек. Әйтерсең лә биш ел сугышта да булмаган, беркайда да исеме юк. Аның турында мәгълүмат эзләп, Подольск хәрби архивына хат яздым. Миндә әткәйнең бердәнбер рәсеме бар иде, аны да җибәрдем. Андый кеше архивта юк, дип җавап хаты килде. Шуннан районга барып, хәрби комиссариаттан сораштым да шуны белдем.

Әти һәм алда әйтеп үтелгән өч авылдашы Похвистневодан телефончы булып озатылган-

нар. Безнең әти Әхмәдулла түгел, ә Әхмәт дип язылган булган икән. 1943 елда ул "Батырлык өчен" медале белән бүләкләнгән. Төньяк-Кавказ фронтында, аерым кабель-шест ротасында телефончы-элемтәче булып хезмәт иткән.

Боларны миңа 2015 елда җибәрелгән справкадан укып белдем. Аны алгач, хәрби комиссариатка бардым. Безнең әткәй биш ел сугышта булган, һәйкәл булса да куегыз, ул моңа хаклыдыр, дигәч, миңа: "Андый указ 1996 елда чыкты, ә әтиең 1949 елда ук үлгән. Әниең исән булса, фатир алыр иде. Бернәрсә дә эшли алмыйбыз", - дип елатып кайтарып җибәрделәр.

Бөек Ватан сугышы беткәч, Япон сугышында катнашканнарга да фатирлар бирделәр, оныклары алды. Уч тутырып акчалар да бирелде. Ә без, кызлары, гомер буе ачы күз яшьләре йотып, әтиебез турында мәгълүмат җыеп, инәкәебезнең интеккәннәрен искә алып яшибез.

Яңа мәгълүмат тә алдым бит әле мин. Черниговский районы, Диңгезбай авылыннан Гөлнара Харрасова интернет челтәрендә Бөек Ватан сугышында катнашкан бабасы Габбас Ягъфәров турында язган һәм бер төркем солдатларның рәсемен элгән. "Бәлки, кем дә булса бу фотосурәттә үзенең туганын таныр. Беренче рәттә, уңнан беренче – минем бабам. Арттагы рәттә, уңнан өченче – Похвистнево районы, Гали авылыннан Барый исемле абый", дип тә өстәгән.

"Безнең белән Гали авылыннан өч кеше хезмәт итте", - дип сөйләгән аңа бабасы.

Бу хәбәрне Похвистневода яшәүче кызым Гөлчәчәк укыган һәм аны миңа да күрсәтте. "Инәкәй, рәсемдә алгы рәттә, сулдан беренче утыручы Әхмәдулла бабай булырга тиеш", - диде ул. Олы апам да бездә иде. Күргәч тә, кычкырып елап җибәрде. Фотосурәттә, чыннан да, безнең әти булып чыкты. "Улым Рәис әтиебезгә охшаган", - диде апам. Калган кешеләрне танымады.

Кызым бу мәкаләне урнаштырган Гөлнараны интернет аша эзләп тапты. Бабасы турында нинди мәгълүмат белә, барысын да сорашты.



*Әхмәдулла Хәмидуллин.*

Гөлнараның әнисенә 81 яшь икән. Шулай да сугыштан соң әтисе Габбасның Гали авылыннан хатыннары белән ике хәрби дусты килүен хәтерли. Тик кемнәр булганын әйтә алмый. "Берсенең хатыны йөкле иде. Соңрак кыз бала тапкан дип ишеттек, исемнәре исемдә калмаган", - дигән ул.

Мөгаен, ул Камалетдин исемле се булгандыр. Аның кызы да, минем кебек, 1947 елда туган. Бергә укыдык без.

1950 елда Габбас абый үзе дә хатыны белән Гали авылына кунакка килгән. "Бер иптәшенең, операция ясатып, үлгәнен бик авыр кичергән әти, чөнки алар аерылмас дус булганнар. Өзелеп-өзелеп елаган", - дип сөйләгән Гөлнарага әнисе.

Бу, әлбәттә, безнең әтиебез турында әйтелгән булган. Әткәйләр сугыш ахырында Леонид Брежнев командованиесендә хезмәт итеп, Берлинга кадәр барып җиткәннәр.

Тагын шунысы ачыкланды. Әткәй, Дон елгасын кичеп, элемтә чыбыгын ялгаган. Шуның өчен "Батырлык өчен" медале белән бүләкләнгән. Шунда бик каты салкын тидереп, алты ай госпитальдә яткан булган икән. Аның үлеменә дә шушы хәл этәргеч булып, үпкәсе каралып, туберкулездан вафат булгандыр, дип исәплибез без.

Әтиебез якты дөньядан 40 яшендә китеп барган. Ә аның сугышчан дуслары картаеп үлделәр.

Әйе, барысын да белә алмасам да, барыбер күпме мәгълүмат җыйдым, Аллаһыга шөкер. Хәзер әткәебезнең фотосурәте авылыбызда урнаштырылган махсус стендта башка Бөек Ватан сугышы каһарманнарының рәсемнәре белән бергә эленеп тора. Үткән саен, аңа сокланып, горурланып карыйм.

Газиз әткәебезнең каберен ташламыйбыз, карап-тәрбияләп торабыз. Үзен догаларыбыздан калдырмыйбыз. Әниебезнең дә, әтиебезнең дә урыннары Җәннәт түрләрендә булсын иде.

Һәр елны без, кызлары, әтиебезнең каберенә җыелып, Коръән укый идек.

Әти үлгән көнне туган Сәгыйдәбез дүрт ел элек якты дөньядан китеп барды шул.

Иң олы Халидә апама хәзер 87 яшь, аның аяклары начар йөри. Сигез ел элек 47 яшендә вафат булган улының хатыны Гөлсинә, унбер яшьлек оныгы тәрбиясендә яши. Киленебез алтын бәясенә тиң. Каенанасын шулкадәр яхшы карый, мең рәхмәт үзенә.

Халисә апама – 84 яшь.

Аллаһыга шөкер, әле дә ярый апаларым бар. Атна саен олы апама барабыз. Дүрт баласын җирләде ул. Кайгы күлендә йөзсә дә, шөкер, бирешмәде.

Халисә апамның да биш малаеның икесе бакыйлыкка күчте.

Әйе, ятимлек безнең итәккә тагылып йөри, юл куймый. Нишлисең? Җилгә каршы бара алмаган кебек, язмышка да үпкәләп булмый. Аллаһы Тәгалә шулай язган, күрәсең. Тешеңне кысып, сабыр булып, түзәргә генә кала...

***Сәламәтлек – кешенең иң зур байлыгы, дигән әйтем бар. Соңгы ике елда бөтен дөньяны дөр селкетеп торган коронавирус зәхмәте бу сүзләрнең дөреслегенә тагын бер кат инандырды. Әйе, кызганычка, бик күп якыннарыбызны, танышларыбызны югалтырга туры килде. Бу куркыныч чирнең күпме дәвам итүе, халык аның тагын ничә төрле штаммы белән көрәшәчәге әлегә билгеле түгел.***

***Эльмира СӘЙФУЛЛИНА.***



# “ВАКЫТНЫ – БУШКА, ГОМЕРНЕ ЗАЯГА УЗДЫРМЫЙСЫ ИДЕ”

Бөтен дөнья табиблары коронавирус белән көрәшә. Вакциналар уйлап таптылар, ашыгыч рәвештә яңа хастаханәләр төзиләр, табиблар ялсыз, көнне төнгә ялгап, “Кызыл зона”ларда эшлиләр...

Бүгенге әңгәмәдәшем – безнең иң зур байлыкны саклаучы белгеч. Юк, ул банк хезмәткәре түгел. Ул – табиб. Таныш булыгыз – терапевт, гомуми практика табибы Риф Хәйдәр улы Гибадуллин.

Ул Кләүле станциясендә гади хезмәт ияләре гаиләсендә беренче бала булып туган.

2004 елда Самарның “Реавиз” медицина университетын тәмамлагач, Калинин исемендәге өлкә хастаханәсендә гинекология буенча интернатура үтә. Хезмәт юлын ул туган якларында – Кләүле район хастаханәсендә гинеколог булып башлап җибәрә. Анда ике ел эшләгәннән соң, Риф гомуми практика табибы белгечлегенә аттестация уза һәм 2007 елдан 2014 елга кадәр Камышлы районының Иске Ярмәк авылында эшли.

Яхшы табиблар алтын бәһасенә тиң бит. Авыл җирендә аеруча белгечләр җитми. Яшь табибны Яңа Усман авылына чакыралар. 2020 елда “Яшь белгечләргә ярдәм итү” программасы буенча кайбер чикләүләр алына, һәм Риф Исаклы районының “Сокский” авылы ФАПына күченә.

– Бу авылда күптәннән табиб юк иде инде, халыкка бик авыр, – дип башлады сүзен әңгәмәдәшем. – Мин монда 2020 елның җәендә эшли башладым. Ә көзен коронавирус котырына башлагач, “Кызыл зоналар” ачылды. Беренче көннән үк диярлек мин «Фронт линиясендә». Бүгенге көндә яңа дарулар, вакциналар ярдәмендә бу куркыныч авыру белән көрәшү җиңеләйде.

***– Ә табиблар, шәфкать туташлары җитәрлекме?***

– Кызганычка, бу ачык, әлегә хәл ителмәгән проблема. Белгечләр җитми. Әмма, башка районнар белән чагыштырганда, безнең хастаханәдә хәлләр түзәрлек. Авырулар саны күп булуга карамастан, мөрәҗәгать иткән һәрбер кешене җентекләп тикшерү, тиешле дәвалану программасын билгеләү өчен белгечләр җитәрлек. Шулай ук безнең берничә мобиль бригада бар. Алар амбулатор дәвалану алучы авыруларны, шул исәптән балалар чирләгәндә, өйләренә





















барып күзәтәләр, аларның хәлен контрольдә тоталар.

Аннан соң, “Омикрон” штаммы ничектер башкача уза. Пневмония очраклары юк, диярлек. Ул дәвалауга да бирешә, авырулар, тизрәк тернәкләнеп, аякка басалар.

***– “Омикрон” балаларга ныграк бәйләнә, диләр, бу шулаймы?***

– Әйе, быел балалар күбрәк авырый, мәктәпләр карантинга ябыла. Минемчә, моның сәбәбе прививкада. Чөнки олыларның күбесе прививка ясатты, ә балалар – юк. Прививка 100 процентка якламаса да, аны ясаткан кешеләр авыруны күпкә җиңелрәк кичерә. Мин моны үземнең күзәтүләремә, тәҗрибәмә таянып әйтәм.

***– Күптән түгел балалар өчен вакцина кулланышка керде. Димәк, аларга да тиз арада прививка ясатыргамы?***

– Мин ашыкмас идем. Дөрес, зурлар арасында вакцинаның файдалы булуын күрәбез. Әмма, гадәттә, андый препаратлар йогынтысын озак вакытлар күзәтәләр. Ә коронавируска каршы балалар өчен чыккан вакцина әлегә бик аз өйрәнелгән. Шуңа күрә мин аңа шикләнеп карыйм. Аннан соң, яшь организм бу авыруга каршы иммунитетны үзе эшләп чыгарса, әйбәтрәк булыр иде.

Шуны да билгеләп үтәсем килә. Начар гадәтләре булмаган, спорт белән шөгыльләнүче кешеләр бу авыруны тизрәк җиңә. Кешенең нерв системасы тәртиптә, гаиләдә тынычлык, җаны тыныч булса – аның чирләргә каршы тору мөмкинлеге дә ныграк. Кешенең эмоциональ халәте физик халәткә турыдан-туры йогынты ясый. Бу – күп кенә галимнәр тарафыннан исбатланган факт. Мин алар белән килешәм.

Мәсәлән, балалар арасында кайберләре еш авырый, ә кайберләре – сирәк. Аларның кайсы нинди гаиләдән икәненә игътибар итсәк, еш авыручыларның я ата-анасы эчкече, я ул гаиләдә тынычлык юк, я ул бала анасы белән генә үсә. Ә тулы, тыныч, гармонияле гаиләләрдә мәхәббәткә төренеп үскән балалар сирәк авырый. Шуңа күрә прививка турында уйланганчы, гаиләдәге атмосфераны, үзебезнең уй-фикерләребезне тәртипкә китерергә кирәк, дип уйлыйм.

***– Риф Хәйдәрович, гадәти медицинадан тыш, сез бу өлкәнең башка юнәлешләре белән дә кызыксынасыз, бугай? Бәлки, сез табиблар гаиләсендә үскәнсездер?***

– Мин үзем өчен “Психосоматика” дигән бик кызыклы нәрсә ачтым. Табиб һөнәрендә бу – бик кирәкле фән, минемчә. Алдарак әйтеп киткәнемчә, күп авырулар кешенең күңелендә яшәгән проблемалар, иске яралар, үпкәләү хисләре, начар уйлар, күпсенү кебек нәрсәләр аркасында килеп чыга. Шуңа күрә пациентны, аны борчыган проблемаларны яхшырак белгән саен, дәвалау да җиңелрәк. Шәхсән минем өчен шулай.

Ә медицина һөнәрен сайлауда гаиләмнең катнашы юк диярлек. Әтием – шофер, әнием – товаровед. Ә менә әтиемнең әнисе Фатыйма әбием балага узалмыйча интеккән хатын-кызларга төрле массажлар белән ярдәм итә иде.

Табиб булып китүемә яшүсмер вакытта очраклы рәвештә кулыма эләккән медицина тематикасын яктырткан газета сәбәпче. Анда төрле йогышлы авырулар турында язылган, рәсемнәр дә күрсәтелгән иде. Газета укучылары сорауларына табиблар аңлатмалары китерелгән рубрика да очрады. Миндә шул вакытта табиб булу теләге туды һәм, хыялымны чынга ашыру өчен, тырыша башладым. Чыгарылыш сыйныфта укыганда югары уку йортының әзерлек курсларында белем алдым.

***– Табиб булып эшли башлагач, үкенү хисе булмадымы? Башка һөнәр сайларга булган икән, дигән уйлар тумадымы?***

– Юк, үз эшемне бик яратам. Чирдән арынган пациентларның шатлыклы йөзләрен күрүе миңа аеруча ләззәт бирә. Covid-19 белән көрәшкән дәвердә табиб һөнәренә күпләр башкача карый башлады, минемчә. Өйдә генә, үз көчең белән генә җиңә ала торган зәхмәт түгел шул ул, кызганычка, – дип авыр сулый Риф. – Без “Кызыл зонада” унар сәгать дежур тордык. Һәр авыруның хәлен иртән һәм кичен тикшереп торабыз.

Коронавирус бик тиз үзгәрүчән нәрсә ул. Мәсәлән, бүген авыруның хәле уртача, ә кичкә кандагы кислород күләме нык кимеп, кешегә һава җитми, тыны кыса башлый. Билгеле инде, без, бөтен булган






мөмкинлекләрне кулланып, аңа ярдәм итәргә тырышабыз. Әмма без тылсымчы түгел шул, кайвакыт бу чир каршысында без көчсез... Шул мизгелдә авыруның тонып барган күзләрендәге өметсезлек, яшәү чаткысының сүнүен күрү искиткеч авыр. Кайберәүләр: "Табиблар таш йөрәкле, алар беркемне дә кызгана белми", - дип расларга ярата. Әмма бу алай түгел.

***– Риф Хәйдәрович, вакцинация темасына килгәндә, бер ел эчендә бу хәл ничегрәк үзгәрде?***

– Хәл уңай якка үзгәрде. Беренчедән, халык прививканың файдасын күрде. Икенчедән, без, авыл халкы белән очрашып, вакцинаның безнең организмга ничек тәэсир итүе, аның ничек эшләве турында әңгәмәләр уздырдык. Халыкны борчыган сорауларга җавап биреп, икеләнүчеләргә ярдәм иттек.

Әйе, элек халык билгесезлектән курыкты, җитмәсә, прививкага каршы булган кешеләр төрле видеолар таратып тордылар. Әмма җәй көнне прививка ясатырга теләүчеләр саны сизелерлек артты, ә көзен инде икеләтә-өчләтә артты, дисәм дә, ялгышмам.

Чир белән көрәшкәндә иң мөһиме – вакытында табибка мөрәҗәгать итү. Вакытны сузган саен, дәвалау кыенрак булачак.

***– Вакыт дигәннән, сезнең буш вакытыгыз каламы? Аны ничек уздырасыз?***

– Бөтен эшеңне, көнеңне дөрес итеп оештырсаң, күп нәрсәгә өлгереп була, ял итәргә дә, хоббига да вакыт табыла, – дип елмая танышым. – Мин балачактан атлар яратам. Берникадәр вакыт үзем дә асрадым. Минем бер хыялым бар. Бәлки, иппотерапия дигән төшенчә турында ишеткәнегез дә бардыр.

Мин менә шушы юнәлештә эшләргә хыялланам. Атлар бит – искиткеч сизгер хайваннар, кешенең эчке халәтен бик нечкә тоялар. Шушы сыйфатлары өчен аларның ярдәмендә төрле авыруларны дәвалау ысулы уйлап тапканнар. Иппотерапия грек теленнән "ат" сүзеннән килеп чыккан. Ул пациентның психикасына уңай йогынты ясый, мускулларны ныгыта. Гомумән алганда, кеше организмына биомеханик йогынты ясый. ДЦП, аутизм кебек авыруларны дәвалауда бик уңышлы кулланыла.

Әмма бу эшне оештырып, ачып җибәрү бик кыйммәткә төшә. Кызганычка, әлегә мин үзем генә җиңеп чыгарлык түгел. Шулай да, өметемне өзмим. Бәлки, мөмкинлеге булган берәр мәрхәмәтле эшмәкәр, мине ишетеп, бу игелекле эшкә алыныр, дип ышанам.

Аннан соң, хәзер популярлашып киткән хиджама белән кызыксынам. Пандемиягә кадәр Яңа Усман фельдшерлык пунктында халыкны әлеге процедураларга кабул иттем. Бик файдалы юнәлеш, авыл халкы бик теләп йөрде.

Шулай ук мин – җыр-моңга гашыйк кеше. Авылда оештырылган чараларда бөтен гаиләбез белән актив катнашабыз. Мин концертларда рәхәтләнеп җырлыйм, биим. Кызым да, улым да данлыклы "Ак каен" ансамблендә бик теләп шөгыльләнәләр. Гаиләбез белән Самарның опера-балет театрында булырга яратабыз. Балалар циркны да читтә калдырмыйлар.

Дини-агарту эше өчен дә, хәйриячелек белән шөгыльләнергә дә вакыт табарга тырышам. Габдулла хәзрәт белән бергә Мөселман яшьләре форумында даими катнашам.

2010 – 2015 елларда Ярмәк авыл җирлеге депутаты итеп сайланган идем.

Кыскасы, вакытны – бушка, гомерне заяга уздырасым килми. Халкыма, авылыма файдалы буласым килә, гомеремне тулы мәгънәле итеп уткәрермен, дип ышанам, – ди яшь, талантлы, үз эшенең чын остасы булган табиб Риф Хәйдәр улы Гибадуллин.

Бу тынгы белмәс, энергиясе ташып торган ир-егетнең Мактау хатлары, граматолары турында да бер-ике сүз булса да әйтеп китмичә булдыра алмыйм. Озын исемлектә күзем төшкән берничәсен аерым атап китәсем килә: 2021 елның августында Риф Хәйдәр улы Гибадуллин «Аль-Игътисам» («Сплоченность») медале, 2020 елның июнендә өлкә губернаторы тарафыннан "За служение людям" дип аталган истәлекле билге, 2016 елда Дмитрий Азаровның рәхмәт хаты белән бүләкләнгән. Күпсанлы Мактау кәгазьләре арасында сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан, спорт ярышларында, балалар бакчасы тормышында актив катнашканы өчен бирелгәннәре дә байтак.

# “БАЛАЧАКТАН ХЫЯЛЛАНГАН ҺӨНӘРЕМДӘ БИК БӘХЕТЛЕ МИН”



***Тормышта табибларга зур игътибар бирелеп, ихтирам күрсәтелеп, кайчак шәфкать туташлары турында онытып та җибәрәләр кебек. Ә бит аларның хезмәте дә бик кирәкле һәм әһәмиятле булып тора. Алай гына да түгел, табиб диагноз куеп, дәвалау курсын билгеләгәннән соң, авыручы нәкъ шәфкать туташлары кулына тапшырыла.***

***Миләүшә Газимова.***

Әйе, һәрбер авыруның моңзарын тыңлап, үз һөнәрләренә тугры калып, ак халатларына тап төшермичә хезмәт куючы шәфкать иләре дә, һичшиксез, хөрмәткә һәм мактауга лаек!

Самар өлкәсе Красный Яр районы хастаханәсенең травматология бүлегендә 22 ел шәфкать туташы булып эшләүче милләттәшебез - Мөхтәр кызы Гөлназ Сафиуллина турында да халыктан бары тик җылы сүзләр ишетергә туры килде миңа.

“Гөлназ ханымның кулы җиңел, күңеле киң, йөрәге тулы мәрхәмәт. Аңардан беркайчан да бер дорфа сүз ишетмәссең, һәрвакыт ачык йөз күрсәтә, йомшак сөйләшә, юата да беләсе. Үз эшенең чын остасы”, - диделәр аңардан медицина ярдәмен алган кешеләр.

Шулай булмыйча, Гөлназ ханым кечкенәдән бу һөнәр турында хыялланып йөргән бит! Башка кызлар укытучы, пешекче, хат ташучы булып уйнаса, ул курчакларны дәвалый, үзләренә укол кадый, кесәләре тулы бинт, мамык була аның.

“Әйе, балачагымнан ак халат киясем, кешеләргә ярдәм итәсем килде минем. Гел табиб булып уйный идем. Туганнарыбыз арасында медицина хезмәткәрләре бар. Алар да миңа берникадәр тәэсир ясагандыр”, - ди әңгәмәдәшем.

Гөлназ Сафиуллина Камышлыда туа. Ә 1984 елда аның гаиләсе Кызыл Яр районының Светлое Поле авылына күчеп урнаша. Кыз янәшәдә урнашкан Мирный поселогы мәктәбендә белем ала. Унберенче сыйныфтан соң “Дәвалау



эше” белгечлеге буенча Самарның Н. Ляпина исемендәге медицина көллиятен (колледж) тәмамлый.

Укып бетергәч тә, үскән авылына кайтып, Кызыл Яр районы хастаханәсенә урнаша һәм бүгенге көнгә кадәр шунда хезмәт итә. Биш ел элек аны травматология бүлегенең өлкән шәфкать туташы итеп билгеләгәннәр икән.

“Әлеге хастаханәдә хирургия бүлегендә диплом алды практикасын үткән идем. Шул вакытта ярдәм күрсәткән, мине күп нәрсәгә өйрәткән хезмәткәрләргә бик рәхмәтлемен.

Ә инде 2000 елда медицина көллиятен тәмамлагач, биредә травматология бүлегендә хезмәт итә башладым.

Көн саен Светлое Поле авылыннан, 12 чакрым араны узып, маршрут ГАЗелендә эшкә барам-кайтам. Ә элеккеге елларда мондый мөмкинлек булмады. Шуңа күрә юл уңаена бара торган машиналарга утырып йөрергә туры килә иде”, - дип сөйли язмам герое.

***“Гөлназ ханым, хезмәтегез хакында сүз башлаганчы, әтиәниегезне искә алыйк әле. Газиз кешеләрегезнең нинди күркәм сыйфатлары сезгә күчкән икән? Аларның нинди үгетнәсыйхәтләрен күңел түрендә саклыйсыз?”*** – дип кызыксындым милләттәшебездән.

“Кызганычка, әнием Гөлсем якты дөньяда юк инде. Әтием Мөхтәр, Аллаһыга шөкер, исән-сау.

Без гаиләдә ике бала - энем Рөстәм бар. Безне укытып чыгарганнары, аякка бастырганнары өчен әти-әниемә бүген дә рәхмәтлебез.

Алар безне мәрхәмәтле, ярдәмчел, кешелекле, олылар-

га хөрмәтле булырга өйрәтеп үстерделәр. Гаделлек, максатлылык, намуслылык сыйфатларым да нәкъ алардан күчкән.

Әнием шундый шат күңелле, игелекле җанлы кеше иде! Дөньядан бик иртә китеп барды шул. Үзен яраталар, хөрмәт итәләр иде. Кайда гына эшләмәсен, һәр җирдә дә җитәкчеләре һәм хезмәттәшләре тарафыннан мактауга гына лаек булды ул, әле дә аны җылы сүз белән искә алалар.

Әнием ветеринария фельдшеры иде. Башта "Красноярский" совхозында үз һөнәре буенча, аннары ветеринария даруханәсе мөдире булып хезмәт итте. Соңгы елларда Кызыл Ярда ветеринария даруханәсендә сатучы иде.

Әтием – шофер, үз гомеренә рульдә булды. Нефтьчеләрне эшкә йөртте. Биш ел элек лаеклы ялга чыкса да, бер дә тик тормый ул. Әти-әнисеннән мирас булып калган умарталыкта мәш килә.



Әниемне догадан калдырмыйбыз. Урыны Җәннәт түрләрендә булсын. Әтиемә Раббыбыз исәнлек, озын гомер насыйп итсен. Ата-ана - иң якын, иң газиз кешеләр. Аларның кадерләрен белеп яшәсәк иде", - дип сөйләгәндә күз яшьләрен тыя алмады Гөлназ ханым.

Шулай, аралаша тора, без аның белән медицина темасына да күчтек.

***"Сезнең өлкәдә эшләүчеләр нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?"*** – дип сорыйм үзеннән.

"Медицина хезмәткәре үз эшен яхшы белергә, тирән гыйлемле, җаваплы булырга тиеш. Безнең хезмәттә хата ясарга ярамый!



Югары профессиональлектән тыш, мәрхәмәтлелек, сабырлык, кайгыртучанлык, игътибарлылык кебек сыйфатлар таләп ителә.

Кешеләр белән аралаша белү мөһим. Бигрәк тә өлкәннәргә хөрмәт белән карарга кирәк. Авырулар бит бездән һөнәри ярдәм генә түгел, ә рухи ярдәм дә көтәләр. Алар проблемалары, кичерешләре белән уртаклашалар. Шуңа күрә үзләрен тыңлый белергә, караңгы йөз күрсәтмәскә иде. Киресенчә, хәленә керергә, киңәш белән ярдәм итәргә, тынычландырырга тырышырга кирәк. Шулай булганда авыручыларның күңеле күтәрелә, хәле яхшыра, тизрәк тереләләр. Татар халкы: "Яралы җанга яхшы сүз дә – дәва", - дип юкка гына әйтми бит инде".

***"Хезмәтегез нәрсәсе белән күңелегезгә якын?"***

"Иң беренче чиратта, кешеләргә ярдәм итүемә, аларга файда китерүемә шатланам. Хәзер, өлкән шәфкать туташы булгач, күбрәк кәгазь эше белән шөгыльләнәм һәм монысын да яратып башкарам. Аннан соң кабинетымда гына утырып тормыйм мин. Хезмәткәрләремә булышам, тәҗрибәм белән уртаклашам, барысын да җентекләп аңлатам, күрсәтәм. Ярдәм кирәксә, беркайчан да баш тартмыйм. Кизү торырга да калгалыйм.

Гади шәфкать туташы булганда да яратып эшләдем, хәзер дә хезмәтем ләззәт китерә, Аллаһыга шөкер. Шушы һөнәрне сайлавыма бер генә дә үкенгәнем юк.

Коллективыбызның яхшы булуы – үзе бер бәхет. Безнең табиблар да, шәфкать туташлары да - белемле, тәҗрибәле кешеләр. Әлхәмдүлилләһ, бердәм булып, бер-беребезне тыңлап, хөрмәт итеп, киңәшләшеп эш итәбез".

***"Һөнәрегездә кемнәрдән үрнәк алдыгыз?"***

"Эшкә урнашкач, беренче көннән үк өлкән шәфкать туташы Анна Васильевна Борисова минем остазым булды, аңардан үрнәк алдым. Хәзер ул лаеклы ялда.

Анна Васильевна безне бөтен нәрсәгә дә өйрәтте. Беркайчан тавышын күтәрмәде, барысын да җентекләп аңлатып, күрсәтеп бирер иде. Чама белән таләпчән, чама белән йомшак булды. Ул безне медицинада әниебездәй тәрбияләде. Мин аңа бик тә рәхмәтлемен. Үзенә исәнлек, озын гомер телим".

***"Хәзер инде үзегез, тәҗрибәле медицина хезмәткәре буларак, яшь шәфкать туташларына нинди киңәшләр бирер идегез?"***

"Әгәр дә бу һөнәрне сайлап алганнар икән, бөтен күңелләрен биреп, тырышып, җиренә җиткереп, җаваплылык тоеп эшләсеннәр



иде. Игътибарлы, максатка омтылышлы булсыннар, һәрдаим белемнәрен камилләштерсеннәр, тәҗрибәле хезмәткәрләрдән үрнәк алсыннар, алардан өйрәнергә тырышсыннар, дип киңәш итәр идем".

***"Җитәкче булуы авырмы?"***

"Җиңел, дип әйтмәс идем. Һәр кешенең үз холкы бар бит.

һәрберсенә җаен табарга кирәк.

Кул астымда эшләүче шәфкать туташларына, санитаркаларга беркайчан да тавыш күтәрмим мин. Күзгә-күз тыныч кына сөйләшеп, барысын да аңлатам. Аларның һәрберсенә хөрмәт белән карыйм".

***"Хезмәтегездә төрле җәрәхәтләр алган кешеләр белән очрашасыз. Авыр хисләрегезне эштә калдырып буламы?"***



*Гөлназ ханымның әтисе һәм әнисе.*

"Әйе, дөрес әйтәсез. Безгә төрле хәлдәге авыруларга ярдәм күрсәтергә туры килә. Эт тешләгән, баш мие селкенүе алган, егылып, сөяген сындырган һәм башкалар, һәм башкалар. Безнең янәшәдән федераль трасса үтә. Шуңа күрә юл һәлакәтенә эләгүчеләр бик күп.

Бәгыребез таш түгел бит, әлбәттә, кешеләрне җәллисең. Авыр хисләрне эштә калдырырга тырышсам да, барыбер өйгә дә кайталар. Хәлен ничек яхшыртырга, тизрәк терелсен өчен тагын нинди ысуллар кулланып карарга, ничек авыртуын бастырырга, дип уйланып йөрисең".

***"Бик тә авыр хәлдә булган авырулар өчен дога кыласызмы?"***

"Раббыбыздан һәрвакыт ярдәм сорыйм мин. Әтием һәм әнием ягыннан әбиләрем кечкенәдән догалар өйрәтеп, динебезнең әһәмиятлелеген, Аллаһы Тәгаләнең барлыгын-берлеген сеңдереп калдырдылар. Рәхмәт үзләренә".

***"Стресслардан ничек арынасыз?"***

"Балаларым, дусларым, туганнарым ярдәм итә. Өйгә кайтып, кызларым кочагына элаккәч, күңелем тынычланып китә, аруым кими, авыр хисләрдән арынам. Хәләл җефетемнең, әтиемнең җылы сүзләре көч, дәрт өсти".

***"Ирем, балаларым, дигәннән. Гаиләгез белән дә таныштырып үтсәгез иде".***

"Ирем Ринат белән ундүрт ел бергә гомер итәбез. Ике кыз бала тәрбиялибез. Эльвирабыз тугызынчы сыйныфны тәмамлады, Альбинага - унөч яшь. Алар - безнең ярдәмчеләребез, өй-йорт эшләрендә булышалар.

Эльвира, миңа карап, медицина өлкәсен сайлап алырга тели. Хирург булырга хыяллана".

***"Ирегезнең нинди сыйфатларына кызыгып кияүгә чыктыгыз?"***



*Эльвира әбисе Халисә белән.*

"Ярдәмчел, кеше кайгысын уртаклашучан, миһербанлы, тәртипле, юмор хисле кеше ул. Миңа карата игътибарлы, ихтирамлы, кадеремне белеп, булышып яши, Аллаһыга шөкер".

***"Ә ул кызларыгызны тәрбияләүдә катнашамы?"***

"Миннән күбрәк ирем катнаша әле, чөнки ул сменалап эшли, ә мин көн саен хастаханәдә. Шуңа күрә балаларыбыз белән ул күбрәк вакыт үткәрә.

Кызларыбыз, Аллаһыга шөкер, безне шатландырып кына торалар. Акыллы, тәүфыйклы, мөстәкыйль булып үсәләр".

***"Кешеләрдә нинди сыйфатларны өстен күрәсез?"***

"Гадел, намуслы, игелекле шәхесләрне яратам".

***"Буш вакытларыгызда нәрсә белән шөгыльләнәсез?"***

"Чәчәкләр яратам. Алар белән йортым тулы. Җирдә, бакчада казынырга ошый миңа. Элегрәк бәйләм бәйли, тегә идем".

***"Сезнең турында уңганбулган, аш-суга оста, бик җитез, барысына да өлгерә, дигән сүзләр ишеттем".***

"Әнием белән әбием шундыйлар иде. Бу миңа алардан күчкәндер инде. Тормыш барышында үзең дә күп нәрсәгә өйрәнәсең бит инде. Гаиләмне, кунакларны татар ашлары белән сыйларга яратам шул", - дип, тыйнак кына елмаеп куйды Гөлназ ханым.

***"Тормышыгызны яңадан башларга туры килсә, берәр нәрсәне үзгәртер идегезме?"*** – дигән соңгы соравымны бирдем аңа.

"Бернәрсәне дә үзгәртмәс идем. Бөтенесеннән дә бик канәгать мин, барысы да бар, тагын нәрсә теләргә була ди?!

Балачактан хыялланган һөнәремә ия булдым, эшемне чын күңелдән яратып башкарам.

Ирем белән бер-беребезне сөеп, хөрмәтләп, зурлап, ярдәмләшеп гомер итәбез, әлхәмдүлилләһ.

Кызлы кеше бик бәхетле, диләр бит. Бу, чыннан да, шулай. Раббыбыз аларны безгә олуг бүләк итеп бирде, Аңа шөкер кылабыз.

Аллаһы Тәгаләдән тагын да күпне сорамаска, ә Ул биргәнгә риза булырга, азсынмаска кирәк, диләр бит. Мин нәкъ шулай яшим дә".

# ТАБИБ БУЛУ ӨЧЕН БЕЛЕМ ГЕНӘ ҖИТМИ

***Ел саен июнь аенда табиблар көне билгеләп үтелә. Табибларны еш кына ак халатлы фәрештәләр, коткаручылар, гомер бүләк итүчеләр, дип атыйлар. Чыннан да, алар бит адәм баласына тәүге тапкыр якты дөньяга аваз салырга да, үлем тырнагыннан котылып калырга да ярдәм итәләр. Хәзерге заман медиклары эшләрендә иң югары технологияләр, алдынгы аппаратуралар кулланалар. Алар ярдәмендә дөрес һәм тиз арада диагноз куеп, дәвалауны кичектермичә башларга мөмкинлек бар. Ә моннан йөз елга якын элек табиблар күбрәк үз белемнәренә, сиземләү сәләтенә таянып эш иткәннәр.***

*Затия Госман кызы Җаббарова сөйләгән истәлекләрне*

***Эльмира СӘЙФУЛЛИНА** язып алды.*







Самар өлкәсе Елховка районының Тупли авылында да чын мәгънәсендә ак халатлы фәрештә яшәгән. Клавдия Пантелеевна Чиндинаны бу авылда бүген дә бик хөрмәтләп, сагынып искә алалар. Авылдашлары аны яратып «Клаудия апа» дип атыйлар.

Клаудия апа турында хатирәләр белән Тупли авылында яшәүче Затия Госман кызы Җаббарова бүлеште.

- Клаудия апа әнием белән бертуган Ярулла абыемның тормыш иптәше иде. Ул үзе рус милләтеннән. Тумышы белән безнең авылдан ерак түгел генә урнашкан Калиновка авылыннан. Элек аны Кобельма авылы дип атаганнар. Ул күп балалы гаиләдә туган. Алар тугызысы да, замана авырлыкларына карамастан, һөнәри белем алганнар. Клаудия апа бәләкәй вакытта ук әтисе үлеп киткән. Әниләре, 9 ятимне канат астына алып, аларны ялгызы аякка бастырган, чын кешеләр итеп тәрбияләгән. Безнең килен апабыз урта мәктәпне тәмамлагач, Куйбышевта медучилищеда укый. Ачялангач булуга карамастан, укуын ташламый. Бөтен авырлыкларны җиңеп, үзенә һөнәр ала. Кайвакыт Куйбышевтан авылга ялга җәяүләп тә кайтырга туры килгән аңа.

Укып бетергәч, аны Елховка авылының земский больницасында фельдшер-акушер булып практика үтәргә җибәрәләр. Бераздан Клаудия апа юллама буенча безнең авылга (Тупли) эшкә килә. Берникадәр эшләгәннән соң, ни сәбәпледер, аны Русская Селитьба авылына күчерәләр. Рус авылы булса да, апабызның күңеле ятмый - ул кире безнең авылга сорала. Шулай итеп, 1939 елда ул Тупли авылында бәләкәй генә медпунктта эшли башлый. Колхоз аны бер ялгыз әбигә квартирант итеп урнаштырган. Шул әби аны акрынлап татарча өйрәтә башлаган.

Көннәр уза торган. Язмыш аны минем Ярулла абыем белән очраштырган. Абый мәктәп директоры булып эшли иде. 1940 елда алар кушылалар, ә 1941 елда уллары Вил туа.

Ул вакытта декрет яллары дигән нәрсә юк бит инде. Шулай итеп, Клаудия апабыз тиздән, җиң сызганып, үз эшенә алына. Вилне минем Хафизә әбием карап үстерешкән. Вилгә 10 яшь тулгач, икенче уллары Равил туа.

Клаудия апабыз үз эшенең чын остасы иде, һөнәренә бөтен җанын-тәнен, күңелен биреп эшләде. Аның җылы, шифалы куллары аша үткән балаларның санын чутлап бетерерлек түгел. Авылда кайсы бала ничәнче елда туганны, кызмы, малаймы икәнне ул, биш





бармагы кебек, белә иде. Ул заманнарда һәр йортта 5-6 бала иде, көн саен 2-3 бала туган. Бала туганнан соң сабыйның да, ананың да хәлен дә белешеп торырга кирәк бит әле. Клаудия апа беркайчан да зарланмады, авырсынмады. Көнме-төнме, яңгырмы-буранмы, сумкасын асып, чыгып китә иде. Шунысын әйтергә оныта язганмын. Клаудия апа карамагына, безнең авылдан тыш, тагын Алмалы һәм Чишмә авыллары да керә иде. Кызганыч, әмма ул авыллар хәзер юк инде. Менә шул өч авыл арасында ул җәяүләп йөри иде. Әгәр бәбиләгәндә берәр авырлык килеп чыкса, ул, үзе транспорт табып, хатын-кызны Елховка хастаханәсенә озата барган. Ул эшләгән дәвердә бер генә бала да үлмәгән.

Авыл халкы белән аралаша-аралаша ул акрынлап татарча җиңел сөйләшә башлады. Безнең халыкны, тормыш рәвешен шулкадәр үз итте ки, хәтта үзе дә мөселман кануннары буенча яшәргә тырышты. Совет власте динне тыйса да, авылда дингә тугры булып калган олылар байтак иде. Безнең әбиебез дә намазларны калдырмаган. Ярулла абыебыз белән Клаудия апага никах укытырга карар кылалар. Әмма моны ачыктан-ачык эшләргә ярамый. Чөнки абый - партия әгъзасы, ә Клаудия апа башка диндә. Авылның 4 мәчетеннән берсе генә эшләгән ул вакытта. Муллалар да Себергә сөрелгән. Әбиебез, Гәрәй мулла белән сөйләшеп, абый белән Клаудия апага яшерен генә никах укыйлар. Мулла апабызга Кадыйча дип татарча исем дә кушкан. Әмма халык аны барыбер гомер буе Клаудия апа, дип атап йөртте. Тик Газизә апа Исмәгыйлева гына аңа үлгәнче Кадыйча апа, дип эндәште. Клаудия апабыз Газизә апага 7 баласын бәбиләргә ярдәм иткән.

Клаудия апа кебек кеше бердәнбердер, мөгаен. Искиткеч киң күңелле, миһербанлы, шәфкатьле, кыю кеше иде. Ул дөньяга аваз салырга ярдәм иткән балалар арасында төрле өлкәләрдә зур уңышларга ирешкән кешеләр шактый. Җитәкчеләр, алдынгы хезмәткәрләр, медиклар, инженерлар, юристлар, укытучылар һәм башкалар. Сугыш елларында тырышып эшләгәне өчен Клаудия апаны орден-медальләр белән бүләкләделәр, Хезмәт ветераны исеменә лаек булды.

1942 елда агулы башак ашап, бик күп халык септик ангина белән авырып үлгән. Халыкка ярдәм итү өчен, авылга тәҗрибәле табиблар килеп, таш мәчеттә вакытлыча хастаханә оештырганнар. Клаудия апабыз, көнне төнгә ялгап, шунда эшләгән. Тәмам авыруны җиңгәнчегә кадәр тәүлекләр буе аягүрә торып хезмәт иткән.

Кадерле, хөрмәтле, яраткан Клаудия апабыз 40 елдан артык Тупли авылы халкының исәнлеге сагында торды, ел саен 150 - 170 балага туарга ярдәм иткән. Ә менә аның үзенә ярдәм кирәккәч, хөкүмәт тарафыннан булышырга теләүче булмады. Хәтта апабызга лаеклы ялга чыгу, инвалидлык рәсмиләштерүне дә без бергәләшеп, зур тырышлык белән генә очлап чыгара алдык. Клаудия апа яман шеш авыруыннан интекте, мәрхүмкәем. Самарда яшәүче улы Вил, эшен ташлап, авылга әнисен карарга кайтты. Ул анасын, сабыйларны караган кебек, тәрбияләде. Уколын да кадый иде, перевязкаларын да үзе ясый иде. Апабыз бик













озак урын өстендә ятты. Хәлемнән килгән кадәр мин үзем дә ярдәм иттем. Күзләремә тутырып карап, шулкадәр зур рәхмәтләр әйтә иде җаныкаем. Башка туганнарыбыз да, тирә-күршеләребез дә, хәтта инде күптән авылда яшәмәгән авылдашлар да, кайтып, Клаудия апабызның хәлен белешеп тордылар. Аллаһының иң олы рәхмәтләре яусын аларга. Күршедә үскән Ильяс, Илдар, Равилә Шәкүровлар аеруча игътибарлы булдылар апабызга.

Кызганычка, кеше гомере чикләнгән шул. 1919 елның 9 маенда туган Клаудия - Кадыйча апабыз 2010 елның июнь аенда 91 яшендә мәңгелеккә күзләрен йомды. Авыл халкы аны хөрмәт итеп, авыл зиратында җирләде. Минем хатирәләрем аның рухын шат итсеннәр, колган догаларым кабул булсын иде, амин.

Ярулла абыебыз белән алар бербөтен, бер уй-фикердә булып, күпләргә үрнәк булырлык гомер юлы уздылар. Искиткеч авыр хезмәт, тормыш ачысына карамастан, алар беркайчан да бер-берсенә кычкырып эндәшмәделәр, караңгы йөз күрсәтмәделәр. Алар арасында бары тик кадәр-хөрмәт һәм мәхәббәт кенә яши иде. Абыебызны санга санап, хөрмәт итеп, яратып яшәгәне өчен Клаудия апабызга мин бик рәхмәтле. Ярулла абый балачакта таудан чана шуганда аягын сындыра һәм гомер буена гарип булып кала. Ул култык таяклары белән генә йөри иде. Шуңа да карамастан, искиткеч көчле рухлы, тынгы белмәс кеше иде. 25 ел мәктәп директоры булып эшләде. Ул вакытта авылда өч мәктәп - таш мәктәп, байлар йортында, агач мәктәп иде. Ул һәр көнне ике таяк белән шулар арасында йөргән. Утын әзерләү, ремонт һәм башка эшләр - барысы да абыебыз җилкәсендә булган. Мәктәпнең 2 аты бар иде. Шул атка утырып, Елховкага да китеп бара иде абый. Лаеклы ялга чыккач та, укытучы булып эшләвен дәвам итте.

Беркемдә дә булмаганда Ярулла абый белән Клаудия апабыз алма бакчасы үстерделәр. Анда алма, чия, җиләк-җимеш тә үсә иде. Алар утырткан кура җиләкләре, карлыган агачлары бүген дә шаулап уңыш бирәләр. Абый, язын-көзен шул агачлар күләгәсенә утырып, тирә-юньдәге гүзәлеккә соклана иде.

Ярулла абый һәм Клаудия апаның истәлеге булып хәзер, язларын ап-ак чәчәккә күмелеп, шул алма бакчасы гына шаулап тора. Бу ике күркәм, олы йөрәкле кешенең урыннары мәңге оҗмах түрендә булсын иде!







# ЭТА СЛУЖБА И ОПАСНА, И ТРУДНА…

***Законы, в рамках которых действовали органы внутренних дел, всегда напрямую зависели от структуры государства и идеологии, которой оно придерживалось.***
***Союз Советских Социалистических Республик, в бытность которого выросли многие поколения людей в нашей стране, был первым в мире государством, ориентированным на социальную справедливость, дружбу и равенство всех народов, проживающих на его территории. Эта страна, пройдя сквозь суровые испытания, стала мощной державой, способной обеспечивать мир во всем мире.***

***Фарид Ширияздaнов***

Законы, составляющие основу государственности, были суровыми, но справедливыми. Они были направлены на защиту интересов государства и граждан страны, невзирая на их пол, национальную и социальную принадлежность.

Для службы в органах внутренних дел тогда подбирались люди самые достойные и верные идеалам, на которые были ориентированы общество и государственный строй.

Надо заметить, что органы внутренних дел тогда напрямую подчинялись Исполнительным комитетам народных депутатов на всех их уровнях.

Это было незабываемое время, когда действовали социально ориентированные законы, правила и принципы, о которых люди мечтали всегда, на протяжении многих столетий.

Органы народной милиции, призванные обеспечивать порядок в стране, прошли долгий путь эволюции. В начале пути приходилось действовать жестко и решительно, так как шла непримиримая борьба между различными социальными слоями. При этом у каждой из сторон была своя правда, за которую они бились насмерть.

В итоге победили идеи социализма.

Когда социалистическое общество набирало темпы в своем развитии, на страже его законов стояла народная милиция, о деятельности которой речь пойдет ниже. Наш собеседник – Фаат Талгатович Мустафин, майор милиции в отставке.

***– Как Вы пришли в органы милиции?***

– Главными принципами отбора в ряды милиции тогда были: чтобы человек отслужил в армии, был крепок физически, морально устойчив и не был судимым.

Отслужив в армии, я приехал домой и устроился на работу в научно-исследовательский институт г. Новокуйбышевска. В то время ежегодно по путевке комсомола несколько человек направляли служить в органы милиции. В их число попал и я.

Сначала окончил школу милиции в городе Куйбышеве и стал служить оперативным работником. Затем направили на обучение в Елабужскую среднюю специальную школу милиции, которую я окончил, получив диплом с отличием. В Новокуйбышевске стал работать участковым инспектором, работал в штабе и начальником службы общественного порядка города. После работал начальником спецкомендатуры, и оттуда направили меня в высшую школу милиции в город Киев. Когда проучился там два с половиной года, развалился Советский Союз, и мы разъехались кто куда, по местам прежней работы.

Ну а выбору этой профессии, наверно, в большей степени способствовала и моя служба в пограничных войсках. Служил я нав Западной Украине, а именно в Закарпатье.

***– После развала Советского Союза было принято очернять его во всех проявлениях и направлениях деятельности. Что думаете об этом?***

– Мы все – выходцы из СССР и воспитаны на основе идеалов, которые были социально ориентированы. Главной ценностью тогда был человек, и все устремления государства были направлены на

заботу о человеке и его защиту как личности.

Перед нами были открыты все пути для жизнедеятельности и даны все возможности для всестороннего роста и развития.

Я, как истинный патриот своей Родины, считаю высшей степени неблагодарностью очернение страны, в которой ты вырос, сформировался как личность, получил образование и мог достойно прожить свою жизнь и воспитывать добропорядочных детей. И самое главное – каждый человек тогда имел право на труд, отдых и ощущать себя достойным гражданином в обществе. А это многого стоит!

Как говорят, время все лечит. Наш народ и общество, втянутые в хаос предателями, под руководством западных злопыхателей, сейчас стал прозревать и признавать пагубность содеянных ошибок. При этом нарастающие чувства ностальгии многих заставляют задуматься не только о прошлом, но и со страхом думать о том, что же нас ждет там, впереди.

***– Что думаете о роли и значении тогдашней милиции и полиции сейчас?***



***На дозоре***

– Без малого тридцать лет я прослужил в органах милиции и горжусь этим. Эти были годы моей молодости, романтизма, когда мы верой и правдой служили Родине и своему народу. Ради этого в полную силу боролись с преступностью, часто подвергая себя смертельной опасности.

В отличие от других, мы прежде всего думали о долге перед Родиной, об офицерской чести, о согражданах и обществе, покой которых мы были призваны охранять.

Я с удовольствием вспоминаю то, когда дружба, честь и взаимовыручка ценились выше всего. Мы постоянно заботились о своей выправке и физическом здоровье и старались быть примером для других во многих проявлениях жизни.

Когда работал участковым, я заводил «амбарную книгу», куда заносил сведения о семьях, с которыми приходилось работать вплотную. Например, где часто нарушался общественный порядок или вырастали трудные подростки, где проживали люди, вернувшиеся из мест заключения.

Наиболее активных ребят, которые тяготели к правонарушениям, я старался привлекать в спортивные секции, изучал их интересы и старался устроить их в различные кружки, за что они и их родители были благодарны мне.

А тех, которые приходили из мест заключения, старался устраивать на работу. Хотя брали их крайне неохотно, я любыми путями старался, чтобы человек не возвращался в преступную среду и, отчаявшись, не превращался в рецидивиста.

Тогда труд для всех был благом, и каждый гражданин просто обязан был трудиться. Это было время, когда люди находили радость в труде, и, самое главное – трудиться было тогда почетно!

Я всегда считал, что участковый инспектор должен быть в курсе всех событий, что происходят на его участке, и вовремя среагировать на любую ситуацию. Более того, он должен быть своим человеком в каждой семье и чтобы люди в нем видели свою опору, защиту и уважали его, как представителя народной власти.

В те годы, когда я работал, шла серьезная работа с детьми. Общество заботилось о том, чтобы они вырастали достойными гражданами.

Тогда активно работали Дома пионеров и другие детские организации, где работали различные кружки для творчества, самодеятельности и созданы все возможности для других занятий. Например, в каждом домоуправлении также были организованы все возможности для проведения досуга детей и проявления их способностей для достойного применения в дальнейшей жизни. Их постоянно посещали и контролировали педагоги, участковые инспекторы и работники детских комнат милиции.



***В погранвойсках***

Кино, театры, искусство, радио, телевидение – всё было нацелено на воспитание добропорядочных граждан, на облагораживание общества. В нашей стране была лучшая в мире образовательная система, где во главу угла ставилось воспитание человека как личности.

Идеалы, на что были ориентированы воспитательные меры, содержали в себе общечеловеческие ценности, которые пропагандировали мир и дружбу между народами.

Сейчас, к сожалению, от всего этого ничего не осталось. Более

того, все прошлые достижения бесцеремонно опошляются и представляются в негативном свете. Возникает такое ощущение, что всё переворачивается наизнанку и ставится с ног на голову.

Например, вместо стройного, подтянутого постового милиционера нередко приходится видеть полицейского с большим пузом. Однажды, когда пришлось побывать в отделе полиции, многое из увиденного поразило мое воображение. Например, когда мимо проходила щупленькая девчонка в мини-юбке, у которой с одной стороны ниже колен болталась резиновая палка, а с другой – на висячем поясе, как у ковбоя, висела кобура с пистолетом, бьющая по голой ляжке, – я обалдел. А когда мой взгляд упал на наручники, висевшие на ее поясе, старался представить себе как же она сможет справиться с опасным преступником?!

Мне как-то странно видеть и полицейского с автоматом в руках. Ведь мы никогда не носили оружия с собой. Пистолеты брали только тогда, когда шли на захват опасного преступника. Ну а автоматы хранились в сейфе и были задействованы лишь в самых крайних случаях.

Тут поневоле задумаешься: что же случилось с нашим обществом?! Что же грозит мирной жизни граждан? Кого они так охраняют в полном боевом снаряжении, как в военное время?

Тут опять приходится сравнивать с тем, что было раньше. Ведь тогда нашим главным оружием была сила слова и убеждения, а нашей опорой был высокий авторитет в обществе. И мы просто охраняли покой и порядок, которые были прочно установлены в нем тогда.

***– Люди устали возмущаться всем тем, что происходит сейчас, и невозможностью представить даже то, что будет завтра. При таком раскладе на что можно надеяться сейчас и что возможно сделать в будущем?***

– Большая ошибка заключается в том, что сейчас отбрасывается всё, что было достигнуто в прошлом. Хотя бы взять народные дружины, которые активно действовали тогда. Ведь таким образом общество само боролось с пороками, которые были в нем.



Во-вторых, нужна идеология, на которую должно быть ориентировано само общество и порядок в ней.

И еще, когда все оценивается деньгами и ни во что не ставятся моральные ценности, возможно ли говорить о стабильности в обществе и порядке в нем? Тем более о взаимоуважении и согласии между людьми!

***– Понятно, что тогда авторитет милиции и доверие к ней были высокими, хотя и там были определенные злоупотребления. Но, при всем этом, Вас характеризуют не только как высокого профессионала, но и как человека искреннего, порядочного, воспитанного на основе высоких моральных устоев. Откуда это?***

– Я родился и вырос в простой семье сельских трудяг. Отец всю жизнь проработал механизатором в колхозе. За доблестный труд был награжден орденом. Мать также трудилась на колхозном производстве. Естественно, они во всем для нас были примером. Мы также вырастали привычными к труду и к трудностям. Поэтому уже с детства познавали многие тонкости жизни во всех ее проявлениях.

Нас воспитывала улица, в лучшем понимании этого слова. Она учила нас коллективизму, ценить дружбу и быть стойкими, уметь постоять за себя, хранить свою честь и доброе имя.

Хотя тогда не было компьютеров и намного позже появились радио и телевизоры, многие из нас стали образованными людьми и успешными в жизни гражданами.

Люди, выросшие в селе, в лоне его природы, лучше ориентированы в жизни и более подготовлены к ее испытаниям. Сельское общество научило нас уважать старших, быть примером для младших, ценить доверие, оказываемое тебе, и быть ответственным за порученное дело.

За весь период служения в органах милиции я старался быть сдержанным, учтивым как с подчиненными, так и в отношении с руководством. Старался быть уважительным и интеллигентным в общении с населением. Естественно, это прививали нам в школе, за что я благодарен своим учителям.

***– У Вас имеются множество грамот, наград и благодарностей за усердие, проявленное в процессе службы. Какие из них наиболее дороги и близки Вашему сердцу?***

– Я считаю, что наиболее ценным для меня является тот факт, что во время Олимпиады, проводимой в Москве, я попал в число лучших, которых отобрали для защиты охраны порядка в процессе его проведения.

Общеизвестно, что страны Запада тогда бойкотировали эту Олимпиаду. Можно было ожидать всё что угодно. Риск был очень высоким.

За весь период прохождения Олимпиады каждый из нас зорко следил за всем тем, что происходит в секторе, ответственность за порядок в котором был возложен на него.

Мы четко взаимодействовали с сотрудниками КГБ. Хотя не было оружия и спец средств и даже средств связи, языком жестов вза-



*С внуками*



*Свадьба сына Вадима*

имодействовали между собой. Несмотря на сложность ситуации, был обеспечен четкий порядок. За это мне выдали почетную грамоту, которой я горжусь по праву.

За всю службу я не имел порицаний и за это был награжден медалями «За безупречную службу» второй и третьей степени. Был награжден дипломом Куйбышевского облисполкома «Лучший участковый инспектор Куйбышевской области».

Как ветеран МВД был внесен в книгу почета ОВД города Новокуйбышевска, где написано: «За значительный вклад в борьбу с преступностью при охране общественного порядка, воспитание и профессиональную подготовку личного состава».

***– Говорят: «Работа и среда формируют специфические черты характера». Но все те, кто знает Вас, характеризуют как добрейшего человека, верного друга, любимого отца, дедушки и даже называли «интеллигентным ментом». Как могли сочетаться суровость профессии и такая мягкосердечность?***

– Во-первых, добрые отношения по достоинству оценивают не только люди, но и животные. Любой человек просто обязан быть человечным и находиться в рамках морали.

К сожалению, это не каждому и не всегда удается. Для этого нужны многие качества: внутренняя крепость, уверенность в себе, быть сдержанным и умение управлять собой и своими чувствами. Взрываться по пустякам, нахамить, нагрубить – легко и ничего не стоит. Но для того, чтобы быть добрым, сдержанным и спокойным, надо воспитывать в себе силу воли и умение уважать других. Только тогда придут к тебе почет и уважение. И самое главное – надо уметь ценить эти достижения и бережно хранить, так как разрушить их можно в одно мгновение.

***– Из-за напряженной, беспокойной работы у многих работников милиции тяжело складываются семейные отношения. Как вы при этом смогли построить гармоничные взаимоотношения в семье?***

– Наверно, мне сильно повезло в жизни в том плане, что жена оказалась способной создавать в семье покой, уют и сделать нашу жизнь комфортной. После напряженного трудового дня я всегда мог отдохнуть и набраться сил для дальнейшей службы. И я, в свою очередь, по достоинству оцениваю это и всегда благодарен ей.

Главная ценность для Фаата Талгатовича Мустафина – его семья, добрые отношения с родными, друзьями и авторитет в обществе, охране порядка в котором он посвятил свою жизнь.

Даже уйдя на пенсию, когда работал начальником службы охраны, он проявил себя также достойно и был награжден медалью «За многолетний добросовестный труд».

К сожалению, в жизни не так много людей, которые могут быть образцом порядочности и преданным своему делу высоким профессионалом. О таких, как Фаат Талгатович Мустафин, и об их службе невозможно сказать лучше слов песни:

*Наша служба и опасна, и трудна,*
*И на первый взгляд как будто не видна.*
*Если кто-то кое-где у нас порой*
*Честно жить не хочет,*
*Значит, с ними нам вести незримый бой.*
*Так назначено судьбой для нас с тобой –*
*Служба дни и ночи.*
*Если где-то человек попал в беду,*
*Мы поможем – мы всё время на посту.*
*Ну а если вдруг кому-нибудь из нас*
*Тоже станет туго –*
*Что ж, друг друга выручали мы не раз,*
*И не раз согрело нас в тяжелый час*
*Сердце, сердце друга.*
*Часто слышим мы упреки от родных,*
*Что работаем почти без выходных,*
*Что разлуки нескончаемы порой,*
*Встречи ненадолго.*
*Только снова поднимает нас с зарей*
*И уводит за собой в незримый бой*
*Наше чувство долга.*
*Наша служба и, опасна и трудна,*
*И на первый взгляд как будто не видна.*
*Если кто-то кое-где у нас порой*
*Честно жить не хочет,*
*Значит, с ними нам вести незримый бой.*
*Так назначено судьбой для нас с тобой –*
*Служба дни и ночи.*



# Укучыларына, хезмәтенә карата күңеле мәхәббәт белән тулы

***Сез укытучы хатын-кызны ничек күз алдына китерәсез икән? Мәсәлән, минем өчен ул чиста-пөхтә, тыйнак итеп киенгән, чәчләрен матур итеп җыйган, нурлы йөзле, елмаючан һәм шул ук вакытта җитди карашлы, таләпчән дә булырга тиеш.***

***Миләүшә Газимова.***

Самарның "Яктылык" мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшләүче Әгъзам кызы Румия Исмәгыйлева - нәкъ менә минем шушы таләпләремә туры килә торган мөгаллимә!

Ул һәрвакыт матур, зәвыклы киенгән, биек үкчәле туфлидан булыр. Аның ягымлы йөзеннән нур сирпелеп тора, елмаюы җанны эретеп җибәрә, һәм шул ук вакытта аңардан укытучыларга хас булган гадел таләпчәнлекне, эшлекле җитдилекне сизәсең.

"Бик тырышып, җанын-тәнен биреп эшли Румия ханым, бик ярдәмчел кеше, башка укытучыларга гел булыша, балалар да үзен яраталар", - диделәр миңа милләттәшебезнең хезмәттәшләре.

Румия апа белән аралашкач, бу сүзләрнең хак булуына тамчы да шигем калмады. Мәктәптәге хезмәте, укучылары турында сәгатьләп сөйли ала ул. Ә шул вакытта аның янган күзләрен күрсәгез икән!

Эшен шулкадәр яратып башкаргач, димәк, балачактан укытучы булырга хыяллангандыр, дип уйларсыз, бәлки, Румия ханым турында. Ә менә бер дә алай түгел шул! Мәктәптә математика фәнен яратып укыган кыз кечкенәдән хисапчы булырга теләгән. Туып-үскән Тупли авылында укуын тәмамлагач, Самарга килеп, план институтына документларын да тапшырган ул. Әмма, кайбер сәбәпләр аркасында, аларны кире алырга мәҗбүр булган.

Авылдан шәһәргә килеп, буш кул белән яңадан әйләнеп кайтып булмый бит инде. Шулай, иптәш кызының тәкъдиме буенча, алар икәүләп пешекчеләр әзерләү училищесына керергә булганнар.

"Мин мәктәптә гел "бишле" билгеләренә генә укыдым. Шуңа күрә училищега документларымны кабул иткәндә, аттестатымны күргән укытучылар гаҗәпләнеп куйдылар. Ә инде авылга кайткач, әнием дә, апамның ире - математика һәм музыка укытучысы, соңрак мәктәп директоры булган Әнвәр абый Зилитдинов та үземне каты ачуландылар.

Җизнәй, укытучым буларак, минем мәктәптә ничек укыганымны яхшы белә иде бит. Әлбәттә, аларның мине башка һөнәр иясе итеп күрәселәре килде.

Шулай итеп, мине авылдан җибәрмәделәр. Укытучылар җитмәгәнлектән, Әнвәр абый миңа авыл мәктәбендә эшләп карарга тәкъдим итте. "Үзем барысына да өйрәтермен, булышырмын. Бер ел эшләп кара әле, ошамаса, дүрт ягың - кыйбла", - диде ул миңа.

Бер ел башлангыч сыйныфта белем бирдем. Шунда мөгаллимә хезмәтенә шулкадәр гашыйк булдым ки, инде үземне башка һөнәрдә күз алдына да китерә алмадым.



Профессиональ белем алу ниятеннән Самарның социаль-педагогика көллиятенә (колледж) юл тоттым. Ул вакытта анда беренче милли төркем туплап маташалар иде. Мин шушында эләктем дә инде. Без биш татар, егерме чуваш кызы укыдык. Кулыма “башлангыч сыйныфлар һәм ана теле укытучысы” дигән, гел “бишле”ләрдән генә торган диплом алып чыктым.

1996 елда, укуымны тәмамлагач, мин инде Туплига белгеч буларак эшкә кайттым, башлангыч сыйныфларда математика фәнен укыттым, “Оста куллар” түгәрәген алып бардым. Башта дүртенче классны җитәкләдем. Ә бер елдан соң беренче сыйныф балаларын кабул иттем. Шушы укучыларымның берсе – Юлия Хөснетдинова бүгенге көндә безнең “Яктылык” мәктәбендә инглиз теле укытучысы булып хезмәт итә”, - дип исенә төшерә язмам герое.

Туплида эшләгән вакытта Румия ханым авылдаш егетенә кияүгә чыга, һәм 2000 елда алар Самар шәһәренә күченеп киләләр. Биредә аңа “Яктылык” мәктәбенә эшкә урнашырга тәкъдим итәләр. Шулай итеп, ул озынайтылган көн группасы тәрбиячесе эшенә керешә. Ә инде бер елдан соң беренче сыйныф балаларын җитәкли һәм башлангыч классларда математика, рәсем сәнгате, технология, музыка, тирә-як мохитне өйрәнү фәннәреннән белем бирә башлый.

“Ул вакытта укыту процессы шундый иде бит. Башлангыч сыйныфларда да төрле укытучылар укыта иде. Соңрак инде барлык дәресләрне дә бер мөгаллимә алып бара башлады”, - ди Румия Исмәгыйлева.

“Яктылык”та эшләгәндә ул югары белем ала - Самарның педагогика институтында психология бүлеген тәмамлый.

Быел милләттәшебез дүртенче сыйныф укучыларын укыта. Ә инде көзен, Аллаһы теләсә, беренче сыйныфка килүче малайлар-кызларны кабул итәчәк. Хәзер шимбә көннәрендә ул шушы балаларны мәктәпкә әзерли, үзләренә белем һәм әхлак нигезләрен өйрәтә.

***“Сезнеңчә, чын укытучы нинди булырга тиеш?”*** - дип кызыксындым әңгәмәдәшемнән.

“Иң беренчесе һәм иң мөһиме – аңарда балаларга карата ихлас һәм көчле мәхәббәт булырга, ул үз эшен чын күңеленнән яратырга тиеш.

Без бит укучыларга кисәтү ясаганда да, бераз ачуланганда да моны нәфрәт белән түгел, ә үзләрен әниләрчә яратып эшлибез, алар тагын да яхшырак, белемлерәк, тәртиплерәк булсыннар дип тырышабыз.

Әлбәттә инде, тирән гыйлем, һөнәрмәндлек, көч-куәт, дәрт таләп ителә.

Мөгаллимәгә төрле көтелмәгән хәлләрдән чыгу юлын таба белергә кирәк. Һәр дәрескә алдан әзерләнсәк тә, ул мәнә нәкъ без ниятләгәнчә генә бармый бит. Шуңа күрә аның барышында укытучы экспромтка да әзер булырга тиеш.

Укучыларга ачык йөз күрсәтү мөһим. Безне “Яктылык”ның беренче мөдире Хәридә ханым Дашкина шулай өйрәтә иде, рәхмәт үзенә. “Кызлар, эчегез тулы ут янса да, мәктәп бусагасын атлап кергәч, йөзегездә елмаю балкысын. Балалар сезнең начар кәефегезне күрергә тиеш түгел”, - дия иде ул. Һәм менә биредә 22 ел эшләү дәверендә мин аның шушы акыллы сүзләрен истән чыгармыйм.

Мөгаллимә хезмәтендә нарасыйларда укуга кызыксыну уятыр өчен иҗат та мөһим урын алып тора. Кечкенә балалар уен формасында, төрле кызыклы күрсәтмә әсбаплары кулланып үткәрелгән дәресләрне яраталар, шул рәвешле теманы яхшырак үзләштерәләр. Мәсәлән, мин математика булсынмы, рус теле булсынмы, әдәбият





булсынмы – һәр дәрестә иҗат өчен урын табам. Аларны рәсемнәр, кулдан ясалган ниндидер әйберләр белән баетам.

Кул эшләрен укучылар да бик ярата. Мин үзләренә шаблоннар әзерләп китерәм, һәм алар шулар буенча төрле нәрсәләр ясыйлар. Бу балаларга шулкадәр ошый ки, эшләрен бетермичә китәселәре килми, дәресләрдән соң калып утыралар. Хәтта башка сыйныфлардан да малайлар-кызлар безгә килеп кушылалар әле.

Мин элегрәк 5 - 8 сыйныфларда рәсем дәресләрен дә алып бара идем. Укучылар аларга да бик теләп, яратып йөрделәр.

Чын укытучыга тагын бер мөһим сыйфатка ия булырга кирәк – ул үз сыйныфы балаларын гына түгел, ә бөтен мәктәп укучыларын яратырга, аларны якын күрергә тиеш”.

***“Яктылык” башка мәктәпләрдән нәрсәсе белән аерылып тора, дип саныйсыз?”***

“Безнең мәктәптә тәрбиягә дә бик зур игътибар бирелә. Күпләрдән сезнең укучыларыгыз тәртипле, тыйнак, олыларга ихтирам күрсәтәләр, исәнләшмичә үтмиләр, дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Һәм бу, чыннан да, шулай. Аннары без дәрес үтте дә бетте, дип эшләмибез. Балаларның нинди гаиләдә тәрбияләнгәнен, аларның эчке халәтен, хәл-әхвәлен, кәефен белеп-тикшереп торабыз. Шәхси проблемаларында ярдәм кулын сузабыз. Без укучыларыбызга әниләредәй бит, безнең өчен чит-ятлар юк, һәрберсе үз балабыздай якын. Алар безгә ышаныч белдерәләр, серләрен дә ачып салалар.

Гомумән, “Яктылык”та өйдәгечә мохит хөкем сөрә, дияр идем. Бередә ямьле, чиста, җыйнак, үз милләт кешеләрең. Аллаһыга шөкер, нарасыйлар мәктәптә үзләрен уңай хис итәләр”.

***“Белеме сайрак булган, әмма зур тырышлык куеп укыган балалар була бит. Аларга тырышлыклары өчен билгене арттырып куярга ярыймы?”***

“Укучымның тырышлыгын күрсәм, мин аны, әлбәттә, дәртләндерәм. Билгеләре яхшы булмаган, әмма бик нык тырышканнарны башкаларга үрнәккә дә куям әле. Гомумән, мин балаларга үз хаталарын төзәтү мөмкинлеген бирәм. Минә “алма пеш – авызыма төш”, дигәннәре белән эшләргә авыр. Кайберәүләргә Аллаһыдан сәләт бирелә, әмма алар ялкаулыклары аркасында уңышларга ирешә алмыйлар. Ә икенчеләре, киресенчә, алай ук башлы да түгелләр, ә тырышып-тырмашып, күп нәрсәгә өйрәнәләр, ниятләренә ирешәләр. Иң мөһиме - теләк кирәк бит ул”.



*Румия ханым ире Йосыф һәм кызы белән.*

***“Балаларны укыту, тәрбияләү – авыр хезмәт. Эшегездән туйган чакларыгыз буламы?”***



“Дөресен әйткәндә, юк. Киресенчә, мәктәптә күңелем ял итә минем. Яратып эшләгәнгә шулайдыр инде ул. Хезмәтем мине рухландыра, илһамландыра, көч-куәт бирә.

Иртән мәктәпкә килеп, укучыларымның самими йөзләрен күргәч, аларның: “Апа, хәерле иртә!” - дип яңгыравык тавыш белән исәнләшкәннәрен, шау-гөр килгәннәрен ишеткәч, канатланып китәм, хәтта аруым, күңелсез уйхисләрем юкка чыга.

Каникуллар вакытында аларны сагынып бетәм мин. Күңелсез булып китә, тизрәк эшкә барасы килә”.

***“Румия апа, ялгышмасам, сез мәктәпнең уку-укыту бүлеге мөдире дә булдыгыз бит?”***

“Әйе, җиде ел башкарып килгән бу хезмәттә остарып та беткән идем инде. Тик ике вазифаны алып баруы авыр булды шул. Шуңа күрә мин, кәгазь эшеннән баш тартып,

күңелемә якынрак булган укытучы хезмәтен, яраткан укучыларымны сайлап алдым”.

***“Утыз ел буена балаларга белем бирүче тәҗрибәле мөгаллимә буларак, яшь укытучыларга нинди киңәшләр бирер идегез?”***

“Бөтен күңелләрен биреп, тырышып, җиренә җиткереп эшләүләрен теләр идем. Балаларга карата игътибарлы булсыннар, хата җибәрсәләр, аны төзәтергә тырышсыннар иде.

Тәҗрибәле, оста мөгаллимнәр белән һәрдаим элемтәдә торып, аларның үгет-нәсыйхәтләренә колак салып хезмәт итсәләр, ишетсәләр, тыңласалар, үзләре дә күп нәрсәгә өйрәнәчәкләр һәм укучыларын да күп нәрсәгә өйрәтә алачаклар. Мин әле бүген дә үземнән олырак укытучылар белән аралашып, киңәшләшеп эшлим”.

***“Һөнәрегездә сезне укыткан кайсы укытучылардан үрнәк алдыгыз?”***

“Безнең бөтен мөгаллимнәребез дә югары һөнәрмәнд, үз эшенең осталары иде. Беренче укытучым Җария апа Дәүләтшинаны бик сагынам. Математика һәм музыка дәресләрен алып барган Әнвәр Зилитдинов, тарихны укыткан Габдулла Насыйров, физика фәненнән белем биргән Наил Гыйматдинов, рус теле һәм әдәбияты укытучысы Равилә Зилитдинова, химия белән биология серләрен төшендергән Изидә Хуҗина - барысы да минем өчен яхшы үрнәк булдылар. Бу акыллы, тәҗрибәле кешеләрдән күп нәрсәгә өйрәндем, үземдә аларның күркәм сыйфатларын тәрбияләргә тырыштым”.

***“Румия ханым, балалар хөрмәтен ничек яуларга?”***

“Мин – укытучы бит!” – дип, үз-үзеңне әллә кемгә куеп йөрмәскә. Укучылар белән уртак тел табар өчен, замана белән бергә атларга, аларның мавыгулары белән кызыксынырга.

Авылда эшләгәндә дә, “Яктылык”та да мин балаларны экскурсияләргә, лагерьларга алып бара идем. Мәктәптән тыш аралашу мөнәсәбәтләрне тагын да якынайта бит ул.

Әйтәм бит, укучылар безгә үз балаларыбыздай. Аларны кайгыртасың, өс-башын күзлисең, бер



*Кызы Айгөл.*



*Румия ханым әнисе һәм кызы белән.*

икмәк сыныгы белән дә бүлешәсең.

Һәм, алда билгеләп үткәнемчә, иң мөһиме – балаларны чын күңелдән яратырга, күңелеңне биреп эшләргә кирәк.

Нарасыйлар үзләренә карата ихлас мөнәсәбәтне шунда ук сизеп алалар һәм сиңа да шулай ук җавап бирәләр".

***"Сыз укыткан малайлар-кызлар арасында башка милләт вәкилләре бармы? Алар белән эшләгәндә авырлыклар тумыймы?"***

"Әйе, кыргызлар, үзбәкләр, казахлар бар. Үзләрен укытканда, шөкер, бер кыенлык туганы юк.

Тырыш балалар, безнең телдә сөйлиләр, татар телен яратып үзләштерәләр".

***"Мәктәптәге коллективыгыз турында нәрсә әйтә аласыз?"***

"Коллективыма шатланып туя алмыйм мин. Без бик дус, аралашып, ярдәмләшеп яшибез. Шушы еллар эчендә туганнардай булып беттек инде. Бер-беребезнең гаиләләрен яхшы беләбез.

Милләттәшләрең белән бергә, бердәм булып, ана телендә сөйләшеп эшләве рәхәт бит ул!

Беренче мөдиребез Хәридә ханым Дашкина да, бүгенге директорыбыз Радик әфәнде Газизов та – оста җитәкчеләр, акыллы, гыйлемле, күркәм холыклы, бай күңелле кешеләр".

***"Укытучы ул белем бирүче генә түгел, ә тәрбияче дә бит әле. Укучыларыгызга нинди үгет-нәсыйхәтләр сеңдерәсез?"***

"Әти-әнине зурларга, олыларны хөрмәт итәргә өйрәтәм. Дөреслекне сөйләгез, алдамагыз, гадел, кешеләргә ярдәмчел булыгыз, дип әйтеп киләм.

"Ялгышлык җибәрү алай куркыныч түгел. Ә менә шул хатаңны төзәтмичә калдыруы куркыныч", - дип нәсыйхәт бирәм".

***"Румия ханым, гаиләгез белән дә таныштырып үтсәгез иде".***

"Ирем Йосыф белән без бер авылдан, бер мәктәптә белем алдык.

Ул миннән ике яшькә генә олырак, абыем белән укыды. Бергә гомер итүебезгә быел 23 ел тулды.

Миңа шушындый ир бүләк иткәне өчен Аллаһыга Тәгаләгә мең шөкер кылам. Бер-беребезне хуплап, ярдәм итешеп яшибез. Үз көчебез белән, бергәләп йорт салдык.

Хатын-кызның бәхете ирдән, диләр. Бу хак сүзләр икән. Иремә



Раббыбыз исәнлек, озын гомер бирсен. Мин аңа барысы өчен дә рәхмәтле.

Бердәнбер кызыбыз, күз нурыбыз Айгөл дә, әлхәмдүлилләһ, безне шатландырып кына тора.

Ул "Яктылык"та үсте, дисәм дә ярый. Мин шимбә көннәрендә дә эшләгәч, аны ике яшеннән үзем белән мәктәпкә алып йөри идем. Ул шунда арттагы партада утырып, мөгаллимә хезмәтен балачактан күреп үсте. Шуңа күрәдер дә, минем эздән китеп, укытучы һөнәрен сайлап алды.

Бүгенге көндә Самарның педагогика университетында белем ала, башлангыч сыйныфлар һәм инглиз теле укытучысы булачак, Аллаһы теләсә.

Айгөл бик яратып, "бишле" билгеләренә генә укый, югары стипендия ала. Университетка үз көче белән, бюджет бүлегенә, конкурс аша узып керде.

"Яктылык"та да тырышып белем алды ул. Татарча җырлады, биеп йөрде. Ана телен яхшы белә.

Миннән үрнәк алып, миңа карап, мөгаллимә һөнәрен сайлаучылар булганга чын күңелемнән шатланам мин. Минем апамның кызы Резеда да быел кулына диплом ала, инглиз теле һәм икътисад дәресләрен укытачак".

***"Укытучының эше бетәрлек түгел бит ул. Сезнең буш вакытларыгыз аз каладыр инде. Андый чакларда нәрсә белән шөгыльләнергә яратасыз? Берәр нинди мавыгуыгыз бармы?"***

"Китаплар укыйм. Миңа һәрвакыт нинди дә булса яңалык ачарга гына булсын! Рәсем ясыйм, кул эшләре белән шөгыльләнәм.

Үз йортыбыз белән яшәгәч, мәшәкать җитәрлек.

Бакчада мәш киләбез. Аеруча ирем бу эшләрне бик ярата инде. Мин җәй буе кайнатма ясыйм, компот ябам.

Гаиләмне татар милли ашлары белән сыйларга ошый миңа.

Табигатькә чын күңелдән гашыйк кеше мин.

Бакчага чыгып, алмагачларны, караҗимеш, өрек агачларын, чәчкәләрне сыпырып, алар белән сөйләшеп-серләшеп йөрим. Безнең мәрхүмә әни шундый иде".

***"Укытучы булуыгызга сез бәхетлеме?"***

"Әйе, бик тә бәхетле, чөнки бу – минем ихластан яратып, ләззәтләнеп башкарган хезмәтем.

Балаларга белем бирү, үзләрен тәрбияләү – зур эш бит ул. Һәм шуның уңай нәтиҗәләрен күрү безнең өчен, әлбәттә инде, олуг сөенеч булып тора.

Нарасыйларның тырышып укыганнарын, яхшы тәртипләрен, белемгә омтылуларын, миңа карата рәхмәтле, ихтирамлы булуларын күргәч, Аллаһыга шөкер, гомерем заяга узмый, дип уйлап куям".

***"Киләчәктә дә шушы бәхетегез кимемәсен, Румия апа. Укучыларыгызны тирән белемле, лаеклы кешеләр итүдә Аллаһы Тәгалә сезгә Үз ярдәмен бирсен".***

# А может быть, буртасы...

## Откуда пришел и куда делся самый загадочный народ Поволжья

***Буртасы – объединение племен, обитавшее по правому берегу Средней Волги. Впервые упоминаются арабскими авторами в IX веке, в русских литературных памятниках – с XIII и до XVII века. О том, кто является их предками и куда они исчезли, ученые до сих пор ведут жаркие дискуссии.***

*Дмитрий ГРЕКОВ*



### Финны, угры или тюрки?

Буртасы появились на территории будущей Пензенской области после разгрома князем Святославом Хазарского каганата и жили чересполосно с мордвинами и булгарами. Некоторые историки предполагают, что они пришли в Поволжье из региона между Уралом и Эмбой и подчинили в Посурье местных мордвинов. Буртасам принадлежали Юловское и Золотаревское городища – последнее, возможно, идентично с городом Буртас у арабского писателя Ибн Саида.

Касательно происхождения буртасов учеными высказано несколько гипотез. Многие авторитетные востоковеды считали их частью мордвы. Персидский хронист Рашид ад-Дин упоминал буртасов в одном ряду с мухшей (мокша) и арджанами (эрзя). Археологические памятники этого народа также находили на территориях расселения мордвы – однако они отличались от мордовских. В ряде исследований конца XX века гипотеза была скорректирована – сторонники финского происхождения буртасов стали считать их не предками или частью мордвы, а самостоятельным вымершим народом.

**Другая часть исследователей настаивала (и настаивает), что буртасы – тюрки. Это было основано на помещении арабскими авторами Тахиром ал-Марвази и Гардизи сведений о них в главу о тюрках, а также рассказы о том, что их верования похожи на религию огузов. Кто-то считает их предками чувашей, татар-мишарей и части башкир.**

Однако погребальный обряд буртасов, описанный у Ибн Русты, коренным образом отличается от погребального обряда огузов, описанного Ибн Фадланом. Поэтому появилась угорская теория, адепты которой считают буртасов частью мадьяр, оставшихся в Поволжье, которые впоследствии были «булгаризованы» в Пензенском крае – Буртасия стала частью Волжской Булгарии. Степные группы буртасов попали в зависимость от кыпчаков, а лесные – от волжских булгар.

Позже других появилась гипотеза об иранском происхождении. Специалисты отыскали ряд осетино-мордовских параллелей в погребальной обрядности и костюме. Сами этниконы «мордва» и «удмурт» в русском языке указывают на происхождение из фарси. Однако предположение о заимствовании названия Казань от осетинского «къадзонаег» большинством исследователей воспринято скептически.

К сожалению, от языка буртасов ничего не осталось. В арабских источниках отмечено, что он отличался от булгарского и хазарского. То есть можно определенно говорить, что в IX–X веках буртасы еще не были тюрками.

### Кто они такие?

Происхождение этого народа уходит своими корнями в седую древность. В этногенезе азербайджанцев приняли участие народы, в разное время жившие на территории обширного горного региона, имя которому – Кавказ. Среди них можно отметить население государства Мана (Манна), существовавшего в первой половине I тысячелетия до нашей эры в Передней Азии. Соседями Маны являлись такие сильные государства древности, как Урарту и Ассирия, с которыми правителям Маны приходилось воевать. В дальнейшем эта территория попадает в зависимость от Мидии. Впоследствии сама Мидия была завоевана персами и вошла в состав их огромной державы. Когда на Восток пришел со своими войсками Александр Македонский, Мидией правил сатрап Атропат. Он признал Александра царем и сохранил свой пост. При разделе державы Александра Македонского после смерти полководца Атропат сумел сохранить власть лишь над северной частью своей страны, которая стала называться Мидия Атропатена. В дальнейшем слово Мидия уже перестало употребляться. В VII веке территория Атропатены была завоевана арабами и стала называться Азербайджаном.

Следует указать также население еще одного древнего государства – Албании Кавказской, которое существовало в последних веках до нашей эры – первом тысячелетии нашей эры. Об этом государстве упоминают античные источники. На его территории проживали разные племена, одним из которых являлись албаны. Со временем их название распространилось и на другие племена.

В XI–XIII веках в основном завершилось формирование азербайджанской этнической общности в результате расселения в этих местах тюркских племен булгар, хазар, печенегов, тюрок-огузов (сельджуков) и других, которые ассимилируют прежнее население.

В последующее время данная территория служит объектом борьбы между Ираном и Турцией. В первой половине XIX века Северный Азербайджан входит в состав Российской империи. В официальных документах конца XIX – начала XX века азербайджанцев обычно называли тюрками или татарами.

В 1918–1920 гг. существовала Азербайджанская Демократическая Республика, затем была образована Азербайджанская Советская Социалистическая Республика, которая сначала входила в Закавказскую федерацию, а затем уже непосредственно в СССР как союзная республика. В 1991 году было образовано независимое государство Республика Азербайджан.

Теперь рассмотрим основные аспекты традиционного хозяйства и культуры азербайджанцев.

В традиционном хозяйстве сочетаются земледельческие и животноводческие традиции. Получили распространение зерновые культуры (пшеница, рожь, ячмень, рис), а также виноград, хлопок, развилось шелководство. В горных и предгорных районах большой размах получило отгонное овцеводство. Из традиционных ремесел и промыслов следует отметить ковроткачество, ювелирное дело, выделку кожи, валяние шерсти, гончарство, обработку дерева и камня, вязание, ткачество и др.

Сельские поселения обычно имеют разбросанную планировку, в горах получили распространение террасные, плотно застроенные дома. Основными строительными материалами служили камень и обожженный кирпич, в некоторых местах строили деревянно-земляные дома, а также саманные избы с плоским верхом. Часто встречались двухэтажные жилища, где верхний этаж являлся собственно жилищем, а нижний отводился под помещения для скота и хозяйственных нужд. Такое деление в некоторых случаях сохраняется и сейчас.

Женский традиционный костюм включал в себя рубаху, широкую юбку, а также архалук – своеобразную кофту с вырезом на груди, поверх которой надевался пояс. Под юбку надевали присборенные шаровары, обувью служили туфли с загнутыми носками без задников.



Головным убором являлась бархатная тюбетейка, поверх которой надевали платок, а пожилые женщины использовали и чалму. Мужской костюм также включал архалук и



*Ширван Керимов – лидер самарских азербайджанцев*

шаровары, кроме того – верхнюю одежду чоха с газырями на груди, кожаную обувь и шапку из меха.

Азербайджанская кухня отличается разнообразием молочных, мясных, мучных и овощных блюд. Важное место в питательном рационе занимает хлеб из пшеничной муки, выпеченный в глиняном очаге тендыре или на железном листе садже. В горных районах получил распространение хлеб из ячменной или просяной муки. К мучным блюдам относится гутаб – род пирожков с зеленью или с мясом. Мясные блюда преимущественно готовились из баранины. Можно отметить такие блюда, как долма – кушанье из капустных и виноградных листьев, фаршированных мясом, рисом и зеленью. Большую популярность получили разные виды плова. Среди напитков – чай, шербет, кислое и свежее молоко.

Азербайджанцы относятся к мусульманским народам. В их фольклоре встречаются реликты древних верований, разные сверхъестественные существа имеют аналоги в татарском и башкирском фольклоре.

Получило развитие музыкальное народное творчество. Крупные вокально-инструментальные произведения – мугамы в своей основе восходят к древним музыкальным традициям Востока. У азербайджанцев, как и у казахов, турок, татар, башкир и других тюркских народов. Распространены предания о седобородом деде Коркуде, воспевавшем подвиги богатырей – его образ восходит к огузскому эпосу.

Яркая и богатая праздничная культура. Одним из наиболее известных традиционных праздников является Навруз (Новруз), знаменующий наступление весны и нового года. Отмечаются мусульманские праздники.

Расселение азербайджанцев в России во многом было связано с освоением нефтяных и газовых месторождений. Еще до начала Великой Отечественной войны советское руководство запланировало создание в Урало-Поволжье новой нефтяной базы – «второго Баку». В книге «Дружба народов на Самарской земле», в разделе, посвященном азербайджанцам, рассказывается о бакинце Исмаиле Султанове, работавшем в Сызрани начиная с военных лет. В суровое военное время, когда сызранские нефтяники оказались отрезанными от Баку, откуда они получали необходимое оборудование, Султанов возглавил ремонтно-механический завод и в короткий срок наладил производство оборудования, необходимого для нефтяной промышленности.

Многие самарские азербайджанцы приехали в наш край уже после распада СССР. Они живут в разных населенных пунктах области.

В 2003 году создана Региональная общественная организация «Лига азербайджанцев Самарской области», которая регулярно проводит множество мероприятий, направленных на сохранение и поддержание традиционной культуры своего народа. Именно она подготовила раздел об азербайджанцах в упомянутой книге «Дружба народов на Самарской земле», где, в частности, названы и архитектурные достопримечательности Азербайджана, в том числе Девичья башня в Баку – один из символов города и страны.

С азербайджанской культурой можно также познакомиться в этнокультурных комплексах.

# Сабан туе – ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ СИМВОЛЫ

***4 июньдә Самарның Гагарин паркы (быел 26нчы мәртәбә), гадәттәгечә, татарлар карамагына биреленде. Иртән-иртүк Ракушка сәхнәсенә бара торган сукмакның ике ягында да пылау-шашлыклар өчен учаклар ягылды, оештыручылар, артистлар йөгерешеп йөрде, тагын ике сәхнәне танылган ансамбльләребез биләде: "Ялкынлы яшьлек" балалар мәйданчыгында урнашкан булса, "Идел", һәрвакыттагыча, көрәш мәйданына алып баручы ике сукмак чатында урын алды.***

*Эльмира ШӘВӘЛИЕВА,*
*Тилав РАСУЛ-ЗАДЕ.*






Өлкә Сабан туеның төп сәхнәсендәге тамашаны Фәрзанә Мәхмүтова һәм Ринат Азизов алып бардылар. Гали авылының - "Мирас", Иске Ярмәк авылының - "Ак каен", Нефтегорск шәһәренең "Мирас" ансамбльләре чыгышларыннан соң Сабан туеның төп спонсоры булган "Дуслык" иҗади-иҗтимагый җәмгыяте вице-президенты Минәхмәт Хәлиуллов Сабан туен ачып җибәрде. Сабан туе әләмен күтәрү бурычы ЦСКА хоккей командасы уенчысы Таһир Мингачевка һәм "Яктылык" мәктәбендә гел «бишле» билгеләренә укучы, татар теле олимпиадалары җиңүчесе Әминә Абдрәхимовага тапшырылды. Шуннан соң "Яктылык" татар мәктәбен тәмамлаган укучылар "Зәкә-зәкә" биюен башкардылар. Бу гадәти бию түгел иде, чөнки бүгенге сәхнәгә төрле елларда бу биюне биегән җыелма команда чыкты. Моның белән хореографлар әле генә 25 еллык юбилеен билгеләп үткән "Яктылык" мәктәбендә, буыннар алмашынып торуга карамастан, татар традицияләре, җыр-биюләре яши һәм буыннан буынга күчеп килә, дип әйтергә теләгәннәрдер, мөгаен.

Татарстанның Азнакай районы артистлары да чын профессиональ программа күрсәттеләр. Сәхнәдә рус телендәге җырлардан торган 80нче еллар дискотекасы, татар халык җыр һәм биюләре күзләрне камаштырырлык матур иде. Аларның мәйданчыгында да көне буе тамаша барды. "Татар йорты"нда төрле бизәнү әйберләре, чиккән калфаклар, милли уенчыклар, савыт-саба сатыла иде. Азнакайлылар имән түмәрдә коймак кыздыру буенча мастер-класс та оештырганнар. Бу болай эшләнә: түмәрне 8 - 10 җирдән аркылыга түгел, буйга кисеп, ярыклар ерырга, уртасында тишек ясап, учак ягарга һәм, түмәр кызгачрак, өстенә таба куярга да тотен исе килеп торган коймак пешерергә була. Мәшәкате









дә, тәтене дә күп, ләкин дачаң утсыз һәм газсыз булганда, бу ысул да ярап тора, дигән нәтиҗә ясадык.

Рәтләр буенча йөргәндә 68 яшьлек Александр Васильевич белән танышып киттек. Ул һөнәре буенча тимерче булган, пенсиягә чыкканчы автомашина кузовларын ремонтлау белән шөгыльләнгән. Ә лаеклы ялга чыккач, агач уенчыклар ясый башлаган. Үзе яраткан уенчыгы сыбызгы-сандугач. Ул аны табигый материаллардан ясый. Сандугач сайрап җибәрсен өчен, эченә су салырга һәм сызгыртырга гына кирәк. Бәясе дә кыйбат түгел, 200 сум гына. Шулай ук ул агач пычак-кинжаллар, ату кораллары да ясый.

- Мин үзем рус кешесе булсам да, Сабан туен көтеп алам. Бирелдә туганнар, дуслар җыелып бәйрәм итә. Шунысы куандыра, бәйрәмне төрле милләт кешеләре дә үз итеп киләләр, бииләр, җырлыйлар, күңел ачалар. Товарларыбыз сатылып бетмәсә дә, бик кайгырмыйбыз, башка авыл-шәһәр Сабан туйларында да балалар безне көтеп алалар, - ди ул.

- Кемгә пылау, тәмле, майлы пылау! - дип кычкырып тора Федор исемле бер урыс. Бәясе - 250 сум! Салаты да, чәе дә комплектта!

Федор татарлар үз иткән Красный Яр районында яши икән. Һөнәре буенча повар.

- Мин конкурс-фестивальләрдә, милли бәйрәмнәрдә катнашырга яратам. Анда төрле милләт кешеләре белән аралашырга, холык-фигылен аңларга мөмкин. Сабан туенда бигрәк тә күңелле була – спорт дисеңме, җыр-бию дисеңме, интеллектуаль уеннар дисеңме... Яратам мин татарларны, эш сөючән һәм чиста-пөхтә халык алар.

Хәләл колбаса, казылык сатып торган Рамил Ишмаев бирегә Мордовиядән ала килгән. Аларның берничә буын ата-бабалары казылык ясый икән. Ит продукциясен зур кибетләргә дә куеп сата, Сабан туйларына йөрергә дә иренми:

- Сабан туйларында үзебезнең хәләл ризыкларны тәкъдим итү мөмкинлеге бар. Ул бит - йөз процентка табигый продукт. Бәясе, авырлыгына карап, 250 - 1000 сумга төшә. Күбрәк алсаң да була, чөнки озак саклана.

Вера Михайловна исемле рус хатыны рәхәтләнеп татар биюләренә сиптергәнен карап тордым да янына килергә булдым.

- Мин Казанда туып-үстем, шуңа күрә татар җырларын, бию көйләрен яратам. Шуларны сагынып, бу бәйрәмгә ел саен киләм, балачагыма кайткан кебек булып китә, - дип аңлатты ул татар музыкасын яратуының сәбәбен. - Кызганычка, елына бер генә мәртәбә тәти миңа мондый бәйрәмнәр!

Казахстанның Күмертау баянчысы Артем Ухановның чыгышы да Самар татарлары өчен яңалык булды - “Играй, гармонь!” Бөтенроссия конкурсының Гран-при бүләге иясе үзен бик оста баянчы итеп танытты. “Радость планет” халыкара фестивале лауреатлары, “DagDance” кавказ биюләре мәктәбенең чыгышы да Сабан туе сәхнәсендә көтелмәгән хәл иде. А барысын бергә җыеп карасаң, татар Сабан туе Самар якларында яшәүче төрле милләт халыклары арасында дуслык мөнәсәбәтләре урнашуын күрсәтә түгелме?

Сабан туе мәйданнарын карап йөргән арада сәхнәдә инде бүләкләүләр башланган. Ел да тапшырылып килүче Фатыйх Мортазин премиясе гомерен татар милли оешмалары эшчәнлегенә, Самарда Җәмигъ мәчетен төзү эшенә багышлаган Җәмил хаҗи Вәлиуллинга, өлкәбездә татар милли мәгарифен торгызу эшенә зур өлеш керткән мәрхүм Дамир Гатинга һәм утыз елдан артык гомерен Сызранның “Туган тел” җәмгыятенә, ислам дине нигезләрен укытуга багышлаган Галиулла Габдерәшитовка тапшырылды. Соңгысына бүләкне Сызран Сабан туенда бирделәр.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, Аппарат җитәкчесе Фәргать Латыйпов утыз ел буе

“Бердәмлек” газетасы хәбәрчесе булып эшләгән, ә соңгы өч елда газетаның баш мөхәррире вазифаларын үтәгән Эльмира Варфоломееваны һәм “Идел” татар эстрадасы ансамбле җитәкчесе Мидхәт Әминовны “Татар халкы алдындагы казанышлары өчен” Бөтендөнья татар конгрессы медальләре белән бүләкләде. “Туган тел” өлкә татар җәмгыяте президенты Ильяс Шәкүров Самарда балалар өчен “Лидерлар мәктәбе” оештырган Тәлгать Мортазинның, Руфинә Зәйнуллинаның, Айнур Вахитовның, Дания Биктимерованың, Эльмира Мифтахованың, Фәрзанә Мәхмүтованың казанышларын Рәхмәт хатлары белән билгеләп үтте.

Бу юлы Сабан туен ачу түгел, ябу тантанасына килеп өлгергән Губернатор Дмитрий Азаровка татар көрәшен күзәтергә, җиңүчеләрне котларга мөмкин булды.

Аннан хөрмәтле кунаклар - губернатор Дмитрий Азаров, шәһәр мэры Елена Лапушкина, мөфти Талип хәзрәт Яруллин, БТК вәкиле Фәргать Латыйпов, Азнакай районы җитәкчесе Марсель Шәйдуллин, Самар өлкәсе милли-мәдәни оешмалары җитәкчеләре сәхнәгә күтәрелделәр һәм халыкны бәйрәм белән котладылар.

- Мин барыгызны да шушы матур бәйрәмегез белән котлыйм, - диде губернатор. - Сабан туена шушы кадәр күп кеше җыелганга бик шатмын. Өлкәбез халкы ата-бабаларының милли-мәдәни мирасын кадерләп саклый. Арабызда төрле милләт, төрле дин кешеләре бар, һәм без барыбыз да бер уй-теләк белән яшибез – туган җиребез имин, чәчкән уңышларыбыз мул булсын. Сабан туе күптән инде төрле милләт халыклары дуслыгы символы булып хезмәт итә. Бу инде - безнең уртак казанышыбыз, яңа традициябез.

Губернатор “Яктылык” татар мәктәбен дә 25 еллык юбилее белән котларга онытмады. Шулай ук татар милли хәрәкәтенә бик зур өлеш керткән Шамил Баһаутдиновны - “Халыклар дуслыгын ныгыткан өчен” Мактау билгесе белән, “Дуслык” җәмгыяте директоры Винер Нурмөхәмитовны “Халыклар дуслыгын ныгыткан өчен” Рәхмәт хаты белән бүләкләде. Шамил Сәлиметдин улы июльнең берендә үзенең 80нче туган көнен билгеләп үтәчәк. Без барыбыз да аны туган көне һәм югары бүләк алуы белән котлыйбыз һәм сәламәтлек телибез.

Азнакай районы башлыгы Марсель Шәйдуллин, мөфти Талип хәзрәт Яруллин да бәйрәм сәхнәсеннән изге теләкләрен җиткерделәр. Әлеге Сабан туеның төп оештыручысы булган Фәхретдин Канюкаев та халыкны бәйрәм белән котлап, авыл Сабан туйларына чакырды. Ә үзенең туган авылы Мәчәләй Сабан туенда шашка уены буенча чемпионат оештырылачагы турында белдерде, губернаторны да анда кунакка чакырды, бәйрәмне оештырырга ярдәм итүчеләргә рәхмәтләрен җиткерде.

Менә шуның белән Ракушка сәхнәсендә Сабан туе кинәт кенә тәмамланды да куйды. Дмитрий Азаров Сабан туена төштән соң гына килү сәбәпле, батырны бүләкләү һәм зурлау тантанасы көрәш мәйданына күчерелгән икән. Махсус белдерү булмаганлыктан, күпләр көткән батырны бүләкләү тантанасын күрми калдылар. Сабан туен оештыручыларның берсе булган Винер Нурмөхәмитов бу сорауга комментарий бирде: “Киләчәктә мондый хәлләр кабатланмас, батырларны бүләкләү тантанасы кайда булачагын алдан әйтеп куярбыз”, - диде.

Соңыннан билгеле булганча, бәрән белән мотоциклны Казан көрәшчесе Динар Кәримуллин алып киткән. Ул Лаеш районының спорт мәктәбендә тренер-укытучы булып эшли, халыкара спорт остасы дәрәҗәсенә ия.

## Сызран Сабан туе

Шул ук көнне Сызранның Горький исемендәге паркында да көтеп алынган бәйрәм гөрләп узды. Сызран шәһәре милли-мәдәни автоно-









миясе рәисе Ринад Шәрәфетдинов сүзләренә караганда, быел бәйрәмгә кételгәннән дә күбрәк халык җыелган. Чакырулы кунаклар да күп булган: Татарстанның төзелеш һәм торак-коммуналь





хуҗалык министры Марат Айзатуллин, Казанның Высокогорский районы башлыгы Равил Хисаметдинов, Сызран шәһәре башлыгы Анатолий Лукиенко, аның социаль эшләр буенча урынбасары Татьяна Журкина, милли автономиягә ярдәмгә килергә һәрвакыт әзер булган милләттәшләребез - Радик Бәхтияров, Вадим Шабанов, Самардан аерым миссия белән килгән Рамил Хәлиуллов һәм башкалар.

Нәкъ менә Рамил Минәхмәт улы өлкә милли-мәдәни җәмгыятьләре исеменнән Сызранның атаклы гражданины, Россия Федерациясенең атказанган очучысы, “Самар өлкәсенең мактаулы татары”, күп еллар буе “Туган тел” мәдәният үзәге рәисе булып эшләгән Галиулла ага Гәбдерәшитовка Фатыйх Мортазин исемендәге премияне һәм медален тапшырды. Шулай ук Рәис ага Бигловның татар телендә язылган һәм күптән түгел генә басылып чыккан “Сызран – иҗат бишегем” китабы презентациясе дә булды.

- “Дуслык” җәмгыяте президенты Фәхретдин Канюкаев та Сызран Сабан туен оештыруга гел ярдәм итеп тора, - дип сөйли Ринад Шәрәфетдинов. - Сызранның “Сила воли” иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Радик Шафиев җәмгыятебезнең үзәк мие булса, шәһәр Думасы депутаты Илдар Мәҗитов - төп оештыручысы. Ул гел безнең башлангычларны күтәреп ала һәм ахырына җиткерергә булыша.

Сабан туе Сызран балаларының симфоник оркестры чыгышы белән башланып китте. Аңа башка коллективлар да кушылды, Казан артистлары бигрәк тә күңелләребезне күтәреп җибәрде. Көрәш мәйданында төрле милләт кешеләре көч сынашты. Ләкин төп призны Ульян өлкәсе, Урта Терешка авылы батыры Азат Әсәдуллин яулады. Бәрәнгә өстәп, аңа “Кёрхер” машина юу аппараты да тапшырылды, дип тәмамлады әңгәмәбезне Ринад Шәрәфетдинов.

## Тольятти Сабан туе

5 июньдә Тольяттиның Җиңү паркында да 35нче юбилейлы Сабан туе уздырылды. Хәбәрчебез Зөлфия Галиханова татар халык бәйрәменә килгән кунаклар саны ишле һәм дәрәҗәле булуына сөенечен белдерде.

- Сабан туен Тольятти шәһәр милли-мәдәни автономиясе рәисе Ислам хәзрәт Гомәров ачып җибәрде. Ул автономия эшчәнлеге, үткәрелеп килә торган чаралар турында берничә сүз әйткәннән соң, сүзне кунакларга бирде. Мөфти Талип хәзрәт Яруллин да халыкны Сабан туе белән котлап, бәйрәмгә хәер-фатихасын белдерде.

Юбилейлы Сабан туенда котлаулар күп булу гадәти хәл инде ул. Шәһәр башлыгы Николай Ренц, Самар губерна Думасы депутатлары Екатерина Кузьмичева, Владимир Бокк, Тольятти шәһәр Думасы депутаты Николай Остудин, Татарстанның Балык Бистәсе районы башлыгы Илдар Тажетдинов, районның Башкарма комитеты җитәкчесе Роман Исланов һәм башкалар милли бәйрәмебезгә, татар халкының уңган-булганлыгына, эшчәнлегенә, Тольяттида яшәүче төрле милләт халыклары дуслыгына тиешле бәя биреп, бәйрәмне хуплап күтәрделәр.

Тантаналы ачыштан соң сәхнәдә Тольяттиның “Идел” ансамбленә йөрүче балалар, яшьләр һәм олы яшьтәге һәвәскәрләр ике сәгатьлек концерт куйдылар. Соңында сәхнә Сызран һәм Балык Бистәсе үзешчән коллективларына, сәнгать осталары Нияз Җәләловка һәм Римма Никитинага бирелде. Халык аларга кушылып җырлады һәм биеде, бер өлеше сәүдә рәтләре буйлап йөрде, шашлык-пылау белән сыйланды.

Ә көрәш тәмамлангач, бөтен халык та диярлек көрәш мәйданына елышты. Батыр булып татарстанлы Муса Галләмов танылуына барысы да хуплау хисләре белдерделәр. Танылган көрәшче Муса Галләмов, үзе Мари иленнән





булып, шунда яшәсә дә, күп еллар Татарстан күләмендәге ярышларда - Теләче районы данын, ә Россия турнирларында Татарстан данын яклап көрәште. Быелгы сезонда Муса Лаеш районы өчен көрәшәчәк, аны Лаеш спорт мәктәбенең директоры итеп куйганнар икән. “Шундый батыр мәйданга чыккач, башкалар икенче рольләргә дә риза инде”, - дип, халык, матур көрәш күрүенә канәгать булып, таралыша башлады.

# БӨТЕНХАЛЫК САБАН ТУЕ



***17 – 18 июньдә Ульяновскида XXII Федераль Сабан туе үткәрелде. Исегезгә төшереп үтәбез, Федераль Сабан туе Ульяновскида дүртенче мәртәбә узды һәм, һәрвакыттагыча, бик югары дәрәҗәдә оештырылган иде. Бәйрәмгә Россиянең 52 регионыннан 60 меңнән артык кеше килгән. Самар өлкәсе делегациясе иң зурларының берсе булгандыр: өлкә “Туган тел” җәмгыяте, өлкә һәм шәһәр автономияләре, “Дуслык” иҗади-иҗтимагый оешмасы, Камышлы һәм Похвистнево районнары, Сызран һәм Новокуйбышевск милли оешмаларының вәкилләре бар иде.***

***Данияр Сәйфиев.***



Театр чишенү бүлмәсеннән башланган кебек, Ульян Сабан туе да кунакларны кунакханәләргә урнаштырудан башланып китте. Безне Ульян өлкәсенең Ульян районы оештыручылары чәкчәк белән каршы алып, ике көн буе кәефебез - бәйрәмчә, тамагыбыз - тук, тору урыннарыбыз уңай булсын өчен җавап бирделәр.

Сабан туе илә дә зур Җиңү паркында узды. Быел гына яңартып төзекләндерелгән ипподром да аңа терәлеп тора, ерак йөрисе түгел. Ә паркта ниләр генә юк бүген! Чәкчәк-бавырсаклар, кием-салым, милли яулыклар, бизәнү әйберләре, сувенирлар һәм уенчыклар сатыла, аерым мәйданчыкларда төрледән-төрле спорт ярышлары, милли уеннар, концертлар бара, кайнар пылау һәм шашлыклар янында да халык күп бөтерелә.

Ипподромда Ульян өлкәсенең 21 районы да үз милли йортларын корып куйганнар. Биредә та-



тар мәдәнияте, гореф-гадәтләре, тормыш-көнкүреш әйберләре, Татарстан осталарының декоратив-гамәли иҗаты белән дә танышырга мөмкин иде. Андагы сыер сарайлары һәм ат абзарлары, печән сарае, борынгы әйберләр, милли киемнәргә киенгән курчаклар, ашамлыклардан сыгылып торган өстәлләр дисеңме!

Сабан туеның беренче көне башлыча ат чабышларына багышланган иде. Ипподромны бу көнгә әзерләү өчен Ульяновск хөкүмәте 250 миллион сум акча тоткан, дип






ишеттек. Саллы сумма! Тамашачылар, тиешле вакыттан алдарак та килеп, урыннар ала башладылар. Һава торышы нинди булуга карамастан, ярышлар үткәреләчәге алдан ук билгеле. Чөнки махсус чабыш юллары, яңгыр яуса да, пычрак булса да, таймый торган итеп эшләнгән.

Бу көнне Сабан туена китерелгән 100 нәселле чабышкыларның 70се ярышты. Һәр чабышта 10 ат катнашты. Алгарак китеп, шуны да әйтим инде: Самар өлкәсенең Гали авылыннан килгән җайдакларга бу юлы җиңү шатлыгын татырга туры килмәде, призлы урыннарга чыга алмадылар. Ә җиңү өчен стимул бар иде. Призлар фонды 5 миллион сум тәшкил итә!

Бөтенроссия Сабан туе хөрмәтенә багышланган беренче заездда җиңүчегә 1 миллион сум акча бүлеп бирелгән иде. Бу җиңү Шэрами кушаматлы атка атланган Андрей Вилкинга тәтеде. Ул атлар белән 11 ел элек Пенза ипподромында шөгыльләнә башлаган, хәзер Мәскәүдә яши.

Ульян өлкәсе губернаторы призы тагын да күбрәк - 1,2 миллион сум. Беренче биш җайдакка 600шәр, калганнарга 300, 180, 72 һәм 48әр мең сум акча тапшырылды. Ә беренче булып бу чабышта Воронеж өлкәсенең Чесменский конезаводыннан чыккан Госе кушаматлы атта Мәскәү жоккее Александр Несяев килде.

Шулай ук Татарстан Республикасы, Казан, Ульян, Түбән Кама шәһәрләре призларына да чабышлар үтте. Халык күңеленә бу тамаша бигрәк тә хуш килде, һәркем үз регионы атлары өчен җан атып, кул чабып, хуплау тавышлары ишеттереп торды. Җайдакларның сүзләренә караганда, бу ярышлар югары дәрәҗәдә үтте, чөнки анда бөтен Россиядән җыелып килгән иң яхшы атлар һәм җайдаклар катнашты. Ләкин ставкалар булмады. Әмма киләчәктә Ульян ипподромында бу тәҗрибәне дә яңартып җибәрерләр әле, дигән сүзләр ишетелгәләде. Заездлар арасында тамашачыларның күңелен җырбиюләре белән төрле регионнардан килгән артистлар ачты.



Кичен Сабан туе кунакларын "Губернаторский" Мәдәният сараенда чыгыш ясарга әзерләнүче Татарстанның җыр һәм бию ансамбле һәм Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган артисты Салават Фәтхетдинов көтәләр иде. Сәламләү сүзе белән Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев чыгыш ясады. Ул Ульян өлкәсе губернаторы Александр Русскихка, шундый





шәп Сабан туе оештырган өчен, рәхмәтләрен җиткерде, Татарстан һәм Ульян өлкәсе арасында дуслык мөнәсәбәтләре урнашуы, икътисад һәм мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек җепләре сузылуы һәм елдан-ел ныгый баруы турында сөйләде.

Сабан туеның икенче көне кояшлы җылы һава белән куандырды. Ә кунаклар һаман киләләр дә киләләр. Бөтен җирдә татар җыры, гармун тавышлары яңгырый. Сәхнәләрдә дә Татарстан һәм Ульян өлкәсе артистлары, узышып-ярышып, бөтен сәләтләрен күрсәтергә тырышалар. Татар йорты киң итеп капкаларын ачып, йорт хайваннары, авыл хуҗалыгы техникасы күргәзмәләрен эшләтеп җибәрде. Халык еракларга сузылып киткән йөзләгән сату рәтләре буйлап йөрде, конкурсларда һәм ярышларда катнашты.

Төш вакытына табарак регионнардан килгән делегатлар, үз әләмнәрен күтәреп, сафларга тезелделәр. Алар XXII Федераль Сабан туен рәсми рәвештә ачып җибәрү өчен Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановны һәм губернатор Алексей Русскихны көтәләр иде. Менә алар да килеп җиттеләр, төп сәхнәдә һәм аның астында төрле иҗат коллективлары чыгышы башланды. Рөстәм Миңнеханов һәм Алексей Русских делегатлар белән аралашып йөрделәр. Самар делегатлары янына килеп җиткәч, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов "Туган тел" президенты Ильяс Шәкүров белән дә берничә сүз алышты, Ильяс Гомәр улы аңа "Башка регионнарда мондый журналлар юк!" - дип, берничә "Самар татарлары" журналын тапшырды.

Сәхнәгә күтәрелгәч, Рөстәм Миңнеханов:

- Бу татарлар бәйрәме генә түгел, бу бөтенхалык бәйрәме булды әле. Шушы кадәр югары дәрәҗәдә оештырылган Сабан туе өчен ульяннлыларга чын күңелемнән рәхмәтләремне җиткерәм, - диде.





- Мин дә Татарстан кунакларын сәламләп, XXII Федераль Сабан туен үткәрүдә күрсәткән булышлыклары өчен рәхмәтләремне әйтәм, - диде үз чиратында Ульян өлкәсе губернаторы. - Безгә дүртенче мәртәбә XXII Федераль Сабан туен кабул итәргә насыйп булды. Моның белән чиксез горурланабыз. Сабан туе Россиядә яшәүче төрле милләт халыкларының гомум мәдәни-тарихи бәйрәменә әверелде. Бүгенге бәйрәм өлкә халкы һәм килгән кунакларыбыз күңелендә озакка сакланыр, дип уйлыйм. Былелгы тынгысыз чорда тынычлык, яхшылык, килешүчәнлек идеялары бигрәк тә зур кыйммәткә ия. Әлеге уртак бәйрәмебез Россия халыклары өчен генә түгел, бөтен дөнья халыклары өчен дә аңлашып яшәү үрнәге булсын иде.

Ахырда Рөстәм Миңнеханов һәм Алексей Русских авыл хуҗалыгы алдынгыларын, мәдәният хезмәткәрләрен, Ульян өлкәсенең һәм Татарстанның матбугат хезмәткәрләрен бүләкләделәр. Ә Ульян өлкәсенең милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе Рәмис Сафинга "Газель" микроавтобусы ачкычлары тапшырылды.

- Дүртенче мәртәбә Федераль Сабан туен каршы алабыз. Һәм ул елдан-ел яхшыра гына бара. Бу - Татарстан хөкүмәтенең, өлкә татар автономиясенең һәм Ульян өлкә хөкүмәтенең аңлашып эшләү нәтиҗәсе. Безнең өлкәдә 150 мең татар яши. Авылларга йөреп тору өчен, Рөстәм Миңнехановның бүләге бик тә кирәк иде безгә. Зур рәхмәт! – диде журналистлар белән сөйләшкәндә Рәмис Сафин.

Ә Сабан туе дәвам итә. Спорт программасында төп урынны, әлбәттә, көрәш бәйгесе били. Көрәш мәйданын халык тыгыз итеп уратып алган, борын төртерлек түгел: бөтен Россиядән җыелып килгән батырлар "Лада-Гранта" өчен көрәшә. Бу юлы абсолют батыр исеменә күптәнге танышыбыз, Самар Сабан туйларында да күп мәртәбәләр җиңүче булып танылган Димитровград көрәшчесе Сергей Павлик лаек булды. Автомобиль ачкычларын аңа президент үзе тапшырды.

- Күп Федераль Сабан туйларында катнашырга туры килде. Ләкин бу кадәр купшылыкны, киң күңеллелекне күргәнем юк иде, - дип уртаклаша тәэсирләре белән Фәһим Йосыпов, Самар өлкә "Туган тел" татар җәмгыяте әгъзасы.
– Бик шәп итеп оештырылган, барысы да уйлап эшләнгән, кунаклар саны бихисап... Күпме көч куелганы турында уйлыйсым да килми, куркыныч. Әлбәттә, ошый миңа бу Сабан туе!

Киләсе Федераль Сабан туе Кузбасс шәһәрендә узачак. "Тулпар ат" сынын Татарстан президенты кулыннан Кемерово өлкәсе губернаторы Сергей Цивилёв кабул итеп алды.

***Эчпочмак – татарское национальное блюдо, печеное изделие из дрожжевого, реже пресного теста, с начинкой из картофеля, мяса, как правило баранины, и лука. Определяющей особенностью блюда является вовсе не его форма, а способ приготовления, при котором начинка в эчпочмак кладется сырой, в отличие от большинства других подобных изделий.***





**Подготовила Гюзэль Абдрафигова**

# ЭЧПОЧМАК

**Ингредиенты:**

Тесто
- вода ........... 200 мл
- молоко......... 200 мл
- дрожжи живые....30 г
- раст. масло .....100 мл
- яйцо ..............2 шт.
- соль................. 15 г
- сахар...............50 г
- мука ............. 600 г

Начинка:
- мясо ............. 300 г
- картофель ........2 шт.
- лук репчатый.....2 шт.
- мясной бульон .1 чашка
- соль, перец

## Рецепт приготовления:

Молоко смешиваем с водой, немножечко подогреваем и отливаем несколько капель в пиалу. Растворяем в этой смеси соль, сахар и дрожжи, ждем, когда появится на поверхности пена. В жидкость добавляем масло, дрожжи, 2 белка и один желток. Муку протрушиваем через сито и вымешиваем хорошую основу. Накрываем и убираем в прохладное место. Начинка состоит из мелкорубленых мяса, картофеля и лука. Все компоненты смешиваем, притрушиваем перцем и присаливаем.



Постоявшее тесто разделяем на колобочки. Каждый раскатываем в кружок, на серединку кладем начинку и формируем треугольник. Раскладываем их на лист бумаги не очень близко друг к другу.

Оставляем эчпочмак с мясом и картошкой немного подойти. Выпекаем в духовке при 180 градусах 30 минут.



# Булочки к чаю

## Рецепт приготовления:

Разведите дрожжи в небольшом количестве теплого молока. Далее добавьте сахар, муку, масло, соль и разведенные дрожжи и замесите не крутое тесто накройте плотно полотенцем и дайте отстояться. Далее полученное тесто разделите на равные доли и сделайте формы в виде булочек. После этого булочки следует аккуратно уложить на противень примерно на полчаса, чтобы дать еще подняться. Далее смажьте полученные булочки взбитым желтком или топленым молоком и посыпьте сахаром. Булочки следует выпекать в духовке при 180°С до готовности.

**Ингредиенты:**

- мука ............. 600 г
- молоко......... 500 мл
- соль...............1 ч. л.
- раст. масло ..... 2 ст. л.
- сахар............ 2 ст. л.
- дрожжи сух. ...... 2 ч. л.



# «Губадия»

***Татарский пирог***



**Ингредиенты:**

Тесто
- Сметана 20%. . . . . . 150 г
- Молоко . . . . . . . . . 50 мл.
- Яйцо . . . . . . . . . . . . . . 1 шт.
- Слив. масло . . . . . .100 г
- Дрожжи сух. . . . .1,5 ч. л.
- Соль . . . . . . . . . . . . . .1 ч. л.
- Сахар . . . . . . . . . . . . 50 г
- Мука . . . . . . . . .450-500 г

Начинка:
- Рис. . . . . . . . . . . . . . . . 200 г
- Вода . . . . . . . . . . . 200 мл
- Масло для риса . . .50 г
- Соль для риса . .1/3 ч. л.
- Корт (сары иримшик) . . . . . . . 500 г
- Сахар для корта . . .50 г
- Масло для корта . .50 г
- Яйца . . . . . . . . . . . . . . .5 шт.
- Изюм . . . . . . . . . . . . 300 г

Посыпка:
- Мука . . . . . . . . . . . . . . .50 г
- Слив. масло . . . . . . .40 г
- Сахар . . . . . . . . . . . . . .30 г




## Рецепт приготовления:

Для теста в сметану добавим молоко, яйцо, растопленное сливочное масло, дрожжи, соль, сахар и муку. Замесим тесто. Накроем пленкой и уберем в теплое место на 1,5 часа.

Для начинки в сковороду высыпаем корт, добавим сахар и сливочное масло. Включаем на сильный огонь и перемешиваем. Масса загустеет и станет плотной. Убираем с огня и даем остыть. В маленькую кастрюлю нальем воду и вскипятим ее. Добавим промытый рис, поставим на средний огонь и варим 7 минут до полуготовности. Затем добаим соль и масло. Все перемешать и дать остыть. Приготовим посыпку. В муку добавим сахар и масло, вилкой перетрем в крошку. У нас получилось 870 г теста, отрежем от него кусочек весом 250 г и отложим его на время. Из основного теста раскатаем большой круг. Выложим его в круглую форму диаметром 24 см. Приступаем к сборке. Первым слоем кладем корт, слегка утрамбуем его. Вторым слоем половину риса. Третьим промытый изюм, далее оставшуюся половину риса. Последний слой – мелконарезанные отварные яйца. Немного посолим. Раскатаем вторую половину теста, в небольшой круг. И выложим на пирог. Защиплем края. Сделаем в середине небольшое отверстие и посыпаем сверху мучной крошкой. Края смажем яйцом и выпекаем в духовке 200°C 30-35 минут.

# ӘЙ, ЯМЬЛЕ ҖӘЙ, ТӘМЛЕ ҖӘЙ

*Ниһаять, көтеп алынган җәй җитте. Су буйлары, болыннар шау чәчәккә төренде, урманнарда, бакчаларда татлы җиләкләр пешә башлады. Хуш исле үләннәр, печән, дымлы чирәм исе башны әйләндерә. Тәүлек буе бертуктамый кошлар сайрый, чуар күбәләкләр һавада уйный, эшчән бал кортлары, чәчәк таҗларына кунып, татлы ширбәт җыя. Әй, ямьле дә, тәмле дә соң безнең җәйләребез!*

Шәүкәт Галиев

## ТӘМЛЕ ҖӘЙ

Аланнарда – җиләк исе,
Басуларда – иген исе,
Җәйләүләрдә – сөт исе...
Тагын аллы-гөлле чәчәк,
Кайнар кояш өстисе –
Шушы булыр җәй төсе!



Татар халык авыз иҗаты

## ТАКМАКЛАР, ЭНДӘШЛӘР

Әй, Зөбәйдә, Зөбәйдә,
Бии-бии үс, әйдә,
Үсеп җит тә гүзәл җәйдә
Гөлләргә су сип, әйдә.

Минем кызым дәү кебек,
Бакчадагы гөл кебек.
Ике күзе янып тора,
Кара бөрлегән кебек.
Көзгегә карыйм әле,
Чәчемне тарыйм әле,
Әбиләргә бер атнага
Кунакка барыйм әле.



Рәфис Корбан

## КОЯШ – БЕЗНЕҢ ДУСТЫБЫЗ

Иртән торып, юлга чыксак,
Кояш озатып килә.
Көне буе юлда кояш,
Көн буе безнең белән.

Суга керсәк, ул да керә,
Чыныктыра нурлары.
Безнең белән уйный кояш,
Без – кояшның дуслары.

Җәй буе озатып барды
Болыннар буе безне.
Тәмле җиләкләр пешереп,
Сыйлады һәммәбезне.

Көнгә чыксак, каршы ала,
Сибеп җылы нурларын.
Кояш һаман безнең белән,
Без – кояшның дуслары!



Вәсимә Хәйруллина

## ШИФА ЧӘЕ

Мунча яккан көнне әни
Шифа чәе пешерә.
Шифа чәе җәй көннәрен
Исебезгә төшерә.

Әнием аларны җәен
Урман, болыннан җыйган.
Кышын кечкенә чәйнеккә
Бөтен җәй үзе сыйган.

Ничә төрле яфрак, җимеш,
Җир җиләге, карлыган.
Исле үлән, бөтнек, чия,
Мәтрүшкә дә калмаган.





Вәсимә Хәйруллина

# ТАБИБЛАР ЯНЫБЫЗДА

Күздән яшь агып тора,
Борыннан тамып тора.
Тамак ачытып тора,
Кытыклап, кырып тора.

Салкын тиюдән туйдым,
Әнигә әйтеп куйдым:
– Бирмә дару, уколлар,
Мин чыныгырга булдым.

Иң яхшы микстура
Булыр ул физкультура.
Кирәкми таблетка,
Күтәреләм турникта.

Уколлар урынына
Чыгам ишегалдына.
Салкын су коям баштан,
Бик авыр булды башта.

Иң шәп табиб – витамин,
Җәй авылга кайтам мин.
Ашыйм акы, балтырган,
Кишер, җиләк, карлыган.

Их, шәп авыл җәйләре,
Җыям үлән чәйләре.
Эшлим бакча, ындырда,
Чөгендер утыйм кырда.

Җәй үтә дә, көз җитә,
Минем китәр көн җитә.
Буйга үстем, ябыктым.
Чирләмәдем, савыктым.
Бирә дарулар табып,
Табигать – үзе табиб.

Фирдәвес Зариф

# ТАТЛЫ ҖӘЙ

Төлке баласы Шаян кошлар сайравына уянды. Күл буена барып, битен юды. Әйләнеп кайтканда, әнисе өстәлгә тәмле-татлы ризыклар куйган иде. Тамагын туйдыргач, Шаян әнисенә рәхмәт әйтте.

– Улым, Җәйгә дә рәхмәт әйт. Бу – Җәй нигъмәтләре, – диде әнисе, Шаянның башыннан сыйпап.

– Әнием, ә Җәйне кайдан табармын соң мин? – дип сорады Шаян.

– Җәй җиләкле урман аланында яши. Әмма ул акыллы балаларга гына күренә.

– Ә акыллы бала нинди була соң, әнием?

– Акыллы бала агач һәм куак ботакларын сындырмый, чәчәкләрне өзми, суны пычратмый, улым. Гомумән, башкаларга гел игелек кенә кыла. Шаян, Җәйне күрү өчен, урман аланына юнәлде. Барганда урман сукмагында бер Кырмыскага чак кына басмый калды.

– Гафу ит, зинһар, Кырмыска дус, – диде Шаян һәм әдәп белән аның яныннан сак кына үтеп китте. Ул ерак китәргә өлгермәде, куаклар арасында чырылдашкан тавышлар ишетте. Шәүлегән баласы оядан егылып төшкән икән. Әнисе, ни эшләргә белми, аның янында бөтерелә, елый. Шулчак кинәт каяндыр Карга атылып чыкты. Шаян, сикереп, Шәүлегән баласын гәүдәсе белән каплады. Төлке баласына бәрелгәч, Карга усал каркылдап, очып китте. Шаян бәләкәчне оясына салды.

– Рәхмәт сиңа, акыллы малай, – диде Шәүлегән. – Син минем баламны үлемнән йолып калдың. Мин, батырлыгыңны җырга салып, башкаларга да сөйләрмен. Һәм Шәүлегән, биеккә күтәрелеп, өздереп сайрый башлады. Шаян алга атлады. Кинәт урман ачыклыгындагы агач ботаклары шартлап сына башлады. Якынрак килеп караса, Аю балалары икән.

– Нигә ботакларны сындырасыз?! – диде Шаян, аларны шелтәләп.

– Без бит көй чыгарабыз, – дип аклана башладылар нәни йөнтәскәйләр, уңайсызланып.

– Сез шулай көй чыгарсагыз, кечкә урманда бер исән агач та калмас, – диде Шаян һәм аларга корыган агач чырасыннан кубыз ясап бирде. Шулай, урман аланына җитүен сизми дә калды Шаян. «Инде ничек Җәйне табармын», – дип, күл буендагы агач төбенә утырып, кайгыга чумды.

Шулчак гаҗәеп ягымлы тавыш ишетелде.

– Кайгырма, Шаян, мин монда. Күрәсеңме, кызарып җиләкләр пешә. Кылган игелекләрең өчен алар сиңа бүләгем булсын. Кояш җылы нурын сипкәндә, кошлар сайраганда, чәчәкләр хуш ис таратып, өсләрендә күбәләкләр очканда, мин һәрчак янында булырмын.

Шаян җиләк өзеп алды да, күзләрен йомып, авызына капты. Кара син аны, Җәй нинди татлы икән, ә?!

Абдулла Алиш

# КАЗ БЕЛӘН АККОШ



Очы-кырые күренмәгән болын уртасында зур бер күл булган. Тирәләре аның яшел кыяклар, шаулап торган камышлар белән капланган икән.

Бу күл буена кеше аягы бер дә басмаган, ул тирәләрдә аучыларның мылтыклары да шартламаган.

Шул тыныч күлдә Аккош белән Каз яшәгәннәр. Дус булып, тату булып гомер кичергәннәр. Балык ашаганнар, су эчкәннәр, йомырка салганнар, бала чыгарганнар.

Җәйнең матур бер көнендә бу ике күрше балалары турында сөйләшкәннәр. Киек Каз әйткән:

– Улым ашны аз ашый, суны гына күп эчә, – дигән.

Аккош әйткән:

– Минем балам бик яхшы ашый, зур үсә, – дигән.

Каз үзенең бәбкәсен төрлечә сыйлап карый икән: тәмле-тәмле балыклар, яшел бакалар, тәмле кыслалар тотып китерә. Баласы, үзе зур булса да, кулына кашык тотып ашамаган, әнисенең ашатуын көткән. Ашау аңа бик зур эш булган. Ашарга-эчәргә тотынса, ул тәмам йөдәп беткән. Ә дуга муен, аккош баласы, кыстатып та тормый, кашыкны үзе тотып, азыкны кат-кат чәйнәп, тәмле итеп ашый икән.

Көннәрдән бер көнне киек Каз белән Аккош баласы әниләренә килгәннәр дә:

– Әни, безгә велосипед алыйкчы! – дип үтенгәннәр.

– Ярый, барсак барыйк, алсак алыйк, – дигәннәр әниләре.

Улларын ияртkәннәр дә велосипед сатыла торган кибеткә киткәннәр. Анда барып кергәннәр дә әниләре:

– Иптәшләр, безнең сөекле улларыбызга велосипед бирегезче! – дигәннәр.

Шунда сатучылар йөгереп килгәннәр дә:

– Рәхим итегез, рәхим итегез! – дип, көмеш төсле ялтырап торган велосипедлар китереп биргәннәр. Шунда Аккошның улына:

– Теләгәнеңне сайлап ал, акыллым! – дигәннәр.

Аккош баласы велосипедка менеп атланган да йөгерткән дә киткән. Аңа карап, сатучылар:

– Менә егет икән бу малай, тамагына шәп ашый, ахры, – дигәннәр, ә Аккош, үз баласының булдыклылыгын күреп, елмаеп, кәефләнеп, карап тора икән, ә малай велосипедны йөгертә дә йөгертә икән.

Киек Каз бәбкәсенә дә чират җиткән. Ул, Аккош бәбкәсе белән бер яшьтә булса да, аңа караганда, бик ябык, буйга да бик кечкенә икән. Аңа да велосипедның көмеш төслесен биргәннәр:

– Яле, акыллым, син дә йөгереп кара! – дигәннәр.

Каз бәбкәсе бер атланып караган – булдыра алмаган, икенче атланырга уйлаган – егыла язган, өченче тапкыр атланырга теләгән икән – егылып ук киткән, әйләндермәгәч, велосипед та тәгәрәмәгән. Кибеттә эшләүче абыйлар шунда ук йөгереп килеп җиткәннәр, киек Каз бәбкәсенә:

– Син, акыллым, ашны аз ашыйсың, вакытында йокламыйсың. Һавада уйнамыйсың, ахры, шуңа күрә бик ябык, буең да кечкенә, шунлыктан велосипедка да аягың җитми, хәзергә өеңә кайтып тор, зур үскәч, килерсең, – ди-гәннәр һәм велосипедны да алып киткәннәр.

Каз бәбкәсе бик күңелсезләнеп кайтып киткән, ә Аккош бәбкәсе велосипедка атланып җилдергән.

Хәзер инде, «велосипедка аягым җитсен, аягым җитсен» дип, Каз бәбкәсе азыкны да ашый, вакытында йоклый да, саф һавада да уйный икән.

**Самарский государственный социально-педагогический университет,** основанный 16 октября 2011 года, является старейшим вузом Самарской области, ставшим альма-матер для многих поколений жителей Самары и других городов России и зарубежья.

Сегодня в СГСПУ реализуется широкий спектр направлений подготовки по программам высшего образования всех уровней: бакалавриат, специалитет, магистратура и аспирантура. В докладе Правительства РФ Федеральному собранию о политике в сфере образования сообщалось о заметном сокращении к 2024 году количества бюджетных мест в российских вузах по сравнению с 2019 годом. В СГСПУ за последние 5 лет практически на 200 мест увеличились контрольные цифры приема, финансируемые из средств федерального бюджета. Эта тенденция увеличения количества бюджетных мест в СГСПУ продолжится и в 2022 году, для приема СГСПУ будет выделено 709 бюджетных мест на все уровни образования и формы обучения. Более половины их этого количества, 514 мест, будет выделено для приема на бакалавриат и специалитет на 1-й курс очной формы обучения, 170 – заочной формы обучения, 25 – очно-заочной формы обучения.

Ежегодно в марте – апреле Самарский государственный социально-педагогический университет проводит олимпиады для учащихся учреждений среднего общего и среднего профессионального образования. Победители и призеры олимпиады получают право на получение целевого направления Министерства образования и науки Самарской области для поступления в СГСПУ на направление подготовки «Образование и педагогические науки». Кроме этого, победители и призеры олимпиады при поступлении в СГСПУ на обучение по программам бакалавриата получают дополнительные 10 баллов за индивидуальные достижения к баллам ЕГЭ. Победители олимпиады, учащиеся 9-х, 10-х классов получают право на зачисление в Центр довузовской подготовки СГСПУ для бесплатного обучения в группах по подготовке к единому государственному экзамену по профилю олимпиады.

Традиционно для учащихся 11-х классов мы проводим подготовку к вступительным испытаниям. Для поступающих доступны варианты: очная форма и дистанционная форма. Занятия проводятся с 01.07 по 14.07 ежедневно, включая выходные.

Время проведения занятий с 09.00 до 16.00.

Запись на занятия и консультации по телефону 8 (846)207-88-77, e-mail: kurs@pgsga.ru


**ПРИЕМНАЯ КОМИССИЯ**

г. Самара,
ул. Антонова-Овсеенко, 24,
каб. 207

**тел. 8 (846) 207-88-77**

priem@sgspu.ru






# ООО «АКТАШ» предлагает услуги по правовой защите граждан и организаций



## ОКАЗЫВАЕМЫЕ УСЛУГИ:

- Юридическая помощь физическим лицам
- Юридическое абонентское обслуживание компаний
- Представительство в арбитражных судах и судах общей юрисдикции
- Услуги в области взыскания задолженности



За дополнительной информацией обращаться по телефону

**8 (927) 797-82-80**

либо по адресу: г. Самара, проспект Кирова, д. 206.